# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2022 4(36)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., ЛУКЬЯНЧЕНКО Е.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Гыйлемшин Ф.Ф.* XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы кыйсса әсәрләрендә саннарның кулланылыш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . 7
*Гыйләҗетдинова Г.Х.* XVII гасыр рус сатирик әдәбиятында төрки сүзләр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
*Юсупов А.Ф.* XIX гасыр (суфичылык) поэзиясе телендә гарәп һәм фарсы чыгышлы ярдәмлек сүзләрнең үзләштерелеше. . 18
*Гыйльмуллин Р.А., Хәкимов Б.Э., Гафарова В.Р.* Татар телендәге текстларда исемләнгән объектларны тамгалау мәсьәләсенә карата. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
*Бәдртдинова А.Ә.* Милли-мәдәни мирас күренеше буларак татар теле сөйләшләренең аваз үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . 34

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Шәрипов Ә.М.* Сирин иҗаты: совет чынбарлыгы чагылышы . . . . 43
*Юсупова Н.М.* XX гасырның икенче яртысы татар шигъриятендә лирик герой концепциясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
*Габидуллина Ф.И.* Ф. Бәйрәмованың «Кыңгырау» повестенда «кыңгырау» образ-символы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
*Мотыйгуллина Ә.Р.* Н. Яһудинның «Атлы казаклар» романы: татар казаклары тормышына бер караш . . . . . . . . . . . . . . . . 75
*Хәсәнова А.Н.* «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәренең идея-эстетик кыйммәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Хафизова Г.С.* Татарстан Республикасының Азнакай районы татар авылларында бала табуга бәйле йола фольклорының бүгенге торышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Әхмәтов Д.И.* Татарстан АССРда балигъ булмаганнар арасында сукбайлык һәм күзәтүчесезлеккә каршы көрәш чаралары (1945–1953 еллар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Шәкүрова М.М.* М.Ә. Фазлуллинның 1920–1930 елларда дидактика өлкәсендәге эшчәнлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
*Батыршина Г.Г., Гарипова-Хәсәншина В.М.* Татар теле дәресләрендә вәгазь текстлары белән эш *(Россия ислам институты мисалында)*. . . . . . . . . . . . . . 116

## СӘНГАТЬ

*Гыйлемҗанова Г.Г.* Татар халкының мөнәҗәт жанрын ислам һәм гомумтөрки шигъри-музыкаль традицияләр контекстында чагыштырма өйрәнү мәсьәләсе турында . . . . . .125

*Юнысова Г.Ф.* Татар бишек җырларының дини эчтәлеге . . . . .131

## ТӨГӘЛ ФӘННӘР

*Галимҗанов Ә.Ф., Галимҗанов Р.Ә.* Зур мәгълүмат массивларын эшкәрткәндә кулланылучы нейрон челтәрләре тигезләмәләре һәм аларны чишү ысуллары . . . . . . . . . . . . .142

## ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР

*Гали Рәхим*. Академия театрында тарихи әсәрләр . . . . . . . . .147

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Әлмиева Н.Ю.* Җырчы рәссам Бакый Урманче. . . . . . . . . . . .153

*Хөсәенова Г.Р.* Тел галиме Үзбәк Байчура тупланмасында шәхес һәм чор язмышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .162

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Галиуллина Г.Р.* Метрика кенәгәләре ни сөйли? . . . . . . . . . .168

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Гилемшин Ф.Ф.* Особенности употребления имен числительных в произведениях жанра кысса второй половины XIX – начала XX века . . . . . 7
*Гилязутдинова Г.Х.* Тюркизмы в русской сатирической литературе XVII века . . . . . 14
*Юсупов А.Ф.* Проблемы грамматического освоения арабских и персидских служебных слов в старотатарском языке XIX века. . 18
*Гильмуллин Р.А., Хакимов Б.Э., Гафарова В.Р.* Проблема разметки именованных сущностей в текстах на татарском языке . . . . . 28
*Бадретдинова А.А.* Звуковые особенности диалектов татарского языка как национально-культурное достояние . . . . . 34

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Шарипов А.М.* Отражение советской действительности в творчестве Сирина . . . . . 43
*Юсупова Н.М.* Концепция лирического героя в татарской поэзии второй половины XX века . . . . . 58
*Габидуллина Ф.И.* Образ-символ «колокольчик» в повести Ф. Байрамовой «Колокольчик» . . . . . 67
*Мотигуллина А.Р.* Роман Н. Ягудина «Конные казаки» : взгляд на жизнь татарских казаков . . . . . 75
*Хасанова А.Н.* Идейно-эстетическая ценность произведения «Дафтар-и-Чингиз наме». . . . . . 85

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Хафизова Г.С.* Фольклор родильной обрядности, бытующий у татар Азнакаевского района Республики Татарстан . . . . . 91

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Ахметов Д.И.* Меры по борьбе с беспризорностью и безнадзорностью среди несовершеннолетних в Татарской АССР (1945–1953 годы) . . . . . 100

## МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Шакурова М.М.* Деятельность М.А. Фазлуллина в 1920–1930-е годы в области дидактики . . . . . 105
*Батыршина Г.Г., Гарипова-Хасаншина В.М.* Работа над текстами проповеднического характера на уроках татарского языка *(на примере Российского исламского института)*. . . . . . 116

## ИСКУССТВО

*Гилемьянова Г.Г.* Татарский народный жанр мунаджат в контексте исламской и общетюркской поэтико-музыкальной традиции: проблемы сравнительного изучения . . . . . . . . . . .125
*Юнусова Г.Ф.* Конфессиональный контент в татарских колыбельных песнях . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .131

## ТОЧНЫЕ НАУКИ

*Галимянов А.Ф., Галимянов Р.А.* Уравнения нейронных сетей для обработки больших данных и методы их решения . . . . . .142

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Гали Рахим*. Исторические произведения на сцене Академического театра . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .147

## ПЕРСОНАЛИИ

*Альмеева Н.Ю.* Поющий художник Баки Урманче . . . . . . . . . .153
*Хусайнова Г.Р.* Судьбы личности и эпохи в коллекции языковеда Узбека Байчуры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .162

## НОВЫЕ КНИГИ

*Галиуллина Г.Р.* О чем говорят метрические книги? . . . . . . . .168

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145

***Ф.Ф. Гыйлемшин***

# XIX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ – XX ГАСЫР БАШЫ КЫЙССА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ САННАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Данная статья посвящена анализу имен числительных, использованных в татарских произведениях, относящихся к жанру кыйсса. Объектом нашего исследования выступают тексты, которые оказали серьезное влияние на формирование норм современного татарского литературного языка. В текстах произведений жанра кыйсса количественные числительные используются для выражения отношения времени, неопределенности, количества предметов, возраста человека и др. Приблизительные числительные выражены парными словами. В текстах произведений жанра кыйсса используется большое количество числительных, среди которых широко распространены количественные числительные, выступающие в номинативном и сакральном значениях. Остальные виды числительных в исследуемых текстах употребляются пассивно, по грамматическим формам и значениям они не отличаются от форм числительных, используемых в современном татарском литературном языке.

**Ключевые слова**: количественные числительные, лексема, морфология, порядковые числительные, жанр кисса, литературный язык, дробные числительные.

This article is devoted to the analysis of numerals used in Tatar works related to the genre of the story (kyssa). The object of our study is texts that have had a serious impact on the formation of the norms of the modern Tatar literary language. In the texts of works, cardinal numbers are used to express the ratio of time, uncertainty, the number of objects, the age of a person, etc. Approximate numbers are expressed in paired words. In the texts of these works a large number of numerals are used, among which quantitative numerals are widespread acting in nominative and sacred meanings. The remaining types of numerals in the studied texts are used passively; in grammatical forms and meanings they do not differ from the forms of numerals used in the modern Tatar literary language.

**Key words:** cardinal numbers, lexeme, morphology, ordinal numbers, kyssa genre, literary language, fractional numbers.

Татар әдәбияты, дөньяның күп кенә әдәбиятлары кебек үк, төрле жанрларга бай. Алар арасында кыйсса жанры да лаеклы урын алып тора. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Насретдин Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» әсәрләре татарлар арасында элек-электән бик популяр булган. قصة «кыйсса» термины гарәпчәдән «хикәя, повесть, новелла» дип тәрҗемә ителә [Баранов, б. 639]. Кыйсса жанры татар әдәбиятында Көнчыгыш әдәбияты тәэсирендә барлыкка килә. Озак вакытлар дәвамында әдәби фонд әлеге жанр әсәрләре белән баетыла.

Кыйссалар XIX гасыр татар әдәбиятында аеруча киң таралган була. Ф. Халидинең «Әлф-ләйлә вә ләйлә», Г. Фәезхановның «Тутыйнамә» һәм «Кәлилә вә Димнә», Каюм Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы», «Әбүгалисина кыйссасы» һ.б. Шәрык әдәбияты ядкярләренең тәрҗемәләре нәкъ менә шул чорда барлыкка килә. Әлеге әдәби истәлекләр безнең фәнни тикшерү объекты булып тора да.

Әсәрләрнең теле катнаш форматта язылган, анда халык сөйләме һәм язма әдәби тел формалары үрелеп бара. Әлеге текстларның тел үзенчәлекләрен өйрәнү хәзерге татар әдәби теленең формалашу үзенчәлекләрен ачыкларга мөмкинлек бирә.

Кыйсса жанрында язылган әдәби чыганакларда саннар бик аз кулланылган. Галимнәр күрсәтүенчә, әдәби текстларда саннарны куллану ешлыгы бик югары түгел һәм бу бик табигый, чөнки мондый күренешнең сәбәбе – әдәби әсәрләрдә еш кына уйлап чыгарылган вакыйгалар, реаль булмаган геройлар тасвирлануда, ә төгәл мәгълүмат юк дәрәҗәсендә. Шуңа да карамастан, галимнәр карашынча, әдәби текстларда автор фикерен укучыга җиткерүдә саннарның әһәмияте зур [Жуковская, с. 35].

Кыйссада микъдар саннарының семантик төсмерләре төрле. Шуларга аерым тукталып үтик. Мәсәлән, *ber* (бер) саны түбәндәге мәгънәләрне укучыга җиткерү өчен кулланыла:

– вакыт аралыгын белдерә: *Ber jyl muttasyl mäγarädä jatyb...* [Әбүгалисина, б. 7] ‘Бер ел буена мәгарәдә тордылар...’; *Ber ğomγa ečendä qajtarmaq ixtijaryn šart qyldylar* [Тутыйнамә, б. 5] ‘Бер атна эчендә кире кайтару шарты белән сатып алырга килештеләр’; *Ber säγat qadäre qarab säjir qyldy* [Кырык вәзир, б. 8] ‘ Бер сәгать буе карап йөрде’;

– предметның берлеген белдерә: *Gali Zibaq suny ečeb satučγγa ber altyn birde...* [Әлҗилдү хәмисү, б. 18] ‘Гали Зибак суны эчеп, су сатучыга бер алтын тәңкә бирде...; *Šul qyznyŋ ber märtäbä qarawy... üzemne zar wä γarjan itde* [Әбүгалисина, б. 26] ‘Шул кызның бер карашы мине еларга һәм ыңгырашырга мәҗбүр итте; *Jawlyqlarγa bäjläb qujγan altynlar ber danäse dä betmägän...* [Әлф-ләйлә, б. 145] ‘Яулыкларга төрелгән алтын тәңкәләрнең бер данәсе дә бетмәгән’;

– предметларның яки әйберләрнең аз күләмдә булуын белдерә: *Ber kälimä süz teleŋä kitermä* [Кырык вәзир, б. 5] ‘Бер генә сүз дә әйтмә’; *Ber süz belän sine ükendermen* [Кырык вәзир, б. 52] ‘Бер сүз белән сине үкенергә мәҗбүр итәрмен’.

Еш кына *ber* лексемасы кыйсса текстларында билгесезлекне белдерү өчен кулланыла: *Bänem ber matur güzäl bäkirä qyzym bar, šuny siŋa bireb, sin bezdä qalyb häm siŋa ber uryn täγajen idäsem kiläder* [Әлҗилдү рәбигу, б. 91] ‘Минем бер чибәр, гыйффәтле кызым бар, мин аны сиңа кияүгә бирергә, сине монда калдырырга һәм сине бер эш урынына билгеләргә телим’; *Ošbu šähärneŋ bilgele kešesendän ber Säγid isemle säwdägär bar ide* [Тутыйнамә, б. 2] ‘Бу шәһәрнең

мәшһүр кешеләре арасында Сәид исемле бер сәүдәгәр бар иде; Soltan *Mäxmüdneŋ Ijäs iseml̇e ber süekle xas xezmätčese bar ide* [Кырык вәзир, б. 2] 'Солтан Мәхмүтнең Ияс исемле яраткан бер хезмәтчесе бар иде'.

*Ike* (ике) саны кыйсса жанрына караган әсәрләрдә предметның яки затның ике данәдә яки парлы булуын белдерә: *Bašqa wilajätkä kit, ber kükdä ike mah bulmas* [Әбүгалисина, б. 102] 'Башка өлкәгә кит, күктә ике ай булмый...'; *Ike wäzire bar ide, bere bik γalim wä bere bik nadan ide* [Кырык вәзир, б. 39] 'Аның ике вәзире бар иде, берсе бик акыллы, икенчесе бик надан иде'; *Ike dust qočaqlašyb bäxilläšdelär* [Кәлилә вә Димнә, б. 9] 'Ике дус кочаклашып саубуллаштылар'; *Ber ata, ber anadan igez ike bala dönjaγa kileb* [Әбүгалисина, б. 9] 'Бер ата-анадан ике игезәк бала дөньяга килеп'; *Anyŋ ike köčle ügeze bar ide, berenä Šäträbä, berenä Mäträbä dijär ide* [Кәлилә вә Димнә, б. 28] 'Аның ике көчле үгезе бар иде, берсен Шатраба, икенчесен Матраба дип атыйлар иде'.

*Өч* саны кыйсса текстларында әкиятләргә, риваятьләргә хас булган мәгънәгә ия. Ул еш кына әсәрләрдә төгәллек һәм камиллек символы буларак катнаша [Гилемшин, с. 216]: *Öč kön istiräxät ideb* [Әлф-ләйлә ..., 25] 'Өч көн ял итеп ...; *Bän šah xozuryna kileb, jirne öč märtäbä übeb, tordym* [Әлф-ләйлә ..., б. 71] 'Мин шаһ янына килдем дә өч тапкыр җирне үбеп торып бастым'; *γaqylly däxi öč wäzire bar ide* [Кырык вәзир, б. 40] 'Аның өч акыллы вәзире бар иде'.

*Dürt* (дүрт) 'дүрт, *biš* (биш) 'биш', *alty* (алты) саннары кыйсса әсәрләрендә күләмне, вакыт аралыгын һәм пространство кебек мөһим төшенчәләрне белдерүдә актив катнашалар: *Dürt täräzäse bar de* [Кырык вәзир, б. 8] 'Дүрт тәрәзә бар иде...'; *Äj Räzzaq Mutäγal bu qolyŋ köndä dürt märtäbä awymny därjajaγa salyb* [Әлф-ләйлә..., б. 25] 'Йә Аллаһ, бу колың һәр көнне ятьмәсен елгага нибары дүрт кенә мәртәбә ташлый бит...'; *Šah balyqčyγa dürt jöz altyn bireb* [Әлф-ләйлә..., б. 39] 'Шах балыкчыга дүрт йөз алтын тәңкә бирде'; *Biš adämlär ilä totyb bunda kiterdek* [Әлҗилдү хәмисү, б. 11] 'Аны (без) биш кеше, бергә тотып алып килдек'; *Biš ajaqly ğanwar digän bet imeš* [Кырык вәзир, б. 66] 'Биш аяклы җанвар дигәннәре бет, имеш'; *Sin bäŋa alty töstle jefäk alyb qajt* [Әлҗилдү сәдисү, б. 196] 'Син миңа алты төстә ефәк (тукыма) алып кайт; *Alty jök qar ni bähä toryr* [Кырык вәзир, б. 111] 'Алты йөк кар кар күпме бәя торыр...'.

*Җиде* төшенчәсен белдерү өчен текстларда *säbγa* дигән гарәп сүзе кулланылу очрагы да күзәтелә: *Jäš waqyda Qor'än šärifne riwajät säbγa ilä bikläb bänem nam wä šöhrätem jite äklimdä šäjjiγ ide* [Әлф-ләйлә..., б. 64] 'Яшь чагында мин изге Коръән һәм «Җиде риваять»не яттан белүем белән исемем һәм даным җиде өлкәгә таралган иде'.

Кыйсса жанрында язылган текстларда *jide / jite* (җиде) санының кулланылышы да бик үзенчәлекле. Танылган тюрколог Ә.Р. Тенишев фикеренчә, төрки халыкларда әлеге сан күп процессларда катнаша: төрле конфессияләрнең дини карашларын билгеләүдә, астрономик

терминнар һәм күзаллаулар формалаштыруда, фольклор сюжетлары, мәкальләр һәм әйтемнәр төзүдә актив кулланыла [Сравнительно-историческая..., б. 633].

Ислам динендә җиде санының үзенчәлекле мәгънәгә ия булуы да билгеле. Кыйсса жанры текстларында, Коръәндәге кебек үк, *җиде кат күк* төшенчәсе очрый, мәсәлән, *Jide qat kük, här berene qalynlyγy biš jöz jyllyq juldyr* [Кырык вәзир, б. 7] ‘Күкнең җиде катламы, һәрберсенең калынлыгы биш йөз елга тигез; *Xaq Täγalä aŋa jide qat kükne (...) kürsätde* [Кырык вәзир, б. 5] ‘Аллаһы Тәгалә аңа күкнең җиде катламын күрсәтте...’.

Өйрәнелә торган текстларда җиде саны *бик күп* дигән төшенчәне дә белдереп килә: *Bunlar jide diŋgezne üteb, ber tawγa jiteb ...* [Әлҗилдү рәбигу, б. 37] ’Алар җиде диңгез аша үтеп, бер тауга җиттеләр’; *Jite čaqrym qadär kitkäč, ber näfis saxraγa čyqdylar...* ‘Алар җиде чакрым җир үтеп, бер матур үзәнгә чыктылар...’; *Jide kön tuj ideb, šadlyqda, ülgälgče, jäγni γomerläre bujynča qaldylar* [Әлҗилдү сәдисү, б. 38] ‘Алар җиде көн туй итеп, үлгәнче, ягъни гомерләре буена, шатлыкта яшәделәр’.

Тикшерелә торган әсәрләрдә башка микъдар саннары да актив кулланыла, алар охшаш функцияләрне башкаралар. Еш кына микъдар саннары төрле объектларның, субъектларның һәм күренешләрнең күплеген белдерәләр: *Mälik wäzire Fazyl Xaqanγa un meŋ altyn bireb äjtde* [Әлф-ләйлә ..., б. 202] ‘Бервакыт патша үзенең вәзире Фазыл Хаканга ун мең алтын биреп әйтте...’; *Un danä alma kitereb äjtde…* [Кырык вәзир, б. 80] ‘Ун данә алма китереп әйтте...’; *Unike kešene alarγa ilče ideb jibärde* [Кырык вәзир, б. 18] ‘Аларга унике кешене илче итеп җибәрде ...’; *Ber fäqyjrgä rast kileb (...) jegerme altyn bireb...* [Әлҗилдү рәбигу, б. 208] ‘Ул бер фәкыйрь кешене очратып, һәм аңа егерме алтын тәңкә бирде...; *Utyz jyl diŋgezdä gizeb* [Кырык вәзир, б. 67] ‘Утыз ел ул диңгездә йөзеп йөрде...’; *Jasdyq östenä ber jawlyqγa töreb ille altyn qujdym ...* [Әлф-ләйлә ..., б. 141] Мин яулыкка төреп илле алтын тәңкәне түшәк өстенә куйдым...’; *Xäkim buny jirgä jatqyzyb, ille qamčy qadär oryač...* [Әлф-ләйлә..., б. 187] ‘Хаким аны җиргә яткызып, илле тапкыр камчы белән суккач...’; *Ber mälik bar ide, jitmeš ike ölkäjä mälik ide...* [Әлҗилдү сәлисү, б. 36] ‘Бер патша бар иде, җитмеш ике өлкәгә хуҗа иде...’.

Кайбер микъдар саннары кешенең яшен белдерү өчен дә кулланылалар: *Ber matur undürt jašenda qyz (...) bäŋa äjtde...* [Әлҗилдү әс-сәни, б. 56] ‘Ундүрт яшьләрдәге матур кыз миңа әйтте...’; *Unbiš jäšenä kerdekdä bän säwdä öčen čit šähärgä kitdem* [Әлф ләйлә, б. 12] ‘(Ул) унбиш яшенә җиткәч, мин сәүдә өчен, чит шәһәргә киттем’.

*Кырык, йөз, мең* саннары шулай ук чамадан тыш күп санда булган предметларны белдергәндә дә катнашалар: *Andan soŋ padišah barča wäzirlären, biklären, wä bašqa γawam xalqyn ğyjyb (...) qyryq köngäčä zäwyq wä safalar itdelär.* [Кырык вәзир, б. 159] ‘Шуннан соң

патша үзенең барлык вәзирләрен, бәкләрен һәм башка гади халыкны җыеп, кырык көн бәйрәм иттеләр. *Qylny qyryqya jaryr ide* [Абугалисина, б. 4] ‘Кылны кырыкка ярыр иде’; Meƞ bäla belän tozaqny özde [Кәлилә вә Димнә, б. 11] ‘Мең бәла белән тозакны өзде’; *Gaqylly keše uldyr härber ešne meƞ törle fiker idär* [Кырык вәзир, б. 17], ‘Акыллы кеше һәр эшне мең тапкыр уйлап эшләр...’ и др.

Кыйсса жанры әсәрләрендә тәртип саннары микъдар саннарыннан *-ynčy -enče* кушымчалары ярдәмендә ясалганнар: *ike bala dönjaya kileb berenä Äbuyalisina, ikenčesenâ Äbulxaris dib isem qujdylar* [Әлф-ләйлә..., б. 3] ‘Ике игезәк бала туган, берсенә Әбүгалисина, икенчесенә Әбелхарис дип исем биргәннәр’; *ber jimešne özeb aldy isä urynyna ikenčese üsä toryr* [Кырык вәзир, б. 98] ‘Әгәр җимеш өзелсә, аның урынында башка ....’; *buny öč uyly bulyb, berse Sälim, ikenčese Sälim, öčenčese Ğudär isemendä idelär* [Әлҗилдү хәмисү, б. 186] ‘Аның өч улы бар иде, берсе Сәйлим, икенчесе Сәлйм, өченчесе Җудар исемле иде’; *dürtenče wäzir kileb äjtde* [Кырык вәзир, б. 26] ‘Дүртенче вәзир килде дә әйтте...’; *dürtenče kičä* [Әлҗилдү әс-сәни, б. 21] ‘Дүртенче кичә’; *Bišenče wäzir kileb äjtde* [Кырык вәзир, б. 31] ‘Бишенче вәзир килеп әйтте…’; *šah Junan altynčy käyazne ačqanda ah wah dijüb ğan birde* [Әлҗилдү әс-сәни, б. 37] ‘Шаһ Юнан алтынчы битне ачканда, ыңгырашып җан бирде’; *jidenče šišäne tükmägä kitergändä (...) qulyndan šišä töšeb uwaldy* [Әбүгалисина, б. 112] ‘Җиденче шешәне түгәргә китергәндә, кулыннан шешә төшеп ватылды’; *axyr sikezenče kön čydaj almad*y [Әлҗилдү хәмисү, б. 154] ‘Ахыр чиккә җитеп, сигезенче көн чыдый алмады…’; *ber häjbät güzäl qyz, ajnyƞ undürtenče kičäse kebek jözläre balqyb tora* [Кырык вәзир, б. 45] ‘Бер һәйбәт гүзәл кыз, айның ундүртенче кичәсе кебек йөзләре балкып тора...’.

Тикшерелә торган әсәрләрдә, хәзерге татар әдәби телендәге кебек үк, бүлем саннары *-ar, -är* һәм *-äm* кушымчалары ярдәмендә ясалган. Саннарның башка төрләреннән аермалы буларак, алар артык таралмаган: *bujawčyya häm išäkčegä jözär altyn bireb...* [Әлф-ләйлә..., б. 112] ‘Буяучыга һәм ишәкчегә йөз алтын тәңкә’; *berär bajyyš ber-berenä qaršy utyryr* [Кырык вәзир, б. 61]’Берәр мәче башлы ябалак берберсенә каршы утыралар...’; *här qajsyna berär bajtal baylab* [Әлҗилдү хәмисү, б. 77] ‘Һәрберсенә берәр чабыш аты бәйләп куйганнар...’; *munčadan čyqyan xatynlardan beräm beräm totyb sorady* [Кырык вәзир, б. 9] ‘Мунчадан чыккан һәр хатынны берәм-берәм туктатып сорады...’.

Кыйсса текстларында чама саннары парлы сүзләр белән белдерелгәннәр: *säƞa dürt-biš tin aqča birerlär* [Кырык вәзир, б. 9] ’Сиңа дүрт-биш тиен акча бирерләр’; *biš-alty säyat kitkäč ...* [Әлҗилдү хәмисү, б. 124] ‘Биш-алты сәгать узгач’; *härkön bezdän ber-ikemezne totasyƞ* [Кырык вәзир, б. 50] ‘Син бер-икебезне көн саен тотасың...’; *ber-ike köndän räxmäti xaqya intiqal äjläde* [Әлҗилдү хәмисү, б. 154] ‘Бер-ике көннән соң үлде...’.

Шулай итеп, кыйсса жанрына караган әсәрләрдә микъдар саннары киң таралган. Алар еш кына номинатив һәм сакраль мәгънәләрне белдерәләр. Башка сан төркемчәләре әсәрләрдә сирәк очрыйлар, аларның грамматик формалары һәм мәгънәләре хәзерге татар әдәби телендәге формалардан аерылмыйлар.

**Әдәбият**


*Баранов Х. К.* Арабско-русский словарь. М.: Рус. яз., 1985. 944 с.

*Гилемшин Ф.Ф.* Кысса в системе татарского литературного языка второй половины XIX – начала XX века. Казань: Фэн, 2022. 340 с.

*Жуковская Н.В.* Функционирование числительных в художественном тексте // Вестник Таганрогского государственного педагогического института. 2009. № 2. С. 35–39.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка / под ред. Э.Р. Тенишева и А.В. Дыбо. М.: Наука, 2006. 912 с.

ابو علي سينا قصه سي ديمكله مشهور تخيلات ننك ترجمه سي.عبدالقيوم عبدالناصر اوغلي ننك ترجمات و تصنيفاتنداندر. قزان اونيويرسيتيتي ننك طبع خانه سنده باصمه اولنمشدر ٤٩٨١ نچي يلده. ٢١١ ب. = Әбүгалисина кыйссасы димәклә мәшһүр тәхйиләтнең тәрҗемәсе = Рассказы Абу Гали Сины. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1894. 112 с.

الف ليلة و ليلة،بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي،٧٩٨١ سنهده ٢١٢ ب. = Әлф-ләйлә вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 1. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1897. 212 с.

الجلد الثاني ترجمة الف ليلة و ليلة ايكنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي ٧٩٨١ سنه ده. اوشبو مننك ده بر كيچه كتابى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل قزان اويازى توبان قرصى آولى حاجى شمس الدين حسين اوغليننك ورثه لري خراجاتي ايلان اول مرتبه ٨٩٨١ يلده ٠٦١ ب. = Әлҗилдү әс-сәни тәрҗәмәти әлф-ләйлә вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 2. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1898. 120 с.

الجلد الثالث ترجمة الف ليلة و ليلة. اوچنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ٩٩٨١ سنه ده. ٨١٣ ب. = Әлҗилдү әс-сәлисү тәрҗәмәти әлф ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 3. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1898. 286 с.

الجلد الرابع ترجمة الف ليلة و ليلة. درتنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ٩٩٨١ سنه ده. ٨١٣ ب. = Әлҗилдү рәбигу тәрҗәмәти әлфи ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 4. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1899. 318 б.

الجلد الخامس ترجمة الف ليلة و ليلة. بشنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ٩٩٨١ سنه ده. ٢٩١ ب. = Әлҗилдү хәмисү әлфи ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 5. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1899. 192 с.

الجلد السادس ترجمة الف ليلة و ليلة. الطنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ٩٩٨١ سنه ده. ٢٨٣ب= Әлҗилдү сәдисү әлфи ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 6. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1899. 382 с.

طوطي نامه. عبدالعلام فيض خان اوغلي نك ترجماتندن. مطبعة كريميه، قزانده ٦١٩١. ٥٧١ ب. =
Тутыйнамә =Тутыname, Казань: Матбагаи Кәримия, 1916. 175 б.

كليله و دمنه كتابي. بو كتاب باصمه اولنمشدر قزان اونيويريستيني ننك طبع خانه سنده٩٨٨١ نچی يلده. ٧٨ ب. = Кәлилә вә Димнә китабы= Калила и Димна. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1889. 87 с.

قرق وزير قصه سي، عثمانلی تلندن ترجمه قيلنوب قزانده اوچونچی مرتبه باصلدی. عبدالقيوم عبدالناصر اوغلي ننك ترجماتنداندر. قزانده انيويرسيتيت طبع خانهسنده باصما اولنمشدر ٣٨٨١ سنه ده.٠٦١ ب. =
Кырык вәзир кыйссасы = Рассказы сорока визирей. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1883. 160 с.

***Гыйлемшин Флер Фоат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе фәнни хезмәткәре,*
*«Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге»*
*федераль тикшеренү үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512

*Г.Х. Гыйләҗетдинова*

# XVII ГАСЫР РУС САТИРИК ӘДӘБИЯТЫНДА ТӨРКИ СҮЗЛӘР

Изучение произведений русской демократической сатиры XVII века дает богатый материал не только для воссоздания общественных отношений, многих сторон жизни и быта того времени – суда, церковной службы, отношение к иноземцам и др., но и для исследования вопросов истории русского языка, в том числе места и роли заимствований, в частности тюркского пласта русской лексики исследуемого периода. В результате анализа текстов демократической сатиры XVII века были выявлены разнообразные тематические группы тюркских заимствований для характеристики общественной и частной жизни: наименования товарно-денежных отношений, украшений и драгоценных камней, одежды и ее деталей, головных уборов и обуви, сосудов, сооружений, напитков и др. Основную часть тюркизмов составляют конкретно-предметные номинации. Словообразовательная характеристика производных слов, созданных на базе тюркизмов, свидетельствует о функциональной активности и глубине адаптации заимствований в русском народно-разговорном языке XVII столетия.

**Ключевые слова:** тюркизм, русский язык, заимствование, словарный состав языка.

Russian democratic satire of the XVII century provides rich material not only for the reconstruction of social relations, many aspects of life and everyday life of that time – court, church service, attitude to foreigners, etc., but also for the study of the history of the Russian language, including the place and role of borrowings, in particular the Turkic layer of the Russian vocabulary of the studied period. As a result of the analysis of the texts of the democratic satire of the XVII century various thematic groups of Turkic borrowings were identified to characterize public and private life: names of commodity-money relations, jewelry and precious stones, clothing and its details, hats and shoes, vessels, structures, drinks, etc. The main part of Turkisms consists of specific subject nominations. The word-formation characteristics of the derived words created on the basis of Turkisms indicate the functional activity and depth of adaptation of borrowings in the Russian vernacular of the XVII century.

**Keywords:** Turkism, Russian language, borrowing, vocabulary of the language.

Рус әдәбиятында XVII гасырның икенче яртысында сатира жанры формалаша, ул «беренче тапкыр Рус дәүләте иҗтимагый тормышының күп кенә якларына карата посад халкы арасында дошманлык мөнәсәбәте кискенләшкән чорда барлыкка килә» [Адрианова-Перетц, 1937 с. 187]. «Посад» әдәбияты жанрының характерлы үзенчәлеге – киң иҗтимагый әһәмияткә ия күренешләрне сатирик фаш итү. Әйтик, «Повесть о Ерше Ершовиче» әсәрендә боярлар һәм воеводалар – кызыл балыклар хөкем иткән гадел булмаган суд күрсәтелә, ә «Азбука о голом и небогатом» әсәрендә феодаль Мәскәү өчен хас социаль тигез-

сезлек ачыла. «Калязинская челобитная» һәм «Повесть о попе Савве» әсәрләрендә чиркәүгә йөрергә дә вакыты булмаган комсыз исерек руханилар ачыктан-ачык сурәтләнә. «Служба кабаку» хикәясе хөкүмәт тарафыннан XVI гасыр уртасында аның керемнәре хисабына дәүләт казнасын тулыландыру максаты белән оештырылган эчү йортына – кабакка сатира үрнәге булып тора.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: тикшеренү өчен чыганаклар булып СССР Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы В.П. Адрианова-Перетц бастырып чыгарган XVII гасыр рус сатирик әдәбияты текстлары хезмәт итте [Адрианова-Перетц, 1954].

Карала торган язма истәлекләрдә табылган төрки сүзләр күпчелек очракта конкрет предметларны белдерәләр һәм түбәндәге лексик-тематик төркемнәргә керәләр: кием-салым һәм аның детальләре атамалары (*балахон* «өске кием», *епанча* «япма, плащның бер төре, җиңсез киң күлмәк», *саян* «хатын-кыз киеме, сарафан», *штаны*, *карман*, *калита* «күн сумка, капчык, билбауга тегеп яки каптырып беркетелгән янчык»), баш киемнәре *(клобук, колпак),* аяк киеме *(башмаки, сапоги),* кыйммәтле ташлар һәм бизәнү әйберләре (*бисер*, *жемчуг*, *лал* «якут», алка), тукымалар (*алтабас* «парча»), акча берәмлекләре (*алтын* «алты акчалык тәңкә», *пул* «вак бакыр акча»), савытлар *(бадья, кузов, таз, шайка),* эчемлек һәм ризык атамалары *(брага, буза, калач),* корылмалар (*амбар*, *кабак* «эчү йорты», *каланча*), озынлык үлчәү берәмлекләре *(аршин);* ат үрчетүчелек белән бәйле терминологик лексика (*аргамак* «көнчыгыш нәселле менге ат», *бахмат* «татар нәселле чыдам ат», *лошадь*) һ.б. Кешеләрне эш төре буенча атаучы (*бурлак* «сукбай», *ярыга* «приказның түбән дәрәҗәле хезмәтчесе») һәм югары катлау вәкилләрен *(боярин)* белдерүче номинацияләр аерым төркем тәшкил итә. Табылган төрки сүзләр арасында абстракт лексика шактый сирәк очрый (*изъян* «зыян»). Шуны да билгеләп үтү мөһим: алынмаларның чыганагын билгеләгәндә, Макс Фасмер төзегән рус теленең этимологик сүзлеге материаллары, Р.Г. Әхмәтҗанов, Н.А. Баскаков, Е.К. Бахмутова, К.Р. Галиуллин, Н.К. Дмитриев, Р.А. Юналеева һ.б. ның тарихи-этимологик тикшеренүләре файдаланылды.

Яраклашкан сүзләр исәбенә кертелгән югарыда санап үтелгән төрки сүзләр XVII гасыр рус теле лексик системасына шактый нык кереп урнашканнар. Алар, башлыча, көнкүреш әйберләрен (кием-салым, туклану, йорт кирәк-яраклары) атау, бер өлеше иҗтимагый мөнәсәбәтләрне, җәмгыятьнең социаль катлауларын билгеләү өчен өчен кулланылган. Чагыштыр, мәсәлән, «Сказание о роскошном бытии и веселии» әсәрендә: *и браги, и бузы и квасу столь множество, что и глядеть не хочется* (Сказ. о роск. житии, с. 40); «Повесть о Фоме и Ереме»да: *На Ереме зипун, на Фоме кафтан, На Ереме шапка, на Фоме колпак, Ерема в лаптях, Фома в поршнях, у Еремы мошна, у Фомы калита* (Пов. о Фоме, с. 43). Биредә һәм алга таба да XI–XVII гасырлар рус теле сүзлеге күрсәткечендә (белешмә томында урнаштырылган) кабул ителгән кыскартулар кулланыла [Словарь русского языка...].

Өйрәнелә торган чор рус теле лексик системасы шулай ук төрки сүзләрдән ясалган дериватлар хисабына да баеган, бу исә алынмаларның функциональ активлыгын һәм җайлашуын чагылдыра. XVII гасыр рус демократик сатирасы истәлекләре материаллары күрсәткәнчә, иң гомуми һәм тотрыклы сүз ясалышы төрләренең берсе – төрки лексик элементлар нигезендә сыйфатлар барлыкка килү: *боярин – боярский*, *изюм* «киптерелгән йөзем» – *изюмный*, *казна* «милек, документлар, акча» – *казенный*, *кисея* «үтә күренмәле тукыма» – *кисейный*, *чугун – чугунный*. Например: *изюмные и винные ягоды, и виноград во все стороны лопатами мечут, дороги прочищают* (Сказ. о роск. житии, с. 41), *Павилиок кисейный да занавес мукосейный* (Росп. о прид., с. 102).

Адъектив ясалма сүзләрнең, исемнәр белән янәшә килеп, яңа мәгънәләр алуы кызыклы. Мисал өчен, *сын боярский*, *дети боярские* тезмәләре – «ватан буенча», ягъни кешеләрнең килеп чыгышы буенча йомышлыларның түбән разряды вәкилләрен белдерә: *Знают де ево* [Ерша] *князья и бояря, и дворяня и дети боярские… что он добрый человек, родом сын боярской, Вандышевых* (Ерш Ершович, с.11).

Текстларда субъектив-бәяләү мәгънәләренә (кечерәйтү, түбәнсетү һ.б.) ия дериватларны куллануга да мисаллар табылды: *алтын – алтынец*, *балахон – балахонишко*, *брага – бражка*, *ковш – ковшичек* һ.б. Мәсәлән: *денешку добудь, алтынец съеж, а половиною прикуп твори, а иногда и не етчи спи* (Служба кабаку, с. 11), *Рожь да ячмень в солоды обростим да пива наварим, брашки насидим* (Калязин. чел., с.68). Сирәк кенә *-ник*ка беткән исемнән ясалган лексик берәмлекләр очрый (*брага – бражник* «эчкече»): *И отверзоша врата рая божия, и возрадовася бражник радостию великою* (Сл. о бражнике, с. 107).

Демократик сатира әсәрләрендә төрки сүзләрнең күчерелмә мәгънәдә кулланылуын билгеләп үтәргә кирәк. Мәсәлән, «агач бүкәне, түмәр» мәгънәсенә ия *болван* сүзе: *Взяша же некую часть имения ото отец своих и приидоша на кормчицу, разточиша же имение свое на бога ради… пьянства желая всегда упивати и, яко болван, валятися* (Служба кабаку, с. 63).

Сатирик әсәрләрдә кайбер төрки сүзләр фразеологизмнар составында очрый. Әйтик, *пул* «вак бакыр тәңкә» тюркизмы тотрыклы сүзтезмә берәмлеге буларак кулланыла: (*нет*) *ни пула,* ягъни бөтенләй акча юк. Чагыштыр: *Денег у него в мошне немало, хватился, ан нет, ни пула не стало* (Сказ. о попе Савве, с. 72). В.И. Дальның аңлатмалы сүзлегендә түбәндәге мәкаль теркәлгән: *У Пикула* (*Микула*) *ни пула* [Даль, т. 3, с. 538]. Шунысы игътибарга лаек: (*нет*) *ни пула* фразеологизмы XVII гасырның синонимик тотрыклы тезмәләре арасына кергән: (*нет*) *ни алтына, ни деньги.*

Шулай итеп, демократик сатира эчтәлеге буенча да, XVII гасыр халык-сөйләм теленең сүзлек составы турындагы мәгълүматлар буенча да гадәттән тыш кызыклы. Моннан тыш, тикшерелә торган

сатирик текстлар рус милли теле, аның лексик катламының формалашу процессын торгызу җәһәтеннән дә зур әһәмияткә ия.

Төрки сүзләр рус җәмгыятенең билгеле бер катлаулары телен чагылдырган XVII гасыр рус демократик сатирасы әсәрләрендә шактый актив кулланылган. Рус телендәге төрки алынмаларны өйрәнү телнең лексик системасының катып калмаганлыгын, хәрәкәтчәнлеген раслый. Бер яктан, табылган төрки сүзләрнең бер өлеше актив кулланылыштан төшеп калган һәм тарихи сүзләр һәм архаизмнар рәтенә күчкән (*алтын*, *аршин*, *боярин*, *зипун*, *кафтан*, *пул*, *ярыга* һ.б.). Икенче яктан, кайбер төрки алынмалар, иҗтимагый тормышның һәм көнкүрешнең төрле якларын чагылдырудагы ихтыяҗларны тулысынча канәгатьләндереп, рус теле составында үз позицияләрен саклап калган (*базар*, *изюм*, *казна*, *карась*, *карман*, *сундук* һ.б.).

**Әдәбият**

*Адрианова-Перетц В.П.* Очерки по истории русской сатирической литературы XVII века. М.,Л.: Наука, 1937. 261 с.

*Адрианова-Перетц В.П.* Русская демократическая сатира XVII века. М.; Л.: Наука, 1954. 292 с.

Словарь русского языка XI–XVII вв. Справочный выпуск / Институт русского языка им. В.В. Виноградова РАН. М.: Наука, 2004. 814 с.

*Даль В.И.* Толковый словарь живого великорусского языка: в 4 т. Т. 3. М.: Русский язык – Медиа, 2003. 555 с.

***Гыйләҗетдинова Гөлинә Хәйретдин кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.51.09

***А.Ф. Юсупов***

# XIX ГАСЫР (СУФИЧЫЛЫК) ПОЭЗИЯСЕ ТЕЛЕНДӘ ГАРӘП ҺӘМ ФАРСЫ ЧЫГЫШЛЫ ЯРДӘМЛЕК СҮЗЛӘРНЕҢ ҮЗЛӘШТЕРЕЛЕШЕ

Статья посвящена исследованию проблем грамматического освоения арабских и персидских служебных слов в старотатарском языке XIX века. В ходе анализа раскрываются закономерности функционирования данных лексических единиц в структуре художественных текстов изучаемого периода. В ходе исследования определены механизмы их адаптации; раскрыты особенности освоения арабизмов и фарсизмов на грамматическом уровне. Утверждается, что в языке суфийской поэзии XIX века арабо-персидские предлоги и союзы употребляются, в основном, в стилистических целях, что позволяет поэтам избегать многочисленных повторов одной и той же формы. Установлено, что заимствованные элементы в поэтических текстах используются не только в значениях и функциях, характерных для арабского и персидского языков, но также переходят в другие части речи, т.е. наблюдается явление конверсии.

**Ключевые слова**: старотатарский язык; заимствование; грамматическое освоение; служебные слова; адаптация; послелог; союз.

The article is devoted to the study of the problems of grammatical development of Arabic and Persian function words in the Old Tatar language of the 19th century. The analysis reveals the patterns of functioning of these lexical units in the structure of literary texts of the period under study. In the course of the study the mechanisms of their adaptation were determined; the features of the development of Arabisms and Farsisms at the grammatical level are revealed. It is argued that in the language of Sufi poetry of the 19th century Arabic-Persian prepositions and conjunctions are used mainly for stylistic purposes, which allows poets to avoid numerous repetitions of the same form. It has been established that borrowed elements in poetic texts are used not only in the meanings and functions characteristic of the Arabic and Persian languages but also pass into other parts of speech, i.e. there is a conversion phenomenon.

**Keywords:** Old Tatar language; borrowing; grammatical development; official words; adaptation; postposition; union.

Татар әдәби теле үсешендә XIX гасыр катлаулы чорларның берсе буларак бәяләнә һәм галимнәр тарафыннан «иске татар төркисеннән яңа татар милли әдәби теленә күчеш этабы» [Фасеев, 1982, с. 164] итеп билгеләнә. Икенче яктан, XIX гасыр татар әдәби теле берничә вариантлы, күпкатламлы булуы белән үзенчәлекле. Әлеге чор шигъри тел вариантларының берсе гарәп-фарсы телләренә хас грамматик категорияләренең кулланылуы белән аерылып тора. XIX гасырда иҗат ителгән поэтик әсәрләр телендә «халыкка авыр аңлашыла торган элекке төрки формалар һәм язма сөйләмгә хас поэтик-сурәтләү алымнары зур урын тота, китап теленә таралган гарәп-фарсы сүзләре һәм изафәләре поэтик сөйләмне шактый чуарлый» [Хаков, 2003, б. 158].

Билгеле булганча, «төрки-язма әдәби тел күп еллар дәвамында күпсанлы чит лексик берәмлекләр һәм грамматик элементлар белән баеган» [Юсупов, 2013, с. 214]. Татар теленең сүзлек составында күпсанлы һәм активлыгы белән аерылып торган алынмалар арасында, иң беренче чиратта, гарәп-фарсы теленнән кергән сүзләрне күрсәтергә мөмкин. Галимнәр фикеренчә, «гарәп-фарсы алынмалары XIX гасырда бик күбәеп киткәннәр» [Мәхмүтов, 1966, б. 11]. «Гарәп теленнән кергән сүзләрнең XIX гасыр иске татар теле сүзлек составында ныклап урнашуы гарәп-фарсы элементлары белән чуарланган һәм шул чор язма әдәби тел үсешенә нык йогынты ясаган суфичылык поэзиясенең алга чыгуы тәэсирендә бара» [Юсупов, 2012, с. 100].

Билгеле булганча, әдәби телне баетуда *алынма сүзләр* мөһим роль уйный. XIX гасыр иске татар әдәби теле лексик хәзинәсенең, шул исәптән поэтик әсәрләр лексикасының билгеле бер өлешен гарәп-фарсы алынмалары тәшкил итә. Гарәп-фарсы чыгышлы сүзләрнең күплеге, беренче чиратта, шул чор әдәби мохите һәм классик-традицион поэтик алымнарның дәвам ителеше (рифма, метрика, поэтик сөйләм үзенчәлекләре) белән бәйле. XIX гасыр татар поэзиясе телендә билгеләнгән гарәп-фарсы алынмалары әлеге әсәрләр теленең лексик составында үзәк урынны алып тора. Галимнәр фикеренчә, «XX гасыр башына кадәр татар әдәби теленең сүзлек составында гарәп-фарсы алынмалары 60–65% тәшкил иткәннәр» [Юсупова, 2007, с. 56]. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, XIX гасыр поэтик әсәрләре телендә кулланылган гарәп һәм фарсы алынмалары грамматик яктан *исем, сыйфат, алмашлык, рәвеш, фигыль* һәм *ярдәмче сүз төркемнәренә* карыйлар.

Татар әдәби телендә гарәп һәм фарсы телләреннән алынган күпчелек сүзләр – исемнәр. Шуңа күрә тикшеренүчеләр әлеге төркемгә караган лексиканы анализлауга өстенлек биргәннәр. Татар әдәби телендә гарәп-фарсы чыгышлы исемнәр Ш. Рамазанов, К. Сабиров, М. Мәхмүтов, Җ. Зәйнуллин һ.б. тарафыннан өйрәнелеп, лексик-семантик төркемнәргә бүленәләр. Соңрак, XX–XXI гасырлар чикләрендә, әлеге проблемага аерым диссертацияләр багышлана, аларда татар теленә «кире кайтарылган» лексика [Сиразиев, 2002], татар мәкальәйтемнәрендә гарәп-фарсы алынмаларының кулланылышы [Федорова, 2003] һәм XIX гасыр суфичылык поэзиясе телен өйрәнү барышында гарәп-фарсы элементларының морфологик яссылыкта үзләштерелешенә игътибар ителә. Татар әдәби телендә гарәп һәм фарсы алынмаларының фонетик һәм морфологик үзләштерелешен өйрәнүгә М.И. Мәхмүтов [Мәхмүтов, 1966; Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге, 1993] зур өлеш кертә, галим үзенең хезмәтләрендә гарәп һәм фарсы сүзләренең татар теленә керү процессында грамматик яссылыкта үзгәрүләренә – конверсия күренешләренә дә туктала.

Мәгълүм булганча, гарәп теле типологик яктан (синтетик) флектив телләр төркеменә керә, фарсы теле дә (аналитик) флектив тел булып санала, татар теле исә үзенең грамматик төзелеше ягыннан (аналитик) агглютинатив телләр төркеменә карый. Телләр төзелешендә

типологик үзенчәлекләр – охшаш һәм аермалы яклар – грамматик категорияләрнең белдерелүендә һәм аерым грамматик формаларның кулланылыш үзенчәлекләрендә чагылыш таба. Гарәп һәм фарсы телләреннән алынган грамматик элементларның үзләштерелеше дә үзенчәлекле.

Әлеге мәкалә кысаларында ярдәмче сүз төркемнәре составында кулланыла торган гарәп-фарсы элементлары өйрәнелеп, аларның XIX гасыр суфичылык поэзиясе телендә грамматик үзләштерелешенә игътибар ителәчәк.

Суфичылык әсәрләре телендә ярдәмлек сүз төркемнәреннән бәйлек һәм бәйлек сүзләр, теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр еш кулланыла.

**Бәйлекләр.** Текстларда кулланылган бәйлекләр урын, вакыт, юнәлеш, охшату-чагыштыру, сәбәп, максат кебек мәгънә мөнәсәбәтләрен белдереп килә. Килеп чыгышы ягыннан бәйлекләрне өч төркемгә бүләргә мөмкин: 1) төрки-татар чыгышлы, 2) фарсы чыгышлы, 3) гарәби чыгышлы. Фарсы һәм гарәп телләрендә төрки телләр өчен хас булган бәйләгеч сүзләр – бәйлекләр кулланылмый. Әлеге ярдәмче сүз төркемнәрен килеп чыгышы ягыннан төркемләү барышында, иң беренче чиратта, аларның синтаксик функцияләренә игътибар ителде. Билгеле булганча, төрки телләр өчен характерлы бәйлекләр функциясен гарәп һәм фарсы телләрендә предлоглар, алкушымчалар (префикслар) башкара[1].

Флектив телләргә хас ярдәмлек сүз төркемнәренең төрки телләрдә бәйлек һәм бәйлек сүз буларак кулланылуы мәгълүм. «Төрки телләрдә бәйлекләр үзләре ияркән сүздән соң килгәнгә күрә, аларны русча язылган хезмәтләрдә *послелог* дип атыйлар. Бу – төрки телләрнең үзенчәлеге. Рус телендә функциональ яктан бәйлекләргә охшаш тел чаралары, мәсәлән, *предлоглар* дип атала» [Хисамова, 2006, б. 298]. Алда күрсәтелгәнчә, гарәп телендә дә бәйлек һәм бәйлек сүзләр кулланылмый, ләкин гарәп теле белгечләре алынма гарәп предлогларының татар телендә ярдәмче сүз төркемнәре функциясен башкаруын билгеләп, аларны бәйлекләр дип күрсәтәләр. «Гарәп телендә рус телендәге кебек бәйлекләр бар. Алар татар телендә килеш кушымчалары белән кайбер теркәгечләрнең рольләрен үтиләр. Гарәп бәйлекләре татар телендә мөстәкыйль рәвештә кулланылмыйлар, алар тик аерым сүзләргә генә ябышып кергәннәр» [Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге, 1993, т. 2, б. 844].

**Фарсы чыгышлы бәйлекләр.** XIX гасыр суфичылык әсәрләре теле *фарсы бәйлекләренең* актив кулланылуы белән үзенчәлекле. Алар арасында *та* «кадәр», *ба* «белән», *дәр* «эчендә», *би* «-сыз / -сез», *на* «-сыз / -сез, түгел» чагыштырмача актив. Алынма фарсы бәйлекләре вакыт, катнашлык, корал, урын кебек мәгънә мөнәсәбәтләрен бирә.

[1] Гарәп һәм фарсы телләреннән алынган предлог һәм префикслар татар телендә күбесенчә бәйлек һәм бәйлек сүзләр вазифасында кулланылганга күрә, әлеге терминнар бәйлек дип бирелде.

Фарсы телендә *та* бәйлеге күпмәгънәле, ул фарсы телендә эш-хәрәкәтнең таралыш чиген, вакыт ягыннан чиген һәм процессның нәрсәгә булса да бәйлелеген белдереп килә [Рубинчик, 2001, с. 317]. XIX гасыр суфичылык поэзиясе телендә *та* «кадәр» бәйлегенең кулланылыш даирәсе чикләнгән: эш-хәрәкәтнең урын яки вакыт чиген белдергәндә кулланыла: bändin razyj ulγyl ta äbäd [А., 1907, б. 415] *миннән мәңге разый бул*.

Галимнәр *ба* «белән, бергә, буенча» бәйлегенең фарсы телендә күпмәгънәле булуын күрсәтәләр [Рубинчик, 2001, с. 318], әмма *ба* бәйлегенең XIX гасыр поэзиясе телендә «белән» мәгънәсендә генә килүен билгеләргә кирәк. *Ба* «белән» корал яки катнашлык нисбәтен белдерүдә катнаша: ba safa ilä wiräsän canyηy [ШЗШ, 82] *шатлык белән җаныңны бирәсең*.

Тикшерелә торган шигъри текстларда *дәр* «эчендә -да /-дә» бәйлегенең кулланылышы да фарсы теле белән чагыштырганда активлыгы ягыннан чикләнгән күләмдә. *Дәр* бәйлеге фарсы телендә урын, вакыт, эш-хәрәкәтнең үтәлеш рәвешен, микъдар саннары белән килгәндә микъдар мөнәсәбәтен һ.б. мәгънә төсмерләрен белдереп килсә дә [Рубинчик, 2001, с. 316], тикшерелә торган шигъри текстларда бары тик урын төшенчәсен бирү өчен генә кулланыла: där xaqyjqät äxiläreη bonlar hämin [ШЗШ, 125] *хакыйкатьтә* (хакыйкать баскычында – *суфичылыкның яки мистик юлның соңгы этабында*) *болар гына синең туганнарың (абыйларың),* gärčä där xäšrät ulyrsäm, zikereηe äjlä, nädim [ТК, 43а] *гәрчә хәсрәт эчендә булсам да, зикереңне әйт, юлчы* һ.б.

*би* «-сыз / -сез» һәм *на* «-сыз / -сез, түгел» бәйлекләре фарсы телендә кемнең яки нәрсәнең дә булса булмавын белдерү өчен кулланыла [Рубинчик, 2001, с. 319]. Тикшерелә торган текстларда да *би* «-сыз / -сез» һәм *на* «-сыз / -сез, түгел» предмет яки күренешнең юклыгын аңлата. Алар ярдәмендә сыйфатлар актив ясала: tuγmady härgäz anadan bän kebi bičara qol [А., 1907, б. 418] *минем кебек бичара кол беркайчан да тумады,* bi iman kitmäkneη axyr afäte [ТХӘБС, 1889, б. 2] *имансыз китүнең (үлүнең) афәте ахырда*, raxmätendin naömid šajtan toryr [ШЗШ, 133] *рәхмәтеңнән өмет өзгән (өметсез) шайтандыр* һ.б. Билгеле булганча, әлеге бәйлекләр ярдәмендә ясалган алынма сыйфатлар хәзерге татар әдәби телендә дә актив.

**Гарәп бәйлекләре.** Тикшерелә торган әсәрләрдә *фи* «эчендә, -да / -дә», *би* «белән», *кәй* «кебек, төсле, сыман», *гайре* «тыш, башка, бүтән», *бәгъдә* «соң, аннан соң, аннары» кебек *гарәп бәйлекләре* очрый. Алар урын, катнашлык, охшату-чагыштыру, вакыт, урын кебек мәгънә төсмерләрен белдерүдә катнашалар.

Гарәп телендә *фи* «эчендә, -да / -дә» бәйлеге «нәрсәнең дә булса, урынын яки вакытны» [Гранде, 1963, с. 404–405] төрле мәгънә төсмерләрендә ачыклап килә. Тикшерелә торган текстларда *фи* бәйлегенең мәгънәсе конкретлаша һәм ул урын нисбәтенә бәйле рәвештә кулланыла: bel: fäna fi allahi [ШЗШ, 85] *бел: юкка чыгу (эреп югалу) Аллаһта*.

Гарәп теле белгечләре *би* «белән» бәйлегенең үзе ияргән торган сүзгә кушылып язылуын һәм күпмәгънәле булуын билгеләп, аның «эш-хәрәкәтне башкару коралын, катнашлык мөнәсәбәтен, эшнең башкарылу рәвешен, эш-хәрәкәтнең үтәлү вакытын, урынын, сәбәбен һ.б.» [Гранде, 1963, с. 394–395] мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерүен күрсәтәләр. XIX гасыр суфичылык поэзиясе телендә *би* «белән» бәйлегенең кулланылыш даирәсе чикле һәм ул, нигездә, катнашлык нисбәтен яки эш-хәрәкәтне башкара торган коралны белдерә: bikülli xaqγa jöz totyb hämišä [ШЗШ, 85] *һәрвакыт хакка йөз тотып.*

Гарәп телендәге *кәй* «кебек, төсле, сыман» бәйлеге *кебек / кеби* төрки-татар бәйлегенең грамматик синонимы булып тора һәм охшату-чагыштыру мөнәсәбәтен бирү өчен кулланыла: γäciz ašöftäder zar zäγifem käj näxif [ШЗШ, 91] *зәгыйфьләрем ябык (авыру) кебек гаҗиз, борчулыдыр.*

*Гайре* «гайре» сүзе гарәп телендә инкяр кисәкчәсе [Гранде, 1963, с. 415–416] булуга карамастан, тикшерелә торган чор шигърияте телендә ул *тыш, башка* бәйлек сүзләре ролендә йөри торган ярдәмче исемнәрнең синонимы буларак кулланыла. Аерым алганда, *гайре* чыгыш килешендәге сүзләр янында килеп, билгеле бер төркемгә кермәгән зат, предмет яисә күренешне белдерә: ta sane belam ki, sändän γajre jarym qalmady [ШЗШ, 102] *сине генә беләм, синнән гайре ярым юк.*

Гарәп телендә *бәгъдә* бәйлеге эш-хәрәкәткә кадәр яки аннан соң булган вакыт аралыгын белдерә [Гранде, 1963, с. 412]. XIX гасыр суфи шагыйрьләр әсәрләре телендә дә *бәгъдә* «соң, аннан соң, аннары» вакыт нисбәтенә бәйле рәвештә кулланыла: bäγdä fillah xäjre xafizan ajäten uqydy [ТХӘБС, 1889, б. 29] *соңыннан Хәйре Хафисан аятен укыды.*

Шул рәвешле, суфичылык әсәрләрендә төрки телләргә хас бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән янәшәдә гарәп-фарсы чыгышлы бәйлекләрнең еш кулланылуы күзәтелә. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: гарәп һәм фарсы телләрендә без тикшергән бәйлекләрнең күбесе күпмәгънәле, алар берничә мәгънә мөнәсәбәтен белдерсәләр, XIX гасыр суфичылык поэзиясе телендә аларның мәгънәләре тарая һәм конкретлаша, гадәттә, алар бер яки ике мәгънә мөнәсәбәтен белдереп киләләр.

Гарәп, фарсы һәм татар телләренең типологик үзенчәлекләре, аерым алганда, татар теле өчен предлог һәм префиксларның ят булуы әлеге элементларның грамматик үзләштерелешендә дә чагылыш тапкан: фарсы чыгышлы *би* «-сыз / -сез» һәм *на* «-сыз / -сез, түгел» префикслары татар телендә сүз ясагыч формалар булып киткәннәр һәм әлеге алкушымчалар белән ясалган сүзләр хәзерге татар әдәби телендә дә актив лексиканы тәшкил итәләр; гарәп теленнән кергән *гайре, бәгъдә* сүзләре хәзерге татар телендә фонетик үзгәрешләр кичереп, пассив лексика составында һәм аерым татар сөйләшләрендә генә кулланылалар. XIX гасыр суфичылык поэзиясе телендә кулланылган гарәби һәм фарсы чыгышлы калган бәйлек һәм алкушымчалар хәзерге татар әдәби теле грамматик системасы өчен ят күренешләр булып исәпләнәләр.

**Теркәгечләр.** Суфичылык әсәрләрендә, татар әдәби телендәге кебек үк, теркәгечләр аерым җөмләләрне һәм җөмлә кисәкләрен бәйләү чарасы буларак кулланыла. Синтаксик функцияләре ягыннан алар тезүче һәм ияртүче теркәгечләргә аерыла. Тикшерелә торган шигъри текстларда кулланылган теркәгечләрне килеп чыгышлары ягыннан 3 төркемгә бүләргә мөмкин: 1) төрки-татар, 2) фарсы, 3) гарәби чыгышлы.

**Фарсы чыгышлы теркәгечләр** тикшерелә торган әсәрләр телендә киң кулланыла. Тектларда алар еш кына төрки-татар чыгышлы теркәгечләрне алыштырып килә. Төзелеше ягыннан аларны түбәндәге төркемнәргә аерырга мөмкин:

а) гади: *ки* «ки», *чөн* «чөнки», *әгәр (гәр)* «әгәр», *һәм* «һәм», *вәли* «әмма, ләкин»;

ә) кушма: *чөнки* «чөнки» *(чөн + ки), бәлки* «бәлки» (каршы куючы *бәл* «әмма, ә» теркәгече + *ки* дән тора), *әгәрчә (гәрчә)* «гәрчә» (*әгәр (гәр)* + *че* «нәрсә» алмашлыгы).

Фарсы чыгышлы теркәгечләр мәгънәләре ягыннан төрле: җыю, каршы кую, бүлү, сәбәп, шарт, кире шарт, аныклау һ.б. мөнәсәбәтләрне белдереп киләләр.

*Һәм* тезүче теркәгече текстларда еш кулланыла һәм берничә функцияне үти:

1. Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен бәйли: räsülenä häzaran dürüdlär häm salawatlar [ТК, 39б] *аның рәсүленә меңнәрчә мактаулар һәм салаватлар.*

2. Күренешләрнең бер-бер артлы килүен күрсәтә: šäriүät häm tariqat häm xaqyjqät – bu öčkä buldy Islam dine qyjsmät [ОРРК, 685т, 4а] *шәригать һәм тарикать һәм хакыйкать – бу өч өлешкә ислам дине бүленде.*

3. Аерым очракларда *-да / -дә* кисәкчәсе урынында килүе күзәтелә: ul qapudan kilä häm ähle gäda [ТХӘБС, 1889, б. 3] *ул капкадан ярлылар да үтәләр.*

*Бәлки* һәм *вәли* «әмма, ләкин» каршы куючы теркәгечләре бер предмет, күренеш яки эш-хәрәкәтнең икенчесенә каршылыгын белдереп килә:

бәлки: bälki däүwa ähleder – xar-zälil [ШЗШ, 116] *бәлки дәгъва итүче – түбән кешедер*;

вәли: äjü süz gärčä canlarүa үazadyr, wäli küb süzlämäklekdä xätär war [ШЗШ, 108] *изге сүз гәрчә җаннарга азык булса да, әмма күп сөйләүдә хәтәр бар.*

Мәгълүм булганча, ияртүче теркәгечләр иярчен җөмләне баш җөмләгә ияртеп киләләр һәм иярчен кушма җөмләнең компонентлары арасында төрле синтаксик мөнәсәбәтләрне оештыруда катнашалар. Фарсы телендә «барлык ияртүче теркәгечләр дә бер мәгънәле түгел, аларның кайберләре ике яки аннан күбрәк мәгънә мөнәсәбәтен белдереп, төрле типтагы иярчен җөмләләрне баш җөмләгә бәйләргә сәләтле» [Рубинчик, 2001, с. 335]. Шуны билгеләп үтәргә кирәк: XIX гасыр

суфичылык әсәрләре телендә фарсы чыгышлы теркәгечләр, гадәттә, бер мәгънә мөнәсәбәтен белдереп киләләр, ягъни татар телендә грамматик яктан үзләштерү процессында аларның мәгънәләре конкретлаша һәм тарая.

*Чөнки* ияртүче теркәгече иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен хезмәт итә һәм сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен белдереп килә: cönki sadryna jasyldy γyjšqy xat [ШЗШ, 82] *чөнки йөрәгенә гыйшык хаты язылды*, čönki bän bu cähanda bändälär bi čarasy [ШЗШ, 87] *чөнки мин – бу җиһанда бәндәләр бичарасы* һ.б. Моннан тыш суфичылык әсәрләре телендә әлеге теркәгечнең кыскартылган *чөн* варианты да еш очрый: čön susamyšmyn qanyma [А., 1907: 415] *чөнки сусадым каныма* һ.б.

*Әгәр* ияртүче теркәгече һәм аның кыскартылган *гәр* «әгәр» варианты иярчен шарт җөмләне баш җөмләгә бәйләүче чара булып хезмәт итә. Текстларда кыскартылган вариантның еш кулланылуы күзәтелә: ägär zindanda torsam da, zarar juq [ТК, 41а] *әгәр зинданда торсам да, зарар юк*, ägär sändin γyjnäjät ulmasa kem ruzy qyjämätdä [ӨКК, 1884, б. 112] *әгәр Синнән ярдәм булмаса, Кыямәт көнендә*, gär delärsän kem, dökänmäz däülätä irešäsän [ШЗШ, 81] *әгәр теләсәң, бетмәс дәүләткә ирешәсең* һ.б.

*Әгәрчә* һәм *гәрчә* «гәрчә» ияртүче теркәгечләре иярчен кире шарт җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла: ägärčä jazyqym čuq, azyγym juq [ШЗШ, 96] *гәрчә языгым күп, азыгым юк*, gärčä käfer äledä bän [ТК, 43а] *гәрчә кяфер кулында мин* һ.б.

Ияртүче *ки* теркәгече төрле иярчен җөмләләрне баш җөмләгә бәйли һәм эш-хәрәкәтнең төп мәгънәсен ачыклый: šul jaŋa kitdem ki, andan kilmešem [ШЗШ, 107] *шул якка киттем ки, аннан киләм.*

**Гарәби чыгышлы теркәгечләр.** Тикшерелә торган шигъри текстлар, төрки-татар һәм фарсы чыгышлы теркәгечләрдән тыш, гарәби чыгышлы теркәгечләрнең күп кулланылуы белән аерылып тора һәм алар синтетик чара буларак җөмлә кисәкләрен, кушма җөмлә компонентларын бәйләүгә хезмәт итә. Төзелешләре ягыннан алар түбәндәге төркемнәргә аерыла:

гади: *вә* «һәм», *фа* «һәм», *бәс* «бәс, шулай булгач, димәк, нәтиҗәдә», *иллә* «әмма, тик, ә инде», *ягъни* «ягъни»;

тезмә: *вә ләкин* «вә ләкин, ләкин, тик, бары» (тезүче *вә* «һәм» теркәгече + каршы куючы *ләкин* «ләкин» теркәгече), *вә иллә* «юкса, югыйсә, башкача булса» (тезүче *вә* «һәм» + каршы куючы *иллә* «әмма, тик, ә инде» теркәгечләре).

Гарәби чыгышлы теркәгечләр җыю, каршы кую, кире кагу, ачыклау, аныклау, шарт һ.б. мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерәләр.

*Вә* «һәм» теркәгече, фарсы чыгышлы *һәм* теркәгеченең грамматик синонимы буларак, җөмләнең тиңдәш кисәкләрен бәйли: xezmät äjlär irde pirä sabax wä šam [ТХӘБС, 1889, б. 23] *пирга* (пир – *дәрвишлек юлын чыгарган кеше, тарикатьтә иң югары баскычта торучы*) *хезмәт итә иде иртә һәм кич*, baqar juq jar wä juldašy, γariblektä anyŋ

iše [ТК, 37б] *күрә: яры һәм юлдашы юк, гариблектә (туган-үскән иленнән аерылып читтә яшәү – дәрвишлек) аның эше* һ.б.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: гарәп телендә *вә* «һәм» кисәкчә булып санала һәм ул җыючы теркәгеч вазифасында килеп, җөмләнең тиңдәш кисәкләрен яки тезмә кушма составындагы гади җөмләләрне үзара бәйләргә мөмкин [Гранде, 1963, с. 399-400]. Тикшерелә торган шигъри текстларда *вә* кисәкчә буларак та кулланыла: кайбер очракларда *вә* теркәгече кабатланып, көчәйтү төсмерен өсти һәм *-да / -дә* кисәкчәсе мәгънәсен ала. Мәсәлән: anyŋ qasdy imanyŋda wä canyŋda wä qanyŋda [ШЗШ, 81] *аның начарлыгы иманында һәм җанында, һәм канында.*

*Фа* «һәм» җыючы теркәгече гарәп телендә шулай ук кисәкчә булып санала һәм берничә мәгънә мөнәсәбәтен белдереп килә [Гранде, 1963, с. 396–397]. XIX гасыр татар суфичылык поэзиясе телендә исә, *фа* «һәм» тезүче теркәгеч функциясендә генә кулланылып, гарәп телендәге кебек үк, ике җөмләнең бер-бер артлы бәйләнешен белдерә. Мәсәлән: fa šökru niүmäti allahi, – dide xaq [ШЗШ, 125] *Аллаһның нигъмәтенә шөкер итегез, – диде Хак.*

*Вә ләкин* «вә ләкин, ләкин, тик, бары» теркәгече күренеш, эш-хәрәкәт яки предметны икенчесенә каршы куя: wäläkin kändü sačymlä möqajjät ulurym [ТХӘБС, 1889, б. 6] *вә ләкин үз чәчем белән бәйләнгән булырмын*, xaqyjqät ählenеŋ äsrare čuqdyr, wäläkin äjlijälär any äzmar [ШЗШ, 108] *хакыйкать әһленең (мистик юлның соңгы баскычында торучы суфиларның) серләре күп, ләкин изгеләр аларны яшерер* һ.б.

*Иллә* «әмма, тик, ә инде» теркәгече гарәп теле грамматикаларында чикләүче кисәкчә функциясендә килеп, берничә мәгънә мөнәсәбәтен белдерә [Гранде, 1963, с. 416]. Тикшеренүләр шуны күрсәтә: татар телендә исә ул бер мәгънә төсмерендә генә үзләштерелә һәм кемнең яисә нәрсәнең дә булса башкарыла торган эш-хәрәкәттән төшеп калуын белдерә: gärčä rah räüšan doryr, illä säfär wäxšätleder [ШЗШ, 118] *гәрчә юл йөрү якты булса да, әмма сәфәр хәтәрле.*

*Вә иллә* «юкса, югыйсә, башкача булса» теркәгече гарәп теленә хас төстә альтернатив шартны белдерә һәм алдагы катгый шартны кире кага [Гранде, 1963, с. 427]. Мәсәлән: äsär kilde bäŋa göl quxusyndan, wä illä tufraүam bän ta äzäldan [ШЗШ, 107] *әсәрләндем гөл исеннән, югыйсә туфракмын мин мәңгегә.*

Аерым очракларда авторлар каршы куючы теркәгеч функциясендә гарәп теленнән кергән *бәс* «бәс, шулай булгач, димәк, нәтиҗәдә» сүзенә мөрәҗәгать итә: bäs qory däүwalara aldanmaŋyz [ШЗШ, 117] *шулай булгач, коры дәгъваларга алданмагыз* һ.б.

Гарәп телендә *ягъни* сүзе үзенең формасы ягыннан III зат, берлек сан, мөзәккәр (ир-ат җенесендәге) хәзерге заман фигыле булып тора һәм *белдерә* дип тәрҗемә ителә. Татар әдәби телендә әлеге фигыль, үзенең төп лексик мәгънәсен югалтып, теркәгечкә әйләнгән. *Ягъни* теркәгече баш һәм иярчен җөмлә кисәкләре арасында ачыклау мөнәсәбәтен белдерә, ягъни күренеш яки эш-хәрәкәтнең асылын

күрсәтү өчен хезмәт итә: jäɣni Xalilneŋ qapusynda ber är šäj-I Allah estäjü kiler [ТХӘБС, 1889, б. 3] *ягъни Хәлилнең (Ибраһим пәйгамбәр) капусына (суфилар яши торак урын) бер кеше хәер сорап килер*, bui canandan äsär kilde bäŋa, jäɣni ul ildän xäbär kilde bäŋa [ШЗШ, 82] *сөйгән ярдан әсәр килде миңа, ягъни ул илдән хәбәр килде миңа.*

Шул рәвешле, суфичылык әсәрләре телендә теркәгечләрнең күбесенчә гарәп-фарсы һәм төрки-татар катламнарыннан торуы күренә. Фарсы һәм гарәп телләрендә күпчелек теркәгечләр һәм теркәгеч функциясендә кулланылган бәйләүче чаралар берничә мәгънә төсмерен белдереп килсәләр дә, аларның татар телендә грамматик үзләштерелеш дәрәҗәсе төрле: *һәм, вә* җыючы теркәгечләре берничә мәгънә төсмерендә кулланылалар, калган гарәп-фарсы чыгышлы теркәгечләрнең кулланылыш даирәсе һәм функциясе тарая, конкретлаша. Икенчедән, XIX гасыр суфичылык поэзиясе телендә теркәлгән гарәп-фарсы теркәгечләренең күпчелеге хәзерге татар әдәби телендә дә актив лексиканы тәшкил итәләр, әмма *вә, вәли, фа, иллә, вә иллә, вә ләкин* кебек теркәгечләр хәзерге татар телендә пассив. Өченчедән, гарәп һәм фарсы телләрендә теркәгеч функциясендә кулланылмаган бәйләүче чаралар да (кисәкчәләр, аерым мөстәкыйль сүзләр), татар суфичылык поэзиясе телендә грамматик үзләштерелү процессында теркәгеч вазифасын башкаралар.

Шулай итеп, XIX гасыр татар суфичылык поэзиясе телендә иске татар һәм Көнчыгыш телләренең диалектик бәйләнеше морфологик яссылыкта ачык чагыла, аерым алганда, бәйләүче сүз төркемнәрендә төрки-татар (угыз-кыпчак) һәм гарәп-фарсы катламнары аерыла. Генетик яссылыкта төрле телләргә караган бәйләүче чаралар (бәйлек, алкушымча, теркәгечләрнең) матур әдәбият телендә, бер әсәр чикләрендә бергә кулланыла. Гарәп-фарсы элементлары төрки-татар грамматик формалары белән параллель кулланылып, стилистик төрлелек һәм грамматик вариантлылык тудыра, аерым формаларны еш кабатлаулардан коткара.

**Әдәбият**

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре. 1 т. / төз. М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин. Казан: Иман, 1993. 448 б.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре. 2 т. / төз. М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин. Казан: Иман, 1993. Б. 449–854.

*Гранде Б.М.* Курс арабской грамматики в сравнительно-историческом освещении. М.: Изд-во вост. лит., 1963. 594 с.

*Мәхмүтов М.И.* Татар әдәби телендә гарәп алынмаларының фонетик һәм грамматик үзләштерелүе: Филол. фән. канд. ... дис. Казан, 1966. 334 б.

*Рубинчик Ю.А.* Грамматика современного персидского литературного языка. М.: Изд. фирма «Восточная литература» РАН, 2001. 600 с.

*Сиразиев И.И.* Арабский пласт лексики современного татарского литературного языка: дис. … канд. филол. наук / Казан. гос. ун-та. Казань, 2002. 177 с.

*Фасеев Ф.С.* Старотатарская деловая письменность XVIII в. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 171 с.

*Федорова Э.Н.* Арабские и персидские заимствования в татарских народных пословицах (по трехтомнику сборнику Н. Исанбета «Татар халык мәкальләре»): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2003. 25 с.

*Хаков В.Х.* Тел – тарих көзгесе: Татар әдәби теленең үсеш тарихыннан. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 295 б.

*Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2006. 334 б.

*Юсупов А.Ф.* Многовариативность старотатарского языка XIX века // Филология и культура. 2012. № 3 (29). С. 99–103.

*Юсупов А.Ф.* Заимствованные имена прилагательные в языке татарских суфийских произведений // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2013. № 10 (28). С. 214–217.

*Юсупова А.Ш.* Арабо-персидские заимствования в двуязычных словарях татарского языка XIX века: к проблеме языковых контактов // Ученые записки Казанского университета. Т. 149. Кн. 4. Серия Гуманитарные науки, 2007. С. 5–64.

**Чыганаклар**

А. – *Фәхретдин Р.* Асар. 13 җөзьә. 2 нче җилд / Р. Фәхретдин. Оренбург, 1907. Б. 343-422.

ОРРК – Чокрый Гали. Җыентык («Фәйзе Гари») / Күчерүчеләр Мөхәммәтгариф Чокрый һәм Гарифулла Чокрый // КФУның Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. 685 т. 13 кгз. = Отдел рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского Казанского федерального университета. 685т. 13 л.

ӨКК – Өмми Камал китабы. Казан: Ун-т табгыханәсе, 1884. 113 б.

ТК – Тубылый кулъязмасы // Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИнең Язма мирас үзәге. Ф. 39. Т. 1. Б. 6058. 209 кгз. = Рукопись Тубыли // Центр письменного наследия ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Ф. 39. Оп. 1. Ед. хр. 6058. 209 л.

ТХӘБС – Тәрҗемәи Хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әс-Сәгыйди. Казан: Казан ун-ның табгыханәсе, 1889. 34 б.

ШЗШ – Шәмсетдин Зәки шигырьләре // Башкортстан Фәннәр академиясенең Уфа тарих, тел һәм әдәбият институты гыйльми архивы Ф. 3. Т. 63. Б. 47. 178 кгз. = Научный архив Института истории, языка и литературы Академии наук Республики Башкортостан. Ф. 3. Оп. 63. Ед. хр. 47. 178 л.

***Юсупов Айрат Фаик улы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты*
*Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты*
*Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф*
*Югары мәктәбенең татар теле белеме кафедрасы доценты*

УДК 81’33, 81.512.1

***Р.А. Гыйльмуллин,***
***Б.Э. Хәкимов,***
***В.Р. Гафарова***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ ТЕКСТЛАРДА ИСЕМЛӘНГӘН ОБЪЕКТЛАРНЫ ТАМГАЛАУ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА

Статья посвящена проблеме разметки именованных сущностей в текстах на татарском языке. Для татарского языка задача распознавания таких объектов в рамках автоматической обработки естественного языка находится на начальном этапе, по данному вопросу опубликовано несколько статей и экспериментальных моделей. Авторами создан размеченный корпус именованных сущностей на татарском языке, состоящий из предложений, отобранных случайным образом из различных текстов. Для корпуса была принята классификация, состоящая из 11 типов сущностей, разметка осуществлена без вложенных и пересекающихся объектов. Размеченный корпус может быть использован для машинного обучения и тестирования моделей распознавания именованных сущностей в текстах на татарском языке.

**Ключевые слова:** татарский язык, автоматическая обработка естественного языка, именованная сущность, ономастика, разметка.

This paper discusses the problem of named entity annotation in Tatar texts. For the Tatar language, the named entity recognition task is at an early stage, with a few articles and experimental models published. A tagged corpus of named entities in the Tatar language was developed. It contains sentences randomly selected from various sources. A classification of 11 named entity types was adopted for the corpus, while nested and intersecting entities have not been annotated. The Tatar named entity corpus can be used for machine learning and testing models for named entity recognition in Tatar texts.

**Keywords:** tatar language, natural language processing, named entity, onomastics, linguistic annotation.

Исемләнгән объектларны тану (рус. «распознавание именованных сущностей», инг. «named entity recognition») – табигый телләрне автомат рәвештә эшкәртү (инг. «natural language processing») өлкәсендәге стандарт биремнәрнең берсе. Хәзерге вакытта ул гадәттә нейрон челтәрләренә нигезләнгән махсус модельләр ярдәмендә башкарыла. Татар теле өчен бу мәсьәлә әлегә башлангыч дәрәҗәдә генә хәл ителгән. Кайбер алымнар һәм эксперименталь модельләр аз санлы фәнни мәкаләләрдә тасвирлана [Nevzorova et al, 2018] яки махсус репозиторийларда тәкъдим ителә [https://github.com/ksemiya/NER_in_Tatar].

Инглиз телендәге *«named entity»* оригиналь термины рус теленә *«именованная сущность»,* төрек теленә «adlandırılmış varlık» яки *«varlık ismi»* [Özger, Diri, 2016], казакъ теленә *«аталған нысан»*

*(«нысан» – «объект»)* дип тәрҗемә ителә. Шуларны исәпкә алып, әлеге мәкаләдә *«исемләнгән объект»* термины тәкъдим ителә.

Исемләнгән объект – гамәли мәгълүмат эшкәртү белән бәйле төшенчә. Тел белемендә ул күбесенчә ялгызлык исемнәргә туры килә, әмма реаль чынбарлыктагы конкрет бер объектка (зат, шәхес, географик урын, оешма һ.б.) нисбәт ителергә тиеш була [Nouvel et al, 2016]. Шул күзлектән караганда, *Рәис – гарәп теленнән кергән исем* һәм *Биектау исемле авыллар республикабызда берничә* кебек җөмләләрдә ялгызлык исемнәр булса да, исемләнгән объектлар юк булып чыга, чөнки конкрет референт аталмый.

Текстларны автоматик эшкәртү өлкәсендә гомум кабул ителгәнчә, текстларда фактларны автомат рәвештә ачыклау нәтиҗәлерәк булсын өчен, ялгызлык исемнәр белән белдерелгәннәрдән тыш, дата, вакыт, акча һәм башка үлчәү берәмлекләрен эченә алган микъдари гыйбарәләр дә исемләнгән объектлар буларак карала [Nadeau, 2007]. Шулай итеп, андый объектларны белдерә торган тел чараларына антропонимнар, топонимнар, эргонимнар һәм башка ялгызлык исемнәр, шулай ук даталарны, вакытны, төрле валюталарда акча күләмен, һәртөрле физик зурлыкларны һ.б. аңлата торган санлы сүзтезмәләр керә.

Исемләнгән объектларны тану модельләрен булдыру һәм өйрәтү өчен тиешле тел берәмлекләре тамгаланган мәгълүмат тупланмалары (корпуслар) кулланыла. Шул максаттан, ТР Фәннәр академиясенең Гамәли семиотика институтында татар телендәге текстларда исемләнгән объектларны тану биремнәрен башкару өчен, 5800 җөмләдән торган махсус тамгаланган корпус төзелде. Аерым җөмләләр төрле чыганаклардан алынды, автоматик ысул белән баш хәрефтән язылган сүзләр очраган мисаллар сайланды. Корпусны тамгалау өчен Label инструментарие базасында А.Ф. Хөсәенов тарафыннан эшләгән махсус веб-интерфейс файдаланылды [https://labelstud.io/].

Куелган максатларга бәйле рәвештә исемләнгән объектларның төрле классификацияләре кулланылырга мөмкин, аерып чыгарыла торган категорияләр саны исә өч-дүрттән алып берничә дистәгә җитә ала [https://grobid-ner.readthedocs.io/en/latest/class-and-senses/]. Аерым объектларның бер җөмләдә бер-берсенә мөнәсәбәтенә карап, төрле тамгалау ысуллары гамәлгә ашырыла. Мәсәлән, Dialogue Evaluation бәйгесе өчен OpenCorpora платформасында тәкъдим ителгәнчә, берничә дәрәҗәле тамгалау ысулы белән эшләп була [Starostin, A. et al, 2016]. Моннан тыш, бер-берсе эченә кергән һәм чикләре кисешкән объектларны исәпкә алмыйча, һәр берәмлеккә бер генә категорияне билгеләүдән гыйбарәт булган ысул да бар [Можарова, Лукашевич, 2016]. Шулай ук, исемләнгән объектларны тамгалаганда телләрнең спецификасын һәм милли-мәдәни үзенчәлекләрне дә игътибарга алу мөһим.

Әзерләнгән корпуста исемләнгән объектлар 11 төргә бүлеп, кисешүләрсез һәм бер-берсе эченә кертелмичә тамгаланды. Корпуста түбәндәге шартлы билгеләр кулланыла: PERSON – кешеләр белән бәйле ялгызлык исемнәре; TITLE – вазифалар, мактаулы исемнәр,

титуллар һ.б.; ORGANIZATION – оешмалар, учреждениеләр һ.б.; LOCATION – географик урыннар; DATE – даталар; TIME – вакыт аралыклары; MONEY – акча берәмлекләре; QUANTITY – теләсә нинди үлчәнешләр (үлчәү берәмлекләре белән бирелгән саннар); CARDINAL – башка төр саннар; FACILITY – аерым корылмалар һәм төзелеш объектлары; OTHER – башка төрдәге объектлар.

1. **PERSON** категориясенә реаль яки уйдырма кеше исемнәре, фамилияләр, ата исемнәре (шул исәптән кызы, улы / углы компонентлары белән ясалган очраклар), кушаматлар, әдәби әсәрләрдәге персонаж исемнәре кертелде.

Татар теленең үзенчәлеге буларак, бу категориядә кешене атый торган ялгызлык исемнәре белән берлектә туганлык атамалары һәм традицион мөрәҗәгать итү сүзләре дә тамгаланды: *апа, абый, түти, дәдәй, ага, бабай, әби, карчык, карт, әфәнде, ханым, туташ, хәзрәт.* Мәсәлән: ***Нурихан ага Фәттахның (PERSON)*** *хатыны* ***Руфина апа (PERSON)*** *да чакырып шалтыраткач, кызыксынуым тагын да көчәйде.*

Хәзерге вакытта продуктив булмаган, әмма тарихи, дини һәм башка текстларда очрый торган, гарәп үрнәге буенча *бинт, бинте, ибн, ибне, бин* компонентлары белән ясалган модельләр дә әлеге категориядә билгеләп үтелде: *Шиһабетдин бине Баһаветдин, Мөхлисә бинт Габделгалләм.* Мәсәлән: ***Галимҗан Әл-Баруди (PERSON) (Галимҗан бине Мөхәммәдҗан бине Бинеямин бине Гали бине Колмөхәммәд) (PERSON)*** *1857 елның 2 февралендә (DATE) Казан губернасы (LOCATION) Казан өязе (LOCATION) Чуашиле авылында (LOCATION) туган.*

Текстта бер төркем кешеләр уртак исем белән бәйләнгән очракларда бөтен фрагмент бер элемент буларак билгеләнде: ***Дилия белән Зилә Нурмөхәммәтовалар (PERSON)****.*

Оешма, учреждение һәм корылмаларның атамалары составында кеше исемнәре һәм фамилияләре булган очраклар, исемләнгән объектның гомуми мәгънәсеннән чыгып, бердәм элемент буларак тасвирланды. Мәсәлән, *Г. Тукай исемендәге аэропорт, В.И. Ленин музей-йорты, В.И. Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты* кебек мисаллар FACILITY (корылмалар һәм төзелеш объектлары) яки ORGANIZATION (оешмалар) категориясенә, кертелде: *Әйтик, 2003 елда (DATE)* ***Габдулла Кариев исемендәге Яшь тамашачы театры (ORGANIZATION)*** *Рабит Батулла (PERSON) пьесасы буенча «Сак-сок» драма-бәетен (OTHER) чыгарган иде.*

Куштырнаклар эчендә бирелгән ялгызлык исемнәр (топонимнар һәм антропонимнар), оешма атамалары һ.б. исемләнгән объектның төре нигезендә тамгаланды, мәсәлән, *«Мәскәү» кунакханәсе – FACILITY.* Шулай ук: *Ә без* ***«Зөләйха күзләрен ача»ны (OTHER)*** *тәрҗемә иткәне өчен, күзен дә ачырмыйча тиргәдек кенә аны.*

2. Үз чиратында, **TITLE** категориясенә вазифа атамалары, мактаулы исемнәр, шәхескә йөкләнә торган функцияләрнең исемнәре

керде. Уникаль вазифа атамалары үзләре бәйләнгән локация яки оешма исеме белән бергә алынды. Мәсәлән: *Соңрак концерт мәйданында республика сайлаучыларын **Татарстан Президенты (TITLE)** Рөстәм Миңнеханов (PERSON) сәламләячәк. Оешма каршында ачылган һәйкәлдә – **Советлар Союзы Герое (TITLE), полковник-элемтәче (TITLE)** Борис Кузнецов (PERSON) образы гәүдәләндерелгән.*

3. **ORGANIZATION** категориясендә кешеләрнең эш урыннары яки башка коллектив эшчәнлеге белән бәйле булган исемләнгән объектлар урын алды. Бу категориягә оешма, компания, фирма, партия, ансамбль, команда, клуб атамалары; кыскартылган атамалар *(ЭЭМ, КПРФ)*; юридик зат төрләре *(ААҖ, ЯАҖ, РайПО)*; ялгызлык исемнәр белән белдерелгән оешма атамалары; билгеле бер территориядә урнашкан хөкүмәт, дәүләт, дәүләт хакимияте органнары атамалары *(Татарстанның данын яклау)*; хәзерге вакытта таркалган, яшәешен туктаткан яки башка исем астында йөргән илләр һәм дәүләт атамалары кертелде *(Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы, Советлар Союзы)*. Мәсәлән: *Ни өчен **Мәскәү (ORGANIZATION)** белән **Грозный (ORGANIZATION)** арасындагы килешү барып чыкмаган? Закон нигезендә, бу өстәмә түләүләр **Россия Пенсия фондына (ORGANIZATION)** күчкән иминият кертемнәреннән чыгып исәпләнелә. 2005 елда (DATE) **«КАМАЗ» ААҖнең (ORGANIZATION)** фаразланган керем күләме 52 миллиард сум (MONEY) тәшкил итәчәк. Без ары таба да биографиябезне, мирасыбызны, **Советлар Союзы (ORGANIZATION)** балалары икәнлегебезне горурлык белән хәтердә тотачакбыз.*

4. Локация буларак (**LOCATION**) чынбарлыктагы урынны һәм хәрәкәт юнәлешен күрсәтә торган исемләнгән объектлар тамгаланды: географик объект атамалары; шәһәр, төбәк, урам исемнәре, йорт һәм / яки фатир номерлары, таулар, күлләр, диңгезләр, океаннар атамалары һ.б. Топонимның ыру төшенчәсен белдергән сүзләр дә исемләнгән объект составында билгеләнде (*өлкә, шәһәр, бистә, урам, йорт, елга* һ.б.). Мәсәлән: *Моннан берничә атна элек ремонтка ябылган күпер аркасында, **Яшел Үзән шәһәре (LOCATION)** белән **Мирный бистәсе (LOCATION)** арасын үтү, транспорт бөкеләре аркасында шактый проблемалыга әверелгән иде.*

Бүтән объектларның өлеше булган географик объектлар аерым тамгаланды: *Фатих Кәрим (PERSON) 1909 елның 9 гыйнварында (DATE) **Башкортстанның (LOCATION) Бишбүләк районында (LOCATION)** туа.*

Берничә элементтан торган төгәл адреслар бер исемләнгән объект буларак билгеләнде: ***Декабристлар ур., 83 (LOCATION)** адресындагы йортка киоск ялганган.*

5. **DATE** категориясенә төрле форматта бирелгән даталар һәм тәүлектән зуррак вакыт аралыклары кертелде: *20.01.2001, 2009 елның сентябре, 1934 елның 1 мае, 1990 еллар, 2000 еллар, 8–14 октябрь 2020, 1895–1919, 965 ел (б.э.к.) һ.б.* Мәсәлән: *Искәртеп узабыз,*

***2016 ел (DATE)*** *өчен милек салымын түләү* ***1 декабрьгә (DATE)*** *кадәр башкарылырга тиеш.*

Корпуста һиҗри ай исемнәре дә тамгаланды: *Изге* ***Рамазан (DATE)*** *аенда Аллаһы Тәгаләгә ышанучылар саваплы гамәлләрне күбрәк башкара.*

6. **TIME** категориясендә тәүлектән кимрәк вакыт аралыклары, булган очракта, *сәгать, минут, секунд* сүзләре белән бергә тамгаланды. Мәсәлән: *Без барып җиткәндә* ***10 (TIME)*** *була, эшли башларга да өлгермибез, төшке аш җитә. Корабның радардан юкка чыгуы турында Мисыр хакимияте (ORGANIZATION) җомга көнне* ***13.00 сәгатьтә (TIME)*** *хәбәр иткән.*

7. **MONEY** категориясендә берәмлек исемнәрен дә кертеп акча күләмнәре тамгаланды: *2 миллиард доллар, 1 млн 400 мең сум.* Мәсәлән: *Җыелма бюджетта белем бирү өлкәсенә –* ***59,9 млрд (MONEY).***

8. **QUANTITY** категориясенә төрле үлчәү берәмлекләре (авырлык, аралык, тизлек, озынлык, мәйдан һ.б.) белән бирелгән саннар кертелде. Саннар үлчәү берәмлекләренең (метр, литр, тонна) атамалары белән, аларның кыскартылган тамгалары (м, кг, ц) һәм махсус тамгалары (мәсәлән, «°») белән бергә тамгаланды. Мәсәлән: *Минә шушы* ***114 гектарлы (QUANTITY)*** *басудан көзге арыш гектарыннан уртача* ***28,2 центнер (QUANTITY)*** *төшем белән куандырган. Туфракка* ***5 мм (QUANTITY)*** *күмдерергә кирәк. Аның параметрлары –* ***90-62-89 (QUANTITY),*** *сылулыкка ул көндәлек хезмәт аша ирешә.*

Катлаулы исемләнгән объектлар берничә үлчәү берәмлеге белән белдерелгән очракларда, алар бер элемент (бер бөтен) буларак билгеләнде, мәсәлән: *3 м 50 см.*

9. **CARDINAL** категориясенә акча берәмлекләренә, даталарга, вакыт һәм үлчәү берәмлекләренә туры килмәгән башка саннар кертелде. Бу саннар цифрлар яки сүз белән бирелеп, саналмыш сүзләрдән башка тамгаланды: *Бүген шәһәрдә* ***1224 (CARDINAL)*** *урынга исәпләнгән* ***ике (CARDINAL)*** *яңа мәктәп төзелә.*

10. FACILITY категориясенә аерым корылмалар, төзелеш объектлары, парк, күпер һәм магистраль атамалары һ.б. кертелде: *Казан Кремле, Казан Богородица чиркәве, Г.Тукай исемендәге аэропорт, «Имәнлек» станциясе, Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры, «Яшьлек» паркы*. Мәсәлән: ***В.И. Ленин музей-йортын (FACILITY)*** *карарга килүче халык саны да 3 тапкырга артыр дип уйланыла.*

11. OTHER категориясенә башка төр объектлар: вакыйга атамалары (*Бөек Ватан сугышы*), күк җисемнәре, табигать күренешләре атамалары; китаплар, җырлар, конкурслар, фестивальләр, премияләр, бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәрнең атамалары, сәнгать әсәрләре исемнәре; закон актлары атамалары, процент тамгалары белән бирелгән саннар, телефон номерлары һ.б. кертелде. Мәсәлән: *Наил*

*Нәбиуллин (PERSON) узган елда* ***«Азатлык» дигән гәзит (OTHER)*** *чыга башлауны хәбәр итеп, аның гомуммилли бәйсез басма булачагын әйтте. Аларда укучыларның* ***85 проценты (OTHER)*** *– инглизләр, чит ил балалары санын* ***15 процентан (OTHER)*** *да арттырмыйлар. Ул Чабаксарда (LOCATION) узды, анда* ***«Россия – спорт державасы» халыкара форумы (OTHER)*** *бара. Бүген шәһәр-районнарда* ***Сабан туйлары (OTHER)*** *узды.*

Йомгак ясап әйткәндә, тупланган корпусны татар телендәге текстларда исемләнгән объектларны тану модельләрен булдыру һәм сынау өчен кулланырга мөмкин. Аерым очракларны тамгалауга карата тәкъдим ителгән алымнар бәхәсле була алса да, тикшеренү нәтиҗәләре мондый берәмлекләрнең категорияләрен билгеләү өлкәсендә бердәм карашлар булдыруга ярдәм итәр дип уйларга нигез бар.

**Әдәбият**

Инструкция по разметке сущностей для Dialogue Evaluation 2016. URL: http://opencorpora.org/wiki/Nermanual/2/model.

*Можарова В.А., Лукашевич Н.В.* Двухэтапный подход к извлечению именованных сущностей // Труды конференции по искусственному интеллекту КИИ-2016. Т. 2., 2016. С. 81–88.

GROBID NER Named entity classes, URL: https://grobid-ner.readthedocs.io/en/latest/class-and-senses/

*Nadeau D., Satoshi S.* A survey of named entity recognition and classification // Lingvisticae Investigationes. 2007. № 30. P. 3–26.

NER_in_Tatar, URL: https://github.com/ksemiya/NER_in_Tatar.

*Nevzorova O., Mukhamedshin D., Galieva A.* Named Entity Recognition in Tatar: Corpus Based Algorithm // Proceedings of Computational Models in Language and Speech Workshop (CMLS 2018). CEUR. Vol. 2303. P. 58–68.

*Nouvel, D., Ehrmann, M., & Rosset, S.* Named Entities for Computational Linguistics. New York: Wiley, 2016. 192 p.

Open Source Data Labeling, URL: https://labelstud.io/.

*Özger, Z.B., & Diri, B.* Türkçe Dokümanlar İçin Kural Tabanlı Varlık İsmi Tanıma // Türkiye Bilişim Vakfı Bilgisayar Bilimleri ve Mühendisliği Dergisi. Vol. 5, No. 2. Jun. 2016.

*Starostin, A. et al*. FactRuEval 2016: Evaluation of Named Entity Recognition and Fact Extraction Systems for Russian // Компьютерная лингвистика и интеллектуальные технологии: Вып. 15 (22). М.: Изд-во РГГУ, 2016. С. 688–705.

***Гыйльмуллин Ринат Абрек улы,***
*физика-математика фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Гамәли семиотика институты директоры*

***Хәкимов Булат Эрнст улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының билингваль*
*һәм цифрлы белем бирү кафедрасы доценты,*
*ТР ФА Гамәли семиотика институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Гафарова Вилүзә Роберт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Гамәли семиотика институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 81`34

***А.Ә. Бәдртдинова***

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАС КҮРЕНЕШЕ БУЛАРАК ТАТАР ТЕЛЕ СӨЙЛӘШЛӘРЕНЕҢ АВАЗ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В этой статье раскрывается утверждение о том, что звуковая система языка является культурной ценностью народа и для достижения цели показаны примеры использования текстов народных песен при изучении языковых особенностей диалектов – форм существования языка – национально-культурного достояния народа. Народные песни являются ценным источником исследований для специалистов разных направлений: фольклористов, музыковедов, этнографов. В них кроме лексического богатства диалектов отражаются и звуковые особенности. В исследовании рассматриваются песни кряшенских татар, чатских татар, омских татар, татар, проживающих в Мамадышском районе, собранные во время экспедиций, организованных ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ в последние годы.

**Ключевые слова:** кряшенский говор, мамадышский говор, чатский говор, тевризский говор, ʒ-еканье, оканье, эпентеза.

In the article, folk songs are analyzed as sources of research of the sound features of the dialects of the Tatar language. Folk songs are a valuable source of research for specialists in various fields: folklorists, musicologists, etc., whose texts can also be used by dialectologists in their works. In some of them, in addition to the lexical richness of dialects, sound features are also reflected. The study examines the songs of the Kryashen Tatars, Chat Tatars, Omsk Tatars, Tatars living in the Mamadysh district, collected during expeditions organized by the G. Ibragimov Institute of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan in recent years.

**Keywords:** Kryashen dialect, Mamadysh dialect, Chat dialect, Tevriz dialect, ʒ-ekanye, okanye, epenthesis.

Тел – аралашу коралы булу белән бергә, халыкның милли-мәдәни мирасы да. Мәгълүм булганча, сөйләм оешуда иң беренче мөһим рольне авазлар башкара, тел сөйләмдә авазлар ярдәмендә материальләшә. Аралашу коралы буларак телне гамәлгә ашыру өчен авазлар хезмәт итүен исәпкә алганда, телнең фонетик системасын халыкның милли-мәдәни мирасы дип санау раслана.

Әлеге мәкаләдә татар теленең авазлар системасы милли-мәдәни мирас буларак карала. Татар теленең төп өч диалектка бүленгәнлеге мәгълүм. Әлеге диалектлар үз эчендә сөйләшләргә һәм аннан да кечкенәрәк төркемнәргә – урынчылыкларга бүленә. Татар теленең һәр диалектында, һәр сөйләшендә, урынчылыгында гамәлдә булган авазлар – алар, чыннан да, халыкның байлыгы, зур хәзинәсе. Диалекталь фонетик үзенчәлекләргә мөнәсәбәттә халыкның авазлар системасын

барлык тулылыгында милли-мәдәни мирас дип раслауның нигезендә әнә шуның әһәмиятен ассызыклау ята.

Дисперс яшәүче халкыбызга хас булган аһәңнәрнең әдәби татар теленнән аермасын билгеләү, билгеле бер төбәк халкына гына хас булган үзенчәлекләрне ачыклау һәм өйрәнүдә төп тикшерену объекты – халык сөйләме. Теге яисә бу як сөйләме өчен характерлы билгеләрне, аермаларны күзәтеп, аларның кыйммәтен бәяләү өчен халык сөйләменә игътибар итәбез. Билгеле булганча, халык авыз иҗаты һәм диалекталь сөйләм тыгыз бәйләнештә яши. Ә инде диалект сөйләменең аваз үзенчәлекләрен фәнни тикшергәндә халык авыз иҗаты үрнәкләре мөһим чыганак ролен үти. Авазларны өйрәнгәндә диалект сөйләме иң кызыклы һәм катлаулы өйрәну объектларының берсе булып тора, чөнки диалектларның авазлар системасына күпвариантлылык хас [Юсупов, 2012, б. 191]. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештыра килгән комплекслы фәнни экспедицияләр вакытында диалектологлар соңгы елларда сораулыклар белән эшләү алымын файдалана башладылар. Сораулыклар – телдә иң еш очрый торган квазиомонимнарны үз эченә алган, алдан әзерләнгән сораулар. Әлеге сораулыклар ярдәмендә телчеләр шушы як сөйләменә хас үзенчәлекләрне билгелиләр. Әмма фәнни тикшерену вакытында, сораулыкларга җаваплар яздырганда информантлар кайвакыт әдәби телгә якын итеп, дөрес итеп сөйләшергә тырышалар, шуңа күрә әлеге метод телнең теге яки бу төбәккә хас авазлар системасын бәяләүдә объектив картинаны бирми. Ә менә фольклор әсәрен бәян иткәндә информант, борынгыдан килгән гадәт буенча, ата-бабасыннан бу әсәрне ничек ишеткән булса, шул рәвешендә җиткерә. Информант теленнән беренчел, дөрес формасында язып алынган әсәрләр нигезендә халык сөйләменең фонетик яңгырашын өйрәнүдә объектив нәтиҗәләргә килү җәһәтеннән, без үзебезнең тикшеренүләребездә халык иҗаты әсәрләренә мөрәҗәгать итәбез. Авазлар үзенчәлеген караганда, татар халык җырларына мөрәҗәгать итү дә отышлы алым. Фольклорчы галимнәребез бик хаклы билгеләгәнчә, «Җырлар – халыкның мәдәни һәм рухи байлыгы. Халык җырының хискә, мәгънәгә бай нәфис сүзләре һәм гамьгә, дәрткә бай тылсымлы музыкасы халыкның рухи бөтенлеген һәм тиңдәшсез талант иясе булуын раслый, татарларның җыр хәзинәсендә чал тарих авазлары да, бүгенге көннәр аһәңе дә тирән булып уелган» [Мөхәммәтҗанова, 2022, б. 114].

Максатыбызга ярашлы рәвештә, тикшеренүебезнең өйрәну объекты буларак җырларны куллану өч төрле юл белән башкарыла ала: беренчесе, тел белгече үзе информантлардан яздырып ала һәм анализлый, диктофонга яздырылган җыр текстларына анализ ясаганда, сөйләмдәге авазларны ишетеп алып («тотып алып») фиксацияли һәм интерпретацияли, ягъни төрен билгели, аныклый; икенчесе, диалектологлар, җыр белгечләре, халык авыз иҗатын өйрәнүчеләр, этнографлар хезмәтләреннән карый, өйрәнә; һәм өченче ысул, халык

ансамбльләре чыгышларындагы җырларны, башка массакүләм чаралардан җыелган материалларны туплап, өйрәнеп, нәтиҗә ясаганда куллана. Төрле чыганакларга мөрәҗәгать итү анализ вакытында объективлыкка ирешүне тәэмин итә.

Мәкаләбездә диалектологлар, тел һәм музыка белгечләре, һәм, әлбәттә, фольклорчы галимнәр хезмәтләрендәге материаллар, төрле урыннарда – сәхнә, радио, телевидение аша яңгыраган халык җырлары һ.б. кулланылды. Фәнни төгәллек максатыннан мисаллар, диалектология фәнендә кабул ителгән транскрипциядә бирелде.

Диалектологларның хезмәтләрендә җыр текстлары еш очрый. Мәсәлән, Ф.С. Баязитованың мамадыш сөйләше тел үзенчәлекләре турында язылган мәкаләсендә җыр текстлары сөйләм үрнәкләре буларак бирелгән:

*/änä[1] kilä aftamabil*
*töjägän:är perännek*
*ajɤrɤlɤşu minutɤna*
*menä kilep teräldek ...*
*par atlarnɤ ʒiktem i ʒaratɤp*
*kilgän ʒullarɤbɤzɢa la qaratɤp*
*bezlär kildek sezlärgä i ʒaratɤp*
*sezlär qalɤrsɤz mikän lä ʒaratɤp/*

*Әнә килә автомобиль,*
*Төягәннәр переннек.*
*Аерылышу минутына*
*Менә килеп терәлдек...*
*Пар атларны җиктем и җаратып,*
*Килгән җулларыбызга ла каратып.*
*Безләр килдек сезләргә и җаратып*
*Сезләр калырсыз микән лә җаратып*

[Баязитова, 2017, б. 122].

Бу җырда татар теленең урта диалекты вәкилләре булган мамадыш сөйләшен йөртүче татарлар сөйләменә хас үзенчәлекләр / *töjägän:är/, /ʒaratɤp/, /ʒullarɤbɤzɢa/, /qaratɤp/, /qalɤrsɤz/ төягәннәр, җаратып, җулларыбызга, каратып, калырсыз* сүзләрендә очрый. Сөйләм үрнәгендә урта диалектның төп билгеләре булган *җ*лаштыру */ʒaratɤp/, /ʒullarɤbɤzɢa/ җаратып, җулларыбызга* сүзләрендә бар. /ö/ авазын дөрес итеп, ирен авазы итеп әйтү очрагы теркәлгән, бу яктан урта диалект көнбатыш диалектка каршы куела, билгеле булганча, көнбатыш диалектта күп очракта /ö/ авазы иренсезләштереп /e/, /i/ авазы белән алыштырып әйтелә, мәсәлән: мамадыш сөйләшендәге җырдагы */töjägän:är/ төягәннәр* сүзе, көнбатыш диалектта */ti(e) jägän:är/ ти(е)ягәннәр* вариантында кулланыла [Рамазанова, 2008,

[1] Транскрипция монда һәм алдагы текстларда авторлар язганча бирелде. Билгеләр МФА системасыннан алынды.

б. 10]. Тирән тел арты /q/ авазы бу мисалдагы /*qaratɤp*/, /*qalɤrsɤz*/ *каратып, калырсыз* сүзләрендә көнбатыш диалект вәкилләре сөйләмендә тел арты /k/ авазы белән әйтелә: /*karatɤp*/, /*kalɤrsɤz*/ *каратып, калырсыз.* Җырда рус теленнән кергән *пряник* сүзен /*perännek*/ *перәннек* формасында үзләштергәндә, татар теленең әдәби теленә һәм диасистемасына хас булган алынма сүзләрдә ике тартык арасына сузык өстәлү – эпинтеза күренеше бар.

Диалектолог Д.Б. Рамазанова хезмәтләрендә дә сөйләм үрнәкләре буларак җыр текстлары бирелгән. Мәсәлән, пермь сөйләшенә багышланган мәкаләсендә түбәндәге үрнәк бар:

/*ʒɤrlɤjɢ äle, ʒɤrlɤjɢ äle,*
*ʒɤrlamɤj tormɤjɢ äle.*
*čäčkä kebek jäş ɢömörne*
*buşqa uzdɤrmɤjɢ äle*
*qaşɤŋ qara küzeŋ kük*
*ciŋa sülär süzem küp*
*sülär idem süzläremne*
*sine kürgän kičem juq*/

*Җырлыйк әле, җырлыйк әле,*
*Җырламый тормыйк әле.*
*Чәчкә кебек яшь гомерне*
*Юкка уздырмыйк әле.*
*Кашың кара күзең күк,*
*Сиңа сүләр сүзем күп.*
*Сүләр идем сүзләремне*
*Сине күргән кичем юк*

[Рамазанова, 2017, б. 222, б. 225].

Монда /*ɢömörne*/ *гөмөрне* сүзендә пермь сөйләшендә /ö/ авазын әдәби телдәгечә әйтү, иренләшү гармониясе дә күренә. Бу яктан пермь сөйләшендәге әйтелеш урта диалект, әдәби телнең орфоэпик нормаларына туры килә. Мисалда пермь сөйләшенең тагын бер үзенчәлеге – /öj/ дифтонгын монофтонглаштырып, әдәби телдәге /*söjlär*/ *сөйләр* сүзен /*sülär*/ *сүләр* дип әйтү очрагы да чагылыш тапкан [Рамазанова, 2008, б. 185].

Сөйләм үрнәге булган җыр текстлары тел белгече А.Җ. Хөсәенованың мамадыш сөйләше үзенчәлекләренә багышланган мәкаләсендә дә бирелгән:

/*ʒɤrlɤj-ʒɤrlɤj ʒonnar erlik*
*monda ömä disennär*
*bolarda ömä ikän dip*
*kürşelär dä kersennär…*
*aq ajlapqɤčlar tekterdek inde qarasɤ tuldɤ*
*bezneŋ jaşle ɢümerebez şulaj räχättä uzdɤ*
*urta kirmän kolχozɤnda qaz ömäse digännär*
*ömä qarap qajtɤjq dijep qazannar da kilgännär*

*Җырлый-җырлый җоннар эрлик*
*Монда өмә дисеннәр*
*Боларда өмә икән дип*
*Күршеләр дә керсеннәр...*
*Ак алъяпкычлар тектердек инде карасы тулды*
*Безнең яшьле гөмеребез шулай рәхәттә узды*
*Урта Кирмән колхозында каз өмәсе дигәннәр*
*Өмә карап кайтыйк диеп казаннар да килгәннәр*
[Хөсәенова, 2017, б. 144].

Диалектолог хезмәтендә бирелгән сөйләм үрнәкләрендә *җ*лаштыру: */ʒonnar/ җоннар* сүзе әдәби телдә */jonnar/ йоннар* вариантында кулланыла, */ɢümerebez/ гүмеребез* сүзе әдәби телдә */ɢömerebez/ гөмеребез* формасында норма буларак кабул ителгән.

Керәшен татарлары җырларында да *җ*лаштыру һәрвакыт диярлек саклана һәм гадәттә гел шулай башкарыла, (гади сөйләмдә генә түгел). Мәсәлән, «Бас әле станокка» җырында:

*/bas äle ɤstanokka ɤstannarɤ ɤstanda*
*sezneŋ öʃen genä ʒäşim*
*şuşɤ tatarɤstanda/.*

*Бас әле ыстанокка ыстаннары ыстанда*
*Сезнең өчен генә җәшим*
*Шушы Татарыстанда.*

Бу очракта *җ*лаштыру күренеше */ʒäşim/ җәшим* сүзендә күренә, бу сүз әдәби телдә */jäşim/ йәшим* була, эпентеза һәм протеза күренешләре дә бар: */tatarɤstan/, /ɤstanok/, /ɤstan/ татарыстан, ыстанок, ыстан. Җ*лаштыру – керәшен татарлары сөйләшләренең төп билгеләреннән берсе. Керәшеннәрнең «Кәвәл авылы көе», «Париж» җырларында да шулай:

*/suda balɤq ʒözäder lä ...*
*böten dönʒanɤŋ nurɤ ...*
*qara küzeŋä qarasam*
*ʒörägem ʒana minem;*
*at östendä bik küp ʒördem appaɢɤm*
*qajɤş dilbegä totɤp*
*bu dönʒada bik küp ʒördem appaʒɤm*
*qajɢɤ χäsrät belän/.*

*Суда балык җөзәдер лә...*
*Бөтен дөнҗаның нуры...*
*Кара күзеңә карасам,*
*Җөрәгем җана минем.*
*Ат өстендә бик күп җөрдем, аппагым,*
*Каеш дилбегә тотып.*
*Бу дөнҗада бик-күп җөрдем, аппагым,*
*Кайгы хәсрәт беләң.*

Бу җырларда *җлаштыру* очраклары түбәндәге сүзләрдә очрый: */ʒözäder/, /dönʒanɤŋ/, /ʒörägem/, /ʒana/, /ʒördem/ җөзәдер, дөнҗаның, җөрәгем, җана, җөрдем* әдәби телдәге вариантлары: */jözäder/, /dönjanɤŋ/, /jörägem/, /jana/, /jördem/ йөзәдер, дөньяның, йөрәгем, яна, йөрдем.*

Мишәр татарлары җырларында да аваз үзенчәлекләре саклана. Мәсәлән, «Сүгән яр» җыры. Җырның исемендә үк /öj/ дифтонгының монофтонглашуы чагыла: */sügän/ сүгән.*

*/estäl eslärendä ike kasä*
*berse şäkär bulsa berse bal*
*jeget matur bulsaŋ sü ike jar*
*berse sɤrχau bulsa berse sau...*
*bijek tau başɤnda äj ʒilmilčä*
*äjlänäder ʒillär timinčä*
*ačta tiräzäŋne min kilminčä*
*jatlarnɤ sejärseŋ belminčä*
*qarɤj urmannarnɤŋ urtasɤnda*
*tuqɤrannar ʙɤna ɤjasɤ...*
*jar süminčä tormi dinjasɤ/.*

*Естәл есләрендә ике касә –*
*Берсе шәкәр булса, берсе бал.*
*Егет, матур булсаң, сү ике яр,*
*Берсе сырхау булса, берсе сау.*
*Биек тау башында әй җилмилчә,*
*Әйләнәдер җилләр тиминчә*
*Ятларны сеярсең белминчә*
*Карый урманнарның уртасында*
*Тукыраннар гына ыясы...*
*Яр сүминчә торми динйасы.*

Әдәби телдә */östäl/, /öslärendä/, /söj/, /täräzäŋne/, /söjärseŋ/, /ojasɤ/, /tormɤj/, /dönjasɤ/ өстәл, өсләрендә, сөй, тәрәзәңне, сөярсең, оясы, тормый, дөньясы* вариантында кулланылган сүзләр җырда көнбатыш (мишәр) диалекттагы кебек көйләп әйтелә: */estäl/, /eslärendä/, / sü/, /tiräzäŋne/, /sejärseŋ/, /ɤjasɤ/, /tormi/, /dinjasɤ/ естәл, есләрендә, сү, тирәзәңне, сейәрсең, ыйасы, торми, динийасы.* Бу мисалларда әдәби телдәге /öj/ дифтонгының, монофтонглашып, /ü/ авазы белән әйтелү */söj/, /sü/, сөй, сү, /söjärseŋ/, /sejärseŋ/ сөярсең, сеярсең, /söjminčä/, /süminčä/ сөйминчә, сүминчә* очраклары бар. /ɤj/ кушымчасының – /i/ авазы белән */tormɤj/ ~ /tormi/ тормый, торми* /ö/ авазының /e/, /i/ авазлары белән алышынуы: */estäl/, /eslärendä/, /dinjasɤ/ естәл, есләрендә, динйасы;* /i/ авазының /ä/ белән чиратлашуы */şäkär/ ~ /şikär/ шәкәр, шикәр; /tiräzäŋne/ ~ /täräzäŋne/ тирәзәңне, тәрәзәңне;* /o/ авазының кыскартылуы /ɤjasɤ/ ~ /ojasɤ/ *ыясы ~ оясы* очраклары чагылыш тапкан. Бу яктан көнбатыш диалект әдәби телгә каршы куела.

Җырларны тикшерүче музыка белгечләре дә сөйләшләрдәге җырларның текстларын биргәндә, еш кына аваз үзенчәлекләрен саклап язалар. Мәсәлән, Новосибирск өлкәсе Колыван районында яшәүче чат татарларыннан Н. Х. Нургаянова түбәндәге җырны язып алган:

*/dostɤm alma dostɤm χörmä*
*dostɤm quraj jeläge*
*dostɤm dostɤqta jäʒjek*
*betmäs doneja kiräge…*
*tüter-tüter tütänä*
*su bujɤnda büdänä*
*büdänäneŋ jäme juq*
*bɤjɤl jäjneŋ majɤ juq*
*ufalardan alɤp qajttɤm*
*asɤlmalu zur köske*
*jaqtɤ joltɤstar söngönče*
*ujlap jattɤm men sezte/*

*Достым – алма, достым – хөрмә,*
*Достым – курай йеләге*
*Достым, достыкта йәшийек,*
*Бетмәс дөнейа кирәге...*
*Түтер-түтер түтәнә,*
*Су буенда бүдәнә.*
*Бүдәнәнең яме юк,*
*Быел йәйнең яме юк.*
*Уфалардан алып кайттым*
*Асылмалы зур көске*
[Нургаянова, 2018, б. 436, 476].

Биредә чат татарлары теленә хас *й*лаштыру очрагы [Булатова, 2016, б. 213] */jeläge/*, */jäjneŋ/ йеләге, йәйнең* сүзләрендә чагылыш таба, әдәби телдә бу сүзләр болай яңгырый: */ʒiläge/, /ʒäjneŋ/ җиләге, җәйнең*. Шулай ук бу җырда әдәби телдәге */dustɤm/ дустым* сүзе чат татарлары телендә очраган *о*лаштыру үзенчәлеге белән әйтелә: */dostɤm/ достым* [Бәдртдинова, 2019, б. 2].

Шушы ук кагыйдәгә буйсынуны, ягъни җыр текстында фонетик үзенчәлекләрне саклап бирүне фольклорчы галимнәр хезмәтләрендә дә еш очратырга мөмкин [Миннуллин, Мухаметзянова, Рогачев, 2020, с. 5–11;]. Болай эшләү халык иҗаты әсәренең кыйммәтен тагын да арттыра төшә. Халык җырларының аваз үзенчәлекләрен өйрәнү мисалында халыкның телен генә түгел, аның тарихи үткән юлын да күзалларга мөмкинлек туа [Мухаметзянова, Миннуллин, 2021, с. 5–14].

Музыка белгече Н.М. Шәрифуллинаның Омск татарлары җырларын анализлаган мәкаләсендә дә шул як татарларына хас үзенчәлекләр бар:

*/bezneŋ illär qajsɤ jaqta*
*almas item küsemne*

*očɤqanɤ koşlarnɤŋ artɤnnan*
*äjter item süzemne*
*bezneŋ illär qajsɤ jaqta*
*almas idem küsemne*
*saɢɤnamɤ saɢɤnam tuɢanɤ ilem*
*qajtɤr item ilemä/*

*Безнең илләр кайсы якта,*
*Алмас итем күсемне.*
*Очыканы кошларның артыннан*
*Өйтер итем сүземне.*
*Безнең илләр кайсы якта,*
*Алмас идем күсемне.*
*Сагынам, сагынам, туганы илем,*
*Кайтыр итем илемә*
[Шарифуллина, 2015, с. 277].

Әдәби телдә яңгырау тартык белән әйтелә торган сүзләрне саңгырау тартык белән алыштырып сөйләүгә мисаллар: */item/, /küsemne/ итем, күсемне* сүзләре әдәби телдә */idem/, /küzemne/ идем, күземне* вариантында кабул ителгән. Татар теленең көнчыгыш диалектында төп закончалыкларның берсе – саңгырау тартыкларның яңгырау тартыклардан өстенлеге [Хисамов, 2013, б. 336].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, сөйләмне төзүче авазлар җырны тыңлаучыга җиткерүгә хезмәт итә. Көе белән башкарылган җыр, ихтыярсыз авазлар аһәңе булып яңгырау барышында, сөйләмдәге төп үзенчәлекләрне саклый, борын-борыннан килә торган традициягә ияреп, информант җырны үзгәртмичә башкара. Мондый иҗатка фонетик яктан игътибар бирү, төрле төбәк кешеләренә хас җырларны тикшерү барышында халык сөйләменең искиткеч зур хәзинә, зур байлык булуы дәлилләнә. Җыр текстлары – диалектларның аваз системасын тикшергәндә кыйммәтле чыганак, ә авазлар системасы нечкәлекләрен өйрәнү аша халыкның тарихын тергезергә, аның элек-электән килә торган уңай традицияләрен ачыкларга һ.б. зур мөмкинлекләр туа. Алга таба да авазларны халыкның матди булмаган байлыгы сыйфатында өйрәнүдә әлеге мәкаләбездә кулланылган ысулга мөрәҗәгать итүнең перспективалары шактый зур булуны искәртү дә дөрес булыр.

**Әдәбият**

*Бадртдинова А.А.* Система вокализма говоров татарских сел Колыванского района Новосибирской области (по материалам экспедиции 2017-го года) [Электронный ресурс] // Мир науки. Социология, филология, культурология. 2019. № 1. URL: https://sfk-mn.ru/PDF/05FLSK119.pdf (дата обращения: 29.06.2022.)

*Баязитова Ф.С.* Гасырларны кичкән йолалар (Җирле сөйләш текстлары ясссылыгында) // Милли-мәдәни мирасыбыз: Мамадыш. Казан, 2017. Б. 103–136.

*Булатова М.Р.* Томск татарларының тел үзенчәлекләре һәм рухи мәдәнияте // Милли-мәдәни мирасыбыз: Томск өлкәсе татарлары. Казан, 2016. Б. 209–276.

*Миннуллин К.М., Мухаметзянова Л.Х., Рогачев В.И.* Взаимосвязи в фольклорно-эпическом наследии татар и мордвы-каратаев (на примере фольклорной лексики) // Вестник Северо-Восточного федерального университета им. М.К. Аммосова. Серия: Эпосоведение. 2020. № 4 (20). С. 5–11.

*Мухаметзянова Л.Х., Миннуллин К.М.* Общие традиции в эпосе и семантике обряда сорэн у татар // Эпосоведение. 2021. № 4 (24). С. 5–14.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Җыр жанрында такмаклар: төрләре һәм функцияләре // Фәнни Татарстан. 2022. № 1 (33). С. 114–119.

*Нургаянова Н.Х.* Этномузыкальные традиции татар Новосибирской области // Милли-мәдәни мирасыбыз: Новосибирск өлкәсе татарлары. Казан, 2018. 427–468 б.

*Рамазанова Д.Б.* Мишәр диалекты // Татар халык сөйләшләре. Икенче китап. Казан, 2008. Б. 4–10.

*Рамазанова Д.Б.* Пермь сөйләше // Татар халык сөйләшләре. Беренче китап. Казан, 2008. Б. 179–211.

*Рамазанова Д.Б.* Тол буендагы тел бизәкләре. Барда төбәге татарлары сөйләше // Милли-мәдәни мирасыбыз: Пермь татарлары. Барда. Казан, 2017. Б. 67–230.

*Хисамов О.Р.* Об итогах экспедиции к барабинским татарам // Филология и культура. 2013. № 4 (34). С. 336–339.

*Хөсәенова А.Җ.* Мамадыш сөйләше үзенчәлекләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Мамадыш. Казан, 2017. Б. 137–156.

*Шарифуллина Н.М.* Песенное творчество татар Иртышско-Ишимского Междуречья // Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. С. 267–285.

*Юсупов Ф.Ю.* Татарский диалектный язык: перспективы синхронных исследований // Филология и культура. = Philology and culture. 2012. № 2 (28). С. 190–195.

***Бәдртдинова Алсу Әнис кызы,***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге кече фәнни хезмәткәре*

УДК 82.091

***Ә.М. Шәрипов***

# СИРИН ИҖАТЫ: СОВЕТ ЧЫНБАРЛЫГЫ ЧАГЫЛЫШЫ

Статья посвящена творчеству татарского поэта Сирина (Батыршина Сирина Ханифовича) (1896–1969). Автор раскрывает малоизвестные страницы биографии поэта. Он родился 14 декабря 1896 года в с. Каракашлы Казанской губернии. До революции учился в медресе села Байряка, преподавал в родной деревне. В 1921 году Сирин Батыршин окончил педагогические курсы в Бугульме. И его первые стихи опубликовались в Бугульминской газете «Юксыл». В 1929 году Сирин Ханифович окончил Казанский педагогический институт и преподавал в школе г. Казани. Одновременно был руководителем литературного кружка швейной фабрики. В 1930 году его назначили редактором отдела сельского хозяйства Татарского книжного издательства. В 1935 году Сирин был репрессирован. В 1941 году ушел на фронт, участвовал в Великой Отечественной войне, несколько раз получил контузию. После войны работал в колхозе. Реабилитирован в 1956 году. Последние годы своей жизни провел в поселке Бавлы. Умер 23 ноября 1969 года. В статье акцентируется внимание на творчестве поэта в 30-е годы XX столетия. В своем анализе автор прослеживает особенности развития творчества Сирина, изучает проблему синтетизма в татарском стихотворном жанре, реконструирует целостную картину жизненных реалий, запечатленных в стихотворениях поэта.

**Ключевые слова:** творчество поэта Сирина, основные жанровые стратегии, художественное развитие, поэтапные особенности.

The article is devoted to the work of the Tatar poet Sirin (Batyrshin Sirin Hanifovich) (1896–1969). The author reveals little-known pages of Pot's biography. The poet was born on December 14, 1896 in the village of Karakashly, Kazan province. Before the revolution he studied at the madrasa of the village of Bayryaka, taught in his native village. In 1921 Sirin Batyrshin graduated from pedagogical courses in Bugulma. And his first poems were published in the Bugulmin newspaper «Yuksyl». In 1929 Sirin Hanifovich graduated from the Kazan Pedagogical Institute and taught at a school in Kazan. At the same time he was the head of the literary circle of the garment factory. In 1930 he was appointed as an editor of the Department of Agriculture of the Tatar Book Publishing House. In 1935 Sirin was repressed. In 1941 he went to the front, participated in the Great Patriotic War, received concussion several times. After the war he worked on a collective farm. Rehabilitated in 1956. He spent the last years of his life in the village of Bavly. He died on November 23, 1969. The article focuses on the poet's work in the 30s of the XX century. In the analysis the author traces the peculiarities of the development of Sirin's creativity in the 30s, studies the problem of synthetism in the Tatar poetic genre, reconstructs a holistic picture of the realities of life captured in the poet's poems.

**Keywords:** creativity of the poet Sirin, the main genre strategies, artistic development, step-by-step features.

Шагыйрь Сирин (1896–1969) иҗатын татар халкы тормышыннан аерып карап булмый. Гомере буе ул туган халкы белән бергә, аның бер улы, бер вәкиле булып яшәде һәм иҗат итте.

Шагыйрь буларак Сирин халык алдында беренче тапкыр 1914 елда чыгыш ясый. Бу болай була. 1913 елның көзендә Кәрәкәшлегә, этиләре янына, Томскида чыккан «Сибирия» газетасында «Хатын-кызлар дөньясы» бүлеген алып барган, бер ара аның редакторы вазифаларын да башкарган, заманының күренекле журналисты һәм җәмәгать эшлеклесе Фәридәи Фатыйма кайта. Ул инде авыру була, шулай да авылда җәмәгать эшләренең үзәгендә кайный: тирә-якта беренче кызлар мәктәбе ача, хатын-кызларны укыта, аң-белем тарата. Әмма 1914 елның 16 февралендә кинәт вафат була. Аны соңгы юлга озату зур демонстрация төсен ала, күрше авыллардан да күп халык җыела. Менә шунда Сирин, меңләгән халык алдында үзенең беренче «Фәридәи-Фатыйма ханым рухына» дигән шигырен укый:

*Син үлсәң дә, әмма ләфзан* (тыштан гына. – *Ә.Ш.), –*
*Син мәгънәи үлмәдең.*
*Керде җәсәдең кабергә,*
*Әмма үзең кермәдең, –*

дигән юллар халык күңеленә бик хуш килә; авыл халкы соңыннан да, Фәридәи-Фатыйма хакында сөйләшкәндә, Сириннең әлеге шигырен искә төшерә. Шигырь шул ук елны «Сөембикә» журналында басылып чыга һәм ул шагыйрьнең матбугатта чыккан беренче әсәре була.

1918 елда Сирин Бөгелмәдәге өчьеллык «Тәгълим-тәрбия курсларына», ягъни укытучылар әзерләү семинариясенә укырга керә. Монда ул Габдрахман Сәгъди, Һади Атласи, Фазыл Туйкин кебек күренекле шәхесләрдән белем ала, социализм идеяләренә чын күңелдән бирелгән актив шәхес булып формалаша.

Сириннең беренче шигырьләре 1919–1920 елларда Самарадагы «Яңа көч», Бөгелмәдәге «Якты юл», Казандагы «Эшче» газеталарында басылып чыга. Аның иҗатында Гражданнар сугышы темасы шактый тулы чагыла. Мәсәлән, «Кызылармеец хаты» (1919) әсәрендә авторның якты киләчәк өчен сугышта үзенең катнашуы белән горурлануы тасвирлана. «Авыл кызына» шигырендә (1919) Гражданнар сугышы еллары өчен типик бер күренеш сурәтләнә: яшь кыз сөйгән егетен сугышка озаткан. Кыз сагына, борчыла, кайгыра, елый. Шагыйрь аны юата, киләчәктә, егете кайткач, матур тормыш булачагына ышандырырга тырыша. «Сәлам сезгә, кызыл бөркетләр!» (1920), «Булмаса» (1920), «Кызыл гаскәргә» (1922), «Атлы шлемнар» (1927), «Кызылармеец атлар» (1928) шигырьләре дә революцион романтика, киләчәк тормышка тирән ышаныч белән сугарылган. Ул елларда Сириннең бигрәк тә «Сикерт атың! (Кавалерия маршы)» (1925) әсәре популяр була. Шагыйрь аны кайта-кайта эшләгән: аның «Атлы шлемнар» дип аталган вариантында (1927) автор шигырьнең эчке ритмына зур әһәмият бирә: ат тоякларының тавышларын

хәтерләтә торган сүзләр генә куллана, шигырьнең музыкальлек ягына басым ясый:

*Әй, командир!*
*Бир команда!*
*Сөйгән атым,*
*Чаптар атым!*
*Тып-тып басып,*
*Ат уйнатып,*
*Атлат атың!*
*Атлат атың!*

Шагыйрь Кызыл гвардиягә дан җырлый, аның уңышларына шатлана:

*Әй, командир!*
*Бир команда:*
*Җиңү якын!*
*Җиңү якын!*
*Тып-тып басып,*
*Ат уйнатып,*
*Сикерт атың!*
*Сикерт атың!*

1921 елгы ачлык башлангач, Бөгелмә семинариясендә укулар туктала. Шул елда язылган «Ачлар авазы» шигырендә Сирин бөтен Идел буен чолгап алган ачлыкның үзәк өзгеч картинасын сурәтли:

*Ярлы илгә ярлылар баш; алтын, көмеш җирдә таш,*
*Төрле чүп-чар, алабута безнең илдә булды аш.*
*Юк әле, түзми күңел, җан тартыша, сызыла йөрәк,*
*Бер телем икмәк сорап, тетри бәгырь, өзелә йөрәк.*
*Ач каберләр капкасын! – ди дошманым, көн-төн сөйли,*
*Җан тәрәзә тактасыннан сызгыра, үлем сөйли.*

«Салкын энәләр (Җыр туганда)» ( 1922) шигырендә дә ул вакыттагы ярлылык, ачлык, салкыннан туңу атмосферасы тасвирлана. 1922 елда халыкның бөтен өмете кырга чәчелгән игеннәрдә була. Шул вакытта иҗат иткән «Яз – игенчегә» шигырендә Сирин авыл кешесен тизрәк кырга эшкә чыгарга чакыра:

*Игенче, ятма йоклап, тор, кулың сызган, бавыңны иш!*
*Сиңа – урак, кәйлә; һәр көн юлыңны ач, тавыңны тиш!*
*Җитә бит яз, иген чәчәр өчен син дә ашык тиздән!..*
*Ашык тиздән, – үлем биргән бу ачлык китсен ул бездән!..*

1923 елның көзендә Сирин Казанда Татар рабфагына укырга керә; иҗади яшьләр белән таныша. Рабфак елларында (1923–1924) Сириннең иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-эстетик карашлары эволюция кичерә. Ул шигырьләрен, Маяковскийдан үрнәк алып, зур аудиторияләрдә кычкырып укуны күздә тотып иҗат итә башлый, шуның белән татар әдәбиятында сөйләм шигырен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә.

Рабфакны тәмамлагач, Сирин 1924–1925 елларда Бөгелмәдә «Якты юл» газетасында җаваплы секретарь булып эшли. Әмма аның күңеле Казанга тарта. Һәм ул, 1926 елның көзендә кабат Казанга килеп, Көнчыгыш дәүләт педагогия институтына укырга керә. Монда ул үзе теләгән иҗади мохиткә эләгә: Һ. Такташ, Г. Кутуй, Х. Туфан, Ә. Исхак һ.б. белән таныша, бөтен тырышлыгын куеп белем алуга, иҗат эшенә бирелә. 1928 елда аны яңа гына оешкан ТАППка әгъза итеп алалар. Нәкъ менә студент еллары һәм шуннан соңгы биш-алты ел (1927–1935) – Сириннең иң актив иҗат иткән һәм көчле трибун шагыйрь булып танылган чоры.

1920–1930 елларда барлык татар шагыйрьләре, шул исәптән Сирин дә аралашып яшәгән Һ. Такташ, Г. Кутуй, К. Нәҗми һ.б., совет власте шартларында поэзиядә үз урыннарын табарга омтылып, иҗатта төрле экспериментлар үткәрәләр. Мәсәлән, Һ. Такташның «Тиеләр», «Янар таулар», Г. Кутуйның «Көн – кадак», «Карт пычкычы», К. Нәҗминең «Еллар гына юып бетермәс», «Кабыргасы белән тора» һ.б. әсәрләре. Сирин дә 1926–1928 елларда шигырьнең формасы белән мавыгып ала. «Беренче май» (1926), «Көнлиләр» (1927), «Безнең кайгылар» (1928) шигырьләрендә ул, катлаулы образларга, сүзләрнең охшаш яңгырашына өстенлек биреп, аларны тезеп төшә һәм әсәрнең эчтәлеген икенче планда калдыра. Әмма аның бу мавыгуы озакка бармый, берике елдан ул үзенең мондый экспериментларыннан арынып, әсәрләренең сәнгатьчәлеген кайгыртып иҗат итә башлый.

Сириннең эзләнүләре, башлыча, поэзиядә үз стилен, үз шигъри формасын эзләүдә, эчтәлек белән форманың берлегенә ирешергә тырышуда күренә. Ул, Маяковскийга ияреп, татар шигыренең трибунлык сыйфатын үстереп иҗат итәргә тырыша. Әсәрләрнең сәнгатьлелегенә ирешүдә ул бер алымны – һәр сүзне аерып алып, аның тирән мәгънәсен ачып салып, сүзләрне бер-бер артлы юл-юл итеп тезеп бару формасын куллана. Бу исә автордан шигырьнең эчке ритмын нечкә тоемлауны, ачык яңгырашлы рифмалар сайлап язуны таләп итә. Шулай итеп, 1930 елларда татар поэзиясендә башка беркемнекенә дә охшамаган «Сирин стиле» барлыкка килә. Бу Һ. Такташ стиле дә, Х. Туфан стиле дә түгел иде. «Сирин стиле», бер яктан, хыялның көчле булуы, тирән эмоция, лиризм һәм революцион романтика белән сугарылган булса, икенче яктан, яңгыравыклы ритмы, халыкның йөгерек, гади, матур телен куллануы белән үзенчәлекле иде. Сирин музыкаль яңгырашлы сүзләр белән төрле халәт-хәрәкәтләрне күз алдына китереп бастыра. Шигырьдә музыкальлек өстенлек ала, аңарда төрле тавышлар яңгыраган төсле, тәэсирле итеп бирелә, шул ук вакытта автор шигырьнең эчтәлегенә дә тирән мәгънә салырга тырыша: һәр әсәренең иҗтимагый яңгырашы турында кайгырта. Поэтик идея белән публицистиканы һәм сәнгатьчәлекне органик кушып алып барырга омтыла.

Беренче шигырьләреннән үк («Энәләр» (1922), «Тегүче кыз» (1925)) Сирин шушы юнәлештә тәҗрибәләр ясый башлый. Шушы

алым белән Сирин 1927 елда үзенең атаклы «Язгы тамчылар» шигырен яза: анда ул, бер яктан, охшаш яңгырашлы сүзләрне сайлап, тамчылар тавышын чагылдырырга омтылса, икенче яктан, әсәрнең эчтәлегенә дә тирән мәгънә салугаирешә. Сирин монда язгы тамчыларның матурлыгын гына җырлап калмый, ә бу күренешне җәмгыять тормышы белән дә бәйли, шуның белән әсәрнең иҗтимагый ролен дә көчәйтә. «Там, там, тамчы там!» сүзләрен рефрен итеп куллана һәм алар, һәр кулланган саен, әсәрнең иҗтимагый мәгънәсен тирәнәйтә баралар, төп идеяне ачарга ярдәм итәләр:

*Там.*
*Там,*
*Тамчы, там,*
*Бергә тамыйк ичмасам!*
*Мин дә тамчыланып тамыйм,*
*Көрәшләрдә аксын кан!*

Әсәр басылып чыгу белән (1927) бик тиз популярлаша һәм халык, яратып, аңа көй дә яза. Ул көй безнең көннәргә кадәр килеп җиткән – ул әле бүген дә балалар бакчаларында, музыка дәресләрендә, балаларны биеткәндә уйнала.

Иҗатының башыннан ук Сирин Тукайдан үрнәк алып яза. 1910–1915 елларда, мәдрәсәдә укыганда ук, ул, Тукай әсәрләреннән өйрәнеп, классик шигъриятнең газәл, касыйдә, мәснәви кебек жанрларын үзләштерә. Бөгелмәдә семинариядә укыганда (1918–1921), яшь шагыйрь үзенең берничә шигырен Тукай иҗат иткән темаларга – аваздаш темаларга багышлый. Сириннең 1920–1930 еллардагы әсәрләре белән Тукай әсәрләре арасында хәтта типологик параллельләр дә үткәрергә мөмкин. Яшь ягыннан Сирин Тукайдан ун яшькә кечерәк, ул 1896 елда туган. Тукай белән Сириннең тормыш юллары һәм иҗат юнәлешләре арасында беркадәр охшашлык та, зур гына аерма да бар. Охшашлык шунда – алар икесе дә мәдрәсә белеме алганнар, иҗатларында Көнчыгыш классик поэзиясе йогынтысын кичергәннәр (Сирин ул йогынтыны Тукай әсәрләре аша алган). Әмма җитди аерма да бар: алар икесе ике төрле җәмгыятьтә яшиләр, икесе ике төрле идеология вәкиле.Тукайның бөтен гомере 1917 елгы революциягә кадәрге шартларда уза. Ә Сирин, үзенең 21 ел гомерен революциягә кадәр яшәсә дә, бөтенләй икенче идеология йогынтысында тәрбияләнгән шәхес, ул – совет чоры шагыйре. Беренче елларда ук, алда әйтеп үтелгәнчә, ул бөтен күңеле белән, революциядән соң гаделсезлекләр булмаган, яңа, бәхетле тормыш төзибез дип, шулкадәр тирән ышана ки, үзенең әсәрләрендә еш кына патша чорындагы ач-ялангачлар тормышын яктырта, ә совет чорын бәхетле, якты итеп сурәтли. Шушы караш Сириннең Тукайга ияреп, яки аның әсәрләренә җавап рәвешендә язган шигырьләрендә дә ачык чагыла.

Тукайның «Эштән чыгарылган татар кызына» шигыре (1909) белән Сириннең Гражданнар сугышы чорында иҗат иткән «Авыл кызына» (1920) әсәре арасында ук охшашлыклар бар: икесе дә яшь

татар кызының елавына багышланган; икесендә дә «мәюсь», «залим», «күңел» кебек уртак сүзләр кулланыла. Әмма Тукайда татар бае «залим» булып саналса, Сириндә иске тормыш «залим» дип атала. Тукайда татар кызының чарасызлыгы сурәтләнә, ә Сирин исә Гражданнар сугышына киткән егетен сагынып елаучы кызны: *«Күп тә үтмәс, менә кайтып җитәр /Җан сөйгәнең көләч йөз белән / Менә, киләчәгең нинди матур/ Рәхәтләнеп гомер итәрсең!»* – дип юата, киләчәкнең якты булачагына өметләндерә.

«Диңгезгә» (1920) шигырен дә Сирин Тукайның «Даһигә» (1913) әсәренә нигезләнеп иҗат иткән. Икесе дә идеал темасына багышланган, икесе дә – мәснәви формасында. Бу әсәрләрнең язылу вакытлары аермасы нибары җиде ел. Тукай үз әсәрендә милли-азатлык хәрәкәте турында уйлана һәм газиз халкын колониаль изүдән коткару, аны иҗтимагый-мәдәни яңарышка алып чыгу юлларын эзләгән даһи образын иҗат итә. Тукай яшәгән җәмгыятьтә алда ялтыраган нәрсә ул ут түгел, ә алтын (ягъни байлык) икән һәм ул «нәрсәдә» нур да, күңел өчен җылылык та юк икән; җәмгыятьнең нигезендә алтынга, байлыкка омтылу ята икән:

*Ялтырау күрдеңме артта? Ут түгел ул – алтын ул;*
*Юк мөкаддәс нур да анда, юк җылылык, салкын ул, –*

ди шагыйрь.

Тукай әлеге даһины үзе бара торган юлдан тайпылмаска, үз идеалына барганда туктап калмаска чакыра:

*Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;*
*Алга барганнарга тик табла табылса – Алла ул, –*

ди.

Сириннең «Диңгездә» шигырендә исә бөтенләй башка идеал тасвирлана; ул – яңа тормыш өчен көрәштә бернәрсә алдында да туктап калмый торган, диңгез дулкыннарына да буйсынмас, көчле, ашкын, бунтарь образ. Диңгезгә эндәшеп, Сириннең лирик образы болай ди:

*Ниндәй дулкыннарга атсаң да, барыбер батмамын!*
*Һәм үлеп, суың төбендә дә череп ятмамын!*
*Миндә көч, гайрәт вә дәрт бар, күкрәгемдә ут яна,*
*Мин күрәмен алда – анда ялтыраган ут, әнә!*
*Ул шулай күзгә күренә, ут түгел, юк, нур бит ул!*
*Пакь вә саф, ап-пак күңелле бер фәрештә нур бит ул!*

Димәк, алда күренгән нәрсә ул, Сирин фикеренчә, нур, фәрештә икән бит; ул күңелне үзенә тартып, кызыктырып тора. Ә ул нур, аның фикеренчә, совет җәмгыятенең якты киләчәге; шагыйрь аны үзе өчен хәтта Алла урынына күрә. Сирин ул елларда совет властена менә ни дәрәҗәдә ихлас күңелдән ышанган икән...

Шунысы кызыклы: Тукайның «Булмаса» газәленә (1908) ияреп, Сирин дә «Булмаса» (1920) шигырен язган (әмма газәл формасын сайламаган, ә ирекле рифмалар кулланган). Ике шигырь дә 15–15 үлчәме

белән иҗат ителгән. Үз шигырендә Тукай шагыйрь күңелен дәртләндерүче былбылга (гүзәл затка, гүзәллек шаһына) мәдхия җырлый:

*Кем белер кадреңне, җаным, дәртле күңел булмаса?*
*Наз итәр кемнәргә гөл – каршында былбыл булмаса?*
*...Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә дөнья бәһа;*
*Ул болай бер кыз гына – каршында Мәҗнүн булмаса.*

Ә Сирин үз шигырен иҗтимагый темага багышлый: «коммунист» дип аталган кешенең совет җәмгыятендә зур дәрәҗәсе, җаваплы вазифасы, «гали фәрештәлеге» барлыгы әйтелә. *«Әгәр ярлы халыкка, ач-ялангачларга чын күңелең белән хезмәт итәргә теләгең булмаса, син коммунист булма да»,* – дигән фикер үткәрелә:

*Булмаса күңелдә халыкка мәхәббәт хисләре, –*
*Булма коммунист, якын килмә бүтән уйлар белән.*
*Янмаса күкрәгеңдә ярлы халыкның уйлары, –*
*Ул гали фәрештәлек, басма аяк герләр белән.*

1923 елда, Тукайның үлеменә ун ел тулу уңае белән Сирин «Безнең яшьләр (Тукайның «Яшьләр»енә ияреп, җавап урынында)» дигән шигырен яза. Тукай әсәре дә, Сириннеке дә классик касыйдә жанрына куела торган барлык таләпләргә дә җавап бирә: икесе дә – аа, ба, ва, га... тәртибендә рифмалашып килә торган икеюллыклар, ягъни бәетләрдән тора. Хәтта күләмнәре дә бер үк диярлек – Тукайныкы ун бәеттән торса, Сириннеке тугыз бәетле. Әмма әсәрләрнең идея юнәлеше монда да төрле: Тукай әсәре 1905 елгы революциядән соңгы кара реакция елларында язылган һәм төшенкелек, киләчәккә өметсезлек мотивлары, яшьләрдә егетлек, кешелек сыйфатларының юклыгына зарлану фикерләре белән сугарылган булса, Сирин шигырендә киресенчә – әсәр революцион романтика, авторның яңа, якты тормыш төзүгә ныклы ышанычы, барган юлдан һичкайчан тайпылмау, ахырга кадәр җиңеп барырга омтылу кебек хис-тойгылары, ниятләре белән өрételгән. Сириндә, алда әйтелгәнчә, үз-үзенә нык ышанган, ашкын, бунтарь герой образы сурәтләнә.

Шигырьнең беренче юлларында ук Тукай болай ди:

*Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,*
*Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас.*
*Кичә якты вә милли бер күңелдән*
*Бүген тычкан утыдай нур табылмас.*

Ә Сирин исә, Коммунистлар партиясе идеяләре белән рухланып, үзенең шигырен романтик пафос, киләчәккә зур өметләр белән башлап китә:

*Йөрәккә ут кабынган, мәңге сүнмәс,*
*Яна күкрәктә дәртләр, һич суынмас.*
*Көч алдык, калтырау юк юлыбызда,*
*Диябез яшьләр: «Бу күкрәк мәңге туңмас!»*

Тукай үз чорындагы яшьләрнең, көндәлек, вак идеаллар белән рухланып, милләт проблемаларыннан читкә китүләрен, акчага, байлыкка табынып яшәүләрен тәнкыйтьли; аларның, тәти уенчык тапкан сабый бала кебек, байлык белән мавыгуларын әйтә.

Сирин дә Тукайның фикер сөреше артыннан бара, әмма, Тукай чорындагы яшьләрдән аермалы буларак, «яңа яшьләрнең» алтын-көмешләргә табынмыйча, халыкка хезмәт итүләрен, искелекләрне җимереп, яңа тормыш төзүләрен, шул алган юлларыннан читкә тайпылмаячакларын белдерә:

*Күңелдә кайный хезмәтләр халыкка,*
*Чын ир алтын-көмешләргә табынмас.*
*Җимердек искелекләрнең барын да,*
*Аларга инде артык кайту булмас.*
*Ышандык без кызыл көчкә, юл алдык,*
*Турайдык сафка, нык юл, һич таелмас.*

Тукай үз чорындагы яшьләр күңелендә егетлек, олпатлык, кешелеклелек сыйфатлары булмаганга зарлана, яшьләрнең үзләренең тарихтагы шанлы һәм данлы, фидакяр бабалары эшчәнлекләренә лаек булган эш-гамәлләр кыла алмаганлыкларына, көчсез булуларына әрни:

*Яралганмы бу яшьләр күңле әллә*
*Мөрәүвәт маддәсе яглыр-ягылмас?*
*Ышанабыз халык көчсезлегенә,*
*Бабайлар шөһрәтен сагныр-сагынмас.*

Ә Сирин һәрберсенең күңеленә иман нуры тулган, ярлы илнең бәхете өчен көн-төн көрәшә торган яңа яшьләр образын тудыра:

*Иман күкрәктә һәммәбездә тулган,*
*Табылмас, безгә көчсезләр тагылмас.*
*Көрәштә без ныгыйбыз көн дә, көн дә,*
*Эшлибез ярлы ил бәхте юлында,*
*Кылыч, балта, чүкеч кулдан салынмас.*

Тукай үзенең шигырен «Милләт байрагын тотып юлга чыксак та, ерак китә алмадык, егылдык» дигән фикер белән тәмамлый. Сирин исә, үзләренең милләт байрагы түгел, ә интернациональ эчтәлектәге кызыл байрак тотып юлга чыгуларын һәм ахыргача барачакларын әйтә. Яңа яшьләрнең нык, көчле икәнлекләрен күрсәтү өчен, үзләренең кулларын «тимер куллар» дип атый.

Шулай итеп, «Безнең яшьләр» – 1923 елда әле Сириннең чын күңелдән гадел җәмгыять төзибез, дип ышанып яшәгән чагын, ягъни аның иҗат юлының башлангыч чорын характерлый торган шигырь. Аны көч-энергиясе ташып торган 27 яшьлек Сириннең 24 яшьлек Тукай белән әңгәмәсе, бәхәсләшүе дип тә карарга мөмкин.

Сирин, татар совет шагыйрьләреннән беренче буларак, үз иҗатында җәмгыять һәм шагыйрь, шагыйрьнең җәмгыятьтәге урыны,

роле, яңа совет шартларында шагыйрьлек миссиясе проблемаларын күтәреп чыга, «Йөрәк каны белән» (1929) шигырен яза. Шунысы мөһим: шагыйрьлек миссиясен аңлауда да Сириннең карашы Тукайныкы белән аваздаш. Бу шигырьдә Сирин үзенең поэтик иҗатын болай сурәтли:

*Бу – минем*
*уйларым,*
*Бу – ритм.*
*Бу – минем*
*йөрәгем тибүе.*
*Бу – минем*
*канымның*
*тәнемнән*
*Җыр булып*
*кәгазьгә*
*күчүе.*

Төзелеп килә торган яңа җәмгыятьтә шагыйрьнең миссиясен ачыграк күрсәтү өчен, ул үз-үзенә шундый сорау бирә: *«Ни өчен, ни өчен мин болай / Ак кәгазь өстендә кан коям? / Каләмнән тамдырып канымны / Үземне вакытсыз ник суям?»* Шушы сорауга бәйләп, ул үзенең төп фикерен әйтә: шагыйрьнең иҗаты, тормыштагы вазифасы аның шәхси мәнфәгате, үз-үзен яратуы, дан-шөһрәткә омтылуы белән бәйле булырга тиеш түгел. *«Шөһрәт кирәкме? – Кирәкми / Мин үлгәч, шөһрәт нәрсәгә?»* – ди ул. Үз алдына куйган сорауга үзе үк: *«Киләчәк тормышны күрәсе һәм шунда яшисе килә»,* – дип җавап бирә. Ә киләчәк тормышны автор идеал итеп күзаллый: *«Киләчәк илларның тормышы / Уемда бик матур корылган. / Шул илларның нигез ташына / Безнең еллар өеп куелган».* Әмма ул матур киләчәкне кул кушырып утырып кына, яки елмаеп, эшләр-эшләмәс йөреп кенә якынайтып булмый. Шагыйрь кәеф-сафа корып, бизәнеп, үз-үзенә сокланып, эшсез утыруга каршы чыга: *«Ни булыр иде соң / мин, Сирин / Гөлсирин булып, гел бизәнсәм? / Яз саен яшәреп, / Таң саен зәп-зәңгәр чәчкәдә утырсам?»* – ди. Һәм ул, якты киләчәкне тизрәк җиткерү өчен, үзенең шигърияте, ялкынлы сүзе белән көрәшәчәген, шушы юлда хәтта үзен корбан итәргә дә әзер торуын белдерә:

*Юк,*
*каным жәл түгел,*
*коелсын чәчкәм дә,*
*Каләмнән тамдырып*
*канымны,*
*кәгазьгә чәчәм дә,*
*Җыр итеп*
*тезәм мин.*

*Беләм мин:*
*корбансыз*
*җиңү юк,*
*Авырлык күрмичә,*
*рәхәтләр күрү юк.*

Күренә ки, Сирин шагыйрьнең җәмгыять тормышындагы миссиясен поэтик югарылыкка күтәреп тасвирлый: үзен шагыйрь дип исәпләгән иҗат кешесенең бары тик янып, халыкның кайгышатлыкларын үз йөрәге аша үткәреп, «йөрәк каны белән» генә язарга тиешлеген белдерә. Тукай да шундый карашта. Тукай да, билгеле булганча, шагыйрьлек вазифасын бик югары бәяләде: шагыйрь үзенең иҗатын шәхси мәнфәгатькә түгел, ә халыкка хезмәт итүгә багышларга тиеш. *«Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә; Бу юлда һәртөрле хурлыкка, зорлыкларга түзмәккә!»* – дигән чакыру ташлады. Үз чорының вазгыятыннан чыгып, шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси ролен «йоклаган» татар халкын уятуда, тергезүтерелтүдә күрде. Тукай бу мәсьәләдә рус классиклары А.С. Пушкин белән М.Ю. Лермонтовка таянды, алардан үрнәк алды. *«Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам / Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам»,* – дип язды үзенең «Бер татар шагыйренең сүзләре» (1907) шигырендә. Монда шундый типологик параллель дә үткәреп була: 1826 елда Пушкин, 1841 елда Лермонтов «Пәйгамбәр» («Пророк») дигән әсәр язалар һәм шагыйрьнең җәмгыятьтәге миссиясен пәйгамбәрлек миссиясе дәрәҗәсенә күтәреп тасвирлыйлар. Тукай да «Пәйгамбәр (Лермонтовтан үзгәртелгән)» (1909) шигырендә шагыйрьнең миссиясен пәйгамбәр миссиясе югарылыгында күрә һәм Сирин әсәрендәге фикергә охшаш фикер әйтә – шагыйрь үз халкы өчен армый-талмый хезмәт итәргә тиеш: *«Керештем мин мәхәббәткә, карендәшлеккә өндәргә / Ашамый-эчми көндез, кич белән баш куймый мендәргә»*; шагыйрь рухани ут белән янарга тиеш: *«Янып рухани ут берлә, ашыккан хәлдә юл тотсам»*, – ди шул ук «Пәйгамбәр» шигырендә. Рус галиме И.Г. Пехтелев язуынча, Тукайның бу фикерләре үзенең остазлары Пушкин һәм Лермонтов фикерләре белән аваздаш. Шулай итеп, Сириннең фикерләре Тукай фикере белән дә, Пушкин һәм Лермонтов фикерләре белән дә аваздаш булып чыга. Бер үк фикердәге Пушкин–Лермонтов–Тукай–Сирин дигән чылбыр барлыкка килә һәм Сирин бу чылбырда ахыргы бер буын ролен үти. Әдәбият һәм сәнгатьнең җәмгыятьтәге урыны, иҗади хезмәт темалары Сириннең «Һейне фикере» (1929), «Тормыш ярына басып» (1933), «Җиңел эшләр» (1933), «Гадәт» (1958), «Минем гаскәрем» (1960) кебек әсәрләрендә дә чагылыш тапты.

1933 елда Сирин, яңа алым кулланып, «Тукаевтан Сирингә телеграмма» дигән шигырь язган. Анда Тукай, Сирингә мөрәҗәгать итеп, аңардан: *«Син үзең ничек яшисең, / Бармы соң ашарыңа? / Бармы соң эшләү шартың, / Квартирың язарыңа?»* – дип сораша, шул турыда үзенә хат язуын үтенә. Шулай итеп, Сирин гомер буе Тукайдан

өйрәнеп, үрнәк алып, күңеленнән аның белән сөйләшеп-фикерләшеп иҗат иткән. Бу, әлбәттә, Сирин иҗатына уңай йогынты ясаган.

Сирин 1920 елларда әле Октябрь революциясенең халыкка матур тормыш алып киләчәгенә чын күңелдән ышана. 1927 елда язылган «Урам уртасында» шигырендә ул Октябрьнең ун еллыгы уңаеннан, рухланып, болай дип яза:

*Их, мин бүген дә, көчем җитсә,*
*Беләмсез, нәрсә эшләр идем? –*
*Бөтен халыкны бер җиргә җыяр идем дә,*
*Җирнең котыбына басып,*
*Октябрьнең ун еллык*
*Уңышын сөйләр идем!*

Сирин иҗатында тормышка иске һәм яңа карашлар капма-каршылыгы совет җәмгыятендәге яңа тормыш күренешләрен сурәтләү аша ачыла. «Тракторчы кыз» (1928) әсәрендә тракторчы һөнәренә укып кайткан авыл кызының фикерләре аның этисенең иске карашына каршы куелып тасвирлана. Сирин авыл тормышына совет власте алып килгән яңа карашка, яңа мөмкинлеккә дан җырлый. Андагы лирик герой – гади бер кыз, түбәндәгене сөйли: ул кыз булып тугач, аның этисе бер дә канәгать булмаган; ул үзенә йорт эшләрендә ярдәмче булыр дип, малай көткән икән. Әмма кыз туган. Әтисе бервакыт, көтмәгәндә *«эштән кайткан чакта салкын тиеп»*, авырый башлый һәм, терелә алмыйча, үлеп тә китә. Кыз белән әнисе икәү генә кала. Шуннан соң алар тормышның барлык авырлыкларын бергә кичерәләр: кышын җеп эрләп, киндер сугалар; җәен бергә урак уралар, печән җыялар. Кыз комсомолга керә, *«эшчән бер кыз булып таныла»*. Бераздан тракторчы булу өчен, шәһәргә укырга китә һәм шул һөнәрне үзләштереп кайта. Кыз инде хәзер үзенең иркен кырларда тракторда эшләве белән горурлана һәм этисенә:

*Исән булсаң, әткәй, күрер идең*
*Кызың ничек эшче булганын.*
*Киң кырларда трактор белән*
*Җырлый-җырлый сабан сөргәнен, –*

ди.

Шулай итеп, бу әсәрдә тормышка эти кешенең – искечә, ә комсомолда тәрбияләнгән кызның яңача карашларының капма-каршылыгы ачыла. 1928 елда иҗат ителгән «Ялган елмаюлар» шигырендә Сирин эчүчелекне тәнкыйтьләп чыга: ул, *«дөнья»*ның беркайчан да үзен *«агу белән кунак итмәгәнен»* әйтә дә, әсәрен болай тәмамлый:

*Ничә еллар җирдә яшәп,*
*Агуларны авыз итмәдем.*
*Кая, китер, мине якын күрсәң,*
*Май ягып бир арыш икмәген!*

Педагогия институтын тәмамлагач (1929), Сирин бер ел Казанның М. Вахитов исемендәге мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта; бер үк вакытта, ТАПП тарафыннан билгеләнеп, Казан тегү фабрикасында яшь каләм тибрәтүчеләрнең әдәби түгәрәгенә җитәкчелек итә. 1930 елда аны нәшриятка, Татиздатның авыл хуҗалыгы бүлегенә редактор итеп эшкә чакыралар. Ул анда 1935 елның августына, ягъни кулга алынганчы эшли. Ул елларда Татиздатның авыл хуҗалыгы бүлеген шагыйрь Нур Баян җитәкләгән.

Шулай иҗат белән янып йөргәндә, кинәт көтелмәгән бер хәл була: Сиринне студент чакта ук кулга алалар. Бу вакыйга турында ул үзенең истәлекләрендә болай яза: *«...Кичке ут алынган иде, ишектән дүрт кеше килеп керде. Шуларның берсе военный милиционер иде. “Батыршин арестован”, – диделәр дә, мине милиция янына куйдылар. Хуҗа хатыны, күрше хатыннарыннан комиссия төзеп, өстәлдә булган китапларны, кәгазьләрне җыеп алып бәйләделәр. Әйберемне һәм үземне “Кара карга” дигән машинага утыртып алып киттеләр... Машинадан төшкәч, аңладым: мине Черек күл каршындагы НКВД төрмәсенә китереп япканнар икән.*

*Мин баш вата башладым. Ни гаебем бар соң? Минем бер начар эш тә эшләгәнем юк. Китапларым – барысы да институт программы буенча укырга күрсәтелгән китаплар, язган шигырьләрем – барысы да үземчә дөрес шигырьләр»* [Батыршин, б. 150].

Башта аны гомуми камерада тоталар. Берничә көннән ялгыз камерага кертеп ябалар, янына шымчы куялар. Камерада икәү генә булгач, әлеге шымчы Сирингә милли мәсьәлә буенча сораулар бирә, аны сыный. Сирин барысына да Ленинча җавап биреп бара. Өч-дүрт көннән соң, ул шымчыны аннан алып, Сиринне ялгызын калдыралар.

*«Шуннан соң мин дә күп тормадым. Кулга алынуга утыз көн тула дигәндә, начальник мине чакырып алып: “Казаннан башка беркая барырга да рөхсәт ителми”, – дип, шул кәгазьгә миннән кул куйдырды һәм теге китап-кәгазьләрне биреп, кайтырга кушты. “Без чакырсак, килерсең”, – диде»* [Батыршин, б. 151].

Шуннан соң Сириннең күңеленә курку кереп оялый. Аны һәр минут «Мине тагын кайчан чакырырлар икән? Исән калырмынмы икән?» дигән сорау борчый. Бу хәл 1927 елда була. Ләкин соңыннан да, Сирин инде Татиздатта эшли башлагач та, аны берничә мәртәбә НКВДга чакырып, сорау алалар.

1930–1935 еллар – Сириннең иң актив иҗат иткән, көчле трибун, үзенчәлекле, популяр шагыйрь булып танылган чоры.

Ритмик һәм музыкальлек җәһәтеннән нәфис эшләнгән «Киләләр» (1930) шигырендә Сирин, яңа алым кулланып, тормышта үзенең нинди теләк-омтылышлары булса, шуларның барысын да «килә» дип санап чыга да, киләчәкнең чыннан да матур буласына ышанып, *«киләсе көннәрнең көлгәнен күрәсе килә; шул көләч көннәрнең гөлләрен үбәсе килә!»* дигән теләк белдерә. Бу шигырь шулкадәр ихлас күңелдән

язылган ки, аңардан әйтерсең укучыларга бары уңай энергия генә килеп тора төсле.

1930 елда Сирин Татарстан АССР төзелүнең ун еллыгына багышлап, «Татарстан» дигән шигырь язган. Ул анда туган халкының үз республикасы булуы белән горурлануын тасвирлый, республиканың үсүенә шатлана:

*Гөлбакча бу,*
*Гөлләр иле – гөлестан.*
*Урманнары, болыннары – гөлбостан.*
*Кошлар сайрый*
*Үз теленчә, үзлекчә:*
*«Яшәсен, – дип, –*
*Иректе Татарстан!»*
*Ел үсәсен*
*Татарстан ай үсә,*
*Бик түбәннән киләбез без*
*ерактан.*
*Үскән саен*
*колхозлар шау-гөж итә,*
*Үсәр өчен*
*төзелгән Татарстан.*

Сириннең «Яла ягылган дошман тарафыннан...» дип башлана торган шигыре (1930) дә патриотик хисләр белән сугарылган. Үзенең бөтен тормышын, иҗатын туган халкына багышлавын, халкы өчен җан атып яшәвен ул түбәндәге сүзләр белән белдерә:

*Халкым, бөегем минем,*
*пакь чишмәм син!*
*Сиңа хезмәтем, җырым, уйларым.*
*Сине җырлаудан, Сине данлаудан*
*мин һич армадым,*
*мин һич туймадым!*
*Әгәр затсызлар сиңа*
*тел орса,*
*Синең даныңны*
*чәйнәп таратса, –*
*Үлгән тәкъдирдә кабердән*
*торырмын,*
*Явыз дошманны кырырмын,*
*урырмын!*

Туган халкының үзе өчен бик кадерле булуын, аны, үзенең газиз баласы кебек күреп, кимсетүләрдән саклаячагын әйтә:

*Тик син, татарым, –*
*Ярамнан да*
*ярам!*

*Тик син дип янам, –*
*Син – минем балам:*
*Татарга кем дә кем кагылса, авыр,*
*Көлке хәлендә калыр ул, калыр!*

Ул үзенең бөек татар халкы вәкиле булуы белән горурлануын болай сурәтли:

*Сатлыклар түгел – Тукайлар нәселе,*
*Гаспралы нәселе, и бөек татарым!*
*Сез җан атканнан татар диеп,*
*Мин мең бер артык җанымны*
*атарым!*
*Татарым! Татарым!*

Шулай итеп, Сирин үзенең туган халкының патриоты икәнлеген исбатлый.

1920–1930 елларда Сирин мәхәббәт шигырьләре дә иҗат иткән: «Каш астыннан», «Эзләрең» шигырьләре, лирик парчалар... Мәсәлән, бер лирик парчада без романтик геройның түбәндәге халәтен очратабыз:

*Бер күрәмме моңсу күзләреңне, –*
*Ник бәхетсез минем күзләрем?!*
*Шул вакыттан авырыйм, айный алмыйм,*
*Мәңге исерек минем йөрәгем.*
*...Елыйсым да килә, көләсем дә,*
*Ник җырлыйм соң гомер буена?*
*Әгәр күрсәм, шашкан хисләр белән*
*Атылыр идем синең муеныңа.*

Сириннең лирик героена шаяру, кызларны үртәү кебек сыйфатлар да хас. 1933 елдагы бер шигырендә ул, Зәйнәп дигән кызга, шаярып, болай ди:

*Тавык булып син кыткылдап йөрсәң,*
*Әтәч булдым мин дә, Зәйнәбем!*

«Үзбәк кызы “Дәрдем бар”га» әсәрендә яшь күңелнең алгысынуы тасвирлана, шагыйрь оригиналь чагыштырулар куллана:

*Күңлең – моң, саз чишмәсе.*
*Күзләрең – күл, йөзләрең –*
*Җәйнең матур иртәсе.*

Үзбәк халык җыры «Яр-яр!» га ияреп иҗат ителгән «Уйнак яр» әсәре дә, рус шагыйре Есенинга ияреп язылган «Зәңгәр кичтә», «Алсу кофта, зәңгәр күзләр» шигырьләре дә яшьлек, мәхәббәт хисләре белән өретелгән.

1930 елларда Сирин балалар өчен «Кыш»(1929), «Көз» (1929), «Яз» (1929), «Җәй» (1929), «Корыч атлар» (1931), «Тимер юл» (1931), «Бә-ә-ә дә мә-ә-ә»(1931), «Җиләк бакчасы» (1933) исемле кечкенә

генә рәсемле китаплар бастырып чыгара. Аларда шагыйрь балаларны ел фасыллары, табигать, йорт хайваннары, чынбарлык белән таныштыра. «Күккү!» (1930) шигырендә автор, күке тавышын тасвирлап, балаларда туган җир табигатенә карата мәхәббәт тәрбияләргә омтыла. 1930 елда Сирин, халык әкиятенә таянып, балалар өчен «Кеше» дигән поэма яза. Әсәр тирән гуманистик фикер белән сугарылган; анда «Кеше»гә, аның акылына, ерткыч хайваннардан өстен булуына дан җырлана; шагыйрь балаларны чын гуманистик рухта тәрбияләүгә үзеннән өлеш кертә. 1930 елда Фатих Кәрим, татар балалар әдәбияты үсешенә анализ ясаганда, Сиринне дә уңай яктан искә алып китә: «Балалар әдәбияты үсешендә «Демьян Фәтхи, Сирин, Минский, Рөстәм Нади, Ләбиб Гыйльми, Ә. Түрәй кебек иптәшләрнең бу юлда зур гына ярдәмнәре булды», – дип яза [Кәрим, б. 213].

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**


*Батыршин Сирин.* Тормыш хатирәләре // Казан утлары. 2016. № 12. Б. 150–151.

*Кәрим Фатих*. Балалар әдәбияты турында // Әсәрләр: өч томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.



***Шәрипов Әнвәр Мәгъдәнур улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 821.512.145, 82:801.6

***Н.М. Юсупова***

# XX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ ЛИРИК ГЕРОЙ КОНЦЕПЦИЯСЕ

В статье раскрываются особенности развития и траснформации концепции лирического героя в татарской поэзии второй половины XX века. В ходе исследования утверждается, что татарскую лирику данного периода отличает внимание к раскрытию социальных и нравственных проблем, к постижению правды времени, пристальный интерес к личности, к кардинальным проблемам духовной жизни. В результате в татарской поэзии порождается своеобразная литературная модель, которая намечает общечеловеческие каноны бытия, воспевает общечеловеческие, вневременные ценности, выражает эмоциональную реакцию лирического героя на общественно-политические каноны действительности. Выстраивание в лирике такой модели обусловливает трансформацию концепции лирического героя и структурирует различные типы лирического героя. Становление субъективности в татарской художественной словесности второй половины XX века идет по сложному пути лавирования между реалистической, авангардной и романтической парадигмой, что проявляется в том числе и в концепции лирического героя.

**Ключевые слова:** татарская поэзия; концепция; лирический герой; трансформация; парадигма.

The article reveals the features of the development and transformation of the concept of the lyrical hero in Tatar poetry of the second half of the twentieth century. In the course of the study it is argued that Tatar lyrics of this period are distinguished by attention to the disclosure of social and moral problems, to comprehending the truth of time, a close interest in the individual, to the cardinal problems of spiritual life. As a result, Tatar poetry generates a kind of literary model that outlines the universal canons of being, sings universal, timeless values, expresses the emotional reaction of the lyrical hero to the socio-political canons of reality. The formation of such a model in the lyrics determines the transformation of the concept of a lyrical hero and structures various types of a lyrical hero. The formation of subjectivity in Tatar literature of the second half of the twentieth century follows a difficult path of maneuvering between the realistic, avant-garde and romantic paradigm, which is manifested among other things in the concept of the lyrical hero.

**Key words:** tatar poetry; concept; lyrical hero; transformation; paradigm.

1960–1980 еллар – татар әдәбиятының тематика һәм сурәтлелек ягыннан киңәю-тармаклану вакыты, ул поэзиядә яңа сыйфат үзгәрешләре белән билгеләнә. Мостай Кәрим билгеләп үткәнчә, татар милли поэзиясендәге «шартлау»ның икенчесе (беренчесе – 1920 еллар уртасында) нәкъ менә 1960 елларга туры килә [Галиуллин, Йосыпова, 2007, б. 4]. Бу үзгәрешләр үз чиратында лирик герой концепциясендә барган трансформацияне, үзгәрешләрне дә нигезли.

Рус әдәбият белемендә 1960–1980 еллар поэзиясе үсешен, яңа сыйфат-үзенчәлекләрнең башлангычын «цензурага буйсынмаган» шагыйрьләр иҗаты белән бәйләп аңлату яши [Кукулин, 2001, с. 251]. Татар шигъриятендә эзоп-киная теленең активлашуы, шуңа бәйле төстә тәнкыйди башлангычның көчәюе 1960–1980 еллар поэзиясендә яңа тип лирик геройның мәйданга чыгуына этәргеч бирә.

Кимчелекләрне күреп тә әйтә алмау газабын кичерүче, шуңа бәйле үз-үзе белән каршылыкта яшәүче мондый лирик герой тибы беренчеләрдән булып юмористик-сатирик әсәрләрдә аваз салып, соңрак гражданлык лирикасында активлаша һәм иҗтимагый тәнкыйтьне активлаштыра. Әлеге хасият иң беренче чиратта Г. Афзал иҗатына бәйле: шагыйрь гражданлык лирикасы белән сатирик шигърият цикләрендә үз синкретик язу рәвешен, гаять үзенчәлекле, берәүне дә кабатламый торган кеше концепциясен тудыра, үз фикере, тормыш позициясе булган, әмма аны башкаларга җиткерергә яки төзәтергә үзендә көч тапмаган, шуңа бәйле үз-үзе белән каршылыкта яшәүче лирик герой тибы ярдәмендә татар поэзиясенең сурәтләү сферасын үзгәртә [Заһидуллина, 2015, б. 30]. Мисал өчен, Г. Афзалның «Елмаям уйчан гына» (1968), «Тун астында кыюлык» (1969), «Гомер китабы» (1969), «Чабаклар йөзгән Иделдә», «Бигрәк юаш басып йөрдем җирдә», «Канәгатьсезлек хисе» (1979), Р. Фәйзуллинның «Вулканнар бар диңгез төбендә» (1966), Г. Зәйнашеваның «Хаклык диңгезен кичәргә!» (1969), Ф. Яруллинның «Үземә тәнкыйть» (1965), Ш. Анакның «Капма-каршылыклар», Р. Мингалимнең «Гел» һ.б. шигырьләрдә лирик геройның «икегә бүленүе» – үз-үзе белән каршылыкка керүе күренә. Диңгезнең төбендә янартаулар булып та, өстенең тыныч халәттә калуы («Вулканнар бар диңгез төбендә»), күңелендә арыслан ятып та, кулында куян булуы («Чабаклар йөзгән Иделдә») кебек образ-сурәтләр лирик геройның эчке халәтенә ишарә ясый:

*Акны кара диеп мин дә*
*Ялган яклап барыйм микән?..*
*Болганчык су өсләрендә*
*Тыныч кына агыйм микән?..*
*Юк, акмаска тыныч кына!..*
*Ташланырга дулкыннарга!..*

[Татар шигърияте, 2007, б. 147].

Әлеге тип лирик герой 1970 елларда яңа тип лирик геройның формалашуына этәргеч бирә. Ул тормыш авырлыкларын күреп, аны укучыга җиткерүче, буын язмышы өчен үзен җаваплы тоючы, хөр фикерле, халыкның бер вәкиле булган гражданин-лирик герой булып мәйдан даулый. Әлеге тип лирик герой үзенең гражданлык вазифасын ил, халык, милләт, туган җир гамен, ваемын кайгыртуда күрә. Мондый шигырьләрдә, идеологияне тәнкыйтьләүнең үткенлегеннән бигрәк, ил каршындагы җаваплылыкны яшәү мәгънәсе белән бәйләнештә аңлау сыйфаты көчле. Ләкин әлеге тип герой концепциясе

реализм чикләрендә кала алмый, ул авангард эзләнүләргә тоташып, андагы хөр фикерле герой тәгълиматы йогынтысында бара. Мисал өчен, ул М. Әгъләмов иҗатының башлангыч чорында ук язылган «Кош» (1963) шигырендә «төшлектә бер үзе йокламый калган, нечкә бәгырьле» [Әгъләмов, 2001, б. 22] кош буларак тәкъдим ителә.

Мәсәлән, М.Әгъләмовның «Җилле көндәй җиллеләр» (1976) шигырендә беренче укылышта җил образы җепшеклек сәясәте, XX гасыр уртасындагы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр булып кабул ителә:

*Озаккарак китте бугай, озаккарак,*
*Күзен текәп көткән иде һәммә тараф...*
*...чыкты буран – ком бураны,*
*Өермәсен тыялмады.*
*Чыкты болыт актарылып,*
*Офыкларга сыялмады.*
*Килгән иде кояр булып,*
*Бар дөньяны юар булып,*
*Ул яумады...*

[Әгъләмов, 1978, б. 23].

Икенче строфада теткәләнгән наратның, җан биреп, басу уртасына авып төшүе ил халкының якты үзгәрешләргә өмете югалуны шәрехләргә мөмкинлек бирә. Алга таба җил образы шушы үзгәрешләр дулкынында мәйданга килгән яшь буынны бәяләүгә юнәлтелә:

*Кәпәчләрен тезгә салып,*
*Картлар тора көлемсерәп:*
*«Файдасызга очынуны*
*Яшьләргә бер күрү кирәк.*
*Яшьләргә бер күрү кирәк».*
*Халык әнә керфекләрен офыкларга теки кабат:*
*– Озаккарак китте шул, әй, озаккарак...*

[Әгъләмов, 1978, б. 24–25].

Әнә шулай М. Әгъләмов үз буынына бәя бирә, аларның омтылышлары, зур идеаллар белән янып яшәве укучы күңелендә соклану катыш якты бер моң тудыра. Әмма аларның «файдасызга очынуы», җил үткәннән соңгы халәтнең «озаккарак сузылуы» ул өметләрнең аклануына шик тудыра, мондый иҗтимагый вазгыять борчылу уята. «Язгы ояну» (1976) шигырендә үз чордашларын, аларның якты омтылышларын «иртә язда тауда уянган үләннәр», «үзләрендә рәшә уйнаткан үләннәр» итеп тасвирлаган М. Әгъләмов яшәү халәтләрен «вакытлы туңган, тик вакытлы туңган үлән» дип бәяли, якты киләчәккә ышанычларын «якты язга» – якты киләчәккә ышануда күрә.

Бу чор татар поэзиясендәге лирик шигырьләрнең бер катламын эзоп теле ярдәмендә идеологиягә бәя биргән, сәяси кануннарның хаксызлыгын раслаган әсәрләр тәшкил итә, алар еш кына сәяси лирика үрнәкләрен хәтерләтә, әмма тулысынча сәяси лирика кысаларына кереп урнашмый. Әлеге үзгәреш тә үзенчәлекле лирик герой

концепциясе формалашу белән янәшә бара. Мондый шигырьләрдәге лирик герой Такташның икенче чор иҗатында үсеш алган лирик герой концепциясен дәвам итә. Ул ил язмышы өчен үзен җаваплы тойган гражданин-лирик герой кысаларында да калмый, шул ук вакытта кимчелекләрне күреп тә әйтә алмау газабын кичерүче, шуңа бәйле үз-үзе белән каршылыкта яшәүче лирик герой тибын да кабатламый. Бу лирик герой – илдәге вазгыятьне аңлаган, аны башкаларга да җиткерү өмете белән янган, үз тавышын ишеттерү максатын куйган герой. Шуңа да әлеге лирик геройга бәйле шигырьләр сәяси кискенлеге белән аерылып тора, шагыйрьләр эзоп теле алымыннан файдаланган хәлдә дә, империя, кол, император, камчы, кулак кебек киң таныла торган образларга еш мөрәҗәгать итәләр. Мисал өчен, Зөлфәтнең «Тырнак» (1971) шигырендә «Сөргеннән котылган Гарәфи ага Хәсәнов болай сөйләде» гыйбарәсе әсәрне беренче юлларыннан ук иҗтимагый-сәяси дулкынга көйли. Илдәге сәяси вазгыять, шәхес культы, кешеләрне сөргеннәргә озату кебек ил кешеләре кичергән фаҗигалар лирик геройның әрнү хисенә сәбәп төсен ала. Эчке мәгънәгә ия Ачъяңак, Ата Аю, Кыргый Аю образларының бер-бер артлы кулланылышы, аларның баш хәрефләр белән бирелүе һәм ил белән янәшә куелуы шушы вакыйгаларга сәбәпче кешеләргә ишарәли:

*Ә илемнең*
*баш түбәсен*
*Аю*
*Кубарды да атты бер читкә.*
*Кара төндә:*
*«Киен!» – дия-дия,*
*Кемнәр какты җылы ишеккә?*
*(...) Бүтән Аю килде ил өстенә,*
*Кыргый Аю тырнак чыгарды,*
*Ата җинаятьче*
*Илнең баш сөяген*
*Бөек Җиңү өчен кубарды.*
*Кыргый Аю*
*Изге үчен алды.*
*Ә без кем соң, илем? –*
*Кол гына...*
[Зөлфәт, 1990, б. 59].

Кол, баш сөяге кубарылган кешеләр шушы илдә яшәүчеләр төсен ала. Ак болытлар образы исә шушы ил кешеләренең бәхетле тормыш хакындагы олы хыялы кебек кабул ителә, аның югары, ерак булуы лирик геройның әрнүен тагын да тирәнәйтә, кискенләштерә. Иң соңгы строфада ул: «мондый яшәү халәте шушы җәмгыятьтә яшәүчеләр күңелендә үзе дә «үчле Аю тырнагы», үч һәм нәфрәт булып укмаша һәм җавап хисе тудыра» дип кабатлый.

Җәмгыять, сәяси вазгыять проблемаларын күтәрү, тормыш турында фикерләшү татар халкының яшәеше хакында уйлануларга

алып килә. Милли проблеманың куелышы милләтнең тамырларыннан аерылуы, рухи нигезен югалтуы, иманы дәрәҗәсендә булган телгә мөнәсәбәтенең кискенләшүе хакында сөйләшүгә юл ача. Мондый шигырьләрдә лирик герой үз милләтенең киләчәк язмышы өчен борчылып, аның хокуксызлыгына әрнеп мәйданга чыга. Шигырьләрдә ат, тулпар, Идел, дала кебек татар тарихына бәйле образлар киң кулланылышка кереп китә, аерым шигырьләрдә алар милли мәсьәләләр хакында фикер җиткерергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, беренче карашка романтик хисләр хакында сөйләгән Зөлфәтнең «Ай сонатасы» (1965) шигыре шундыйлардан. Шигырь структурасында чәрдәкләнгән ай, яшен суккан имән, кан савып үлгән чаптар ат образлары милли фаҗига булып кабул ителә башлый. Шигырьнең соңгы строфасында «Нишләттең син сабыр Иделемне?» соравы лирик геройның милләт язмышына бәйле чарасызлык чигенә килүе турында хәбәр итә. Шагыйрьнең «Гөл» (1969) шигыре дә шул хакта. Таш, үлән тамыры, ат тавышлары, аларның югалуы ерак гасырлардан килгән милли нигезләрнең онытыла баруы кебек кабул ителә. «Чабата» (1979) шигырендә исә Зөлфәт чабата үрүнең калыбын югалту милли тамырларны оныту буларак шәрехли. Чабата үрү гыйбарәсенең Алып образы белән янәшәлектә кулланылышы шигырьне шушы эчтәлектә укуга көйли.

1920 еллар авангард шигърият традицияләрен дәвам итеп, үстереп әдәби мәйданга чыккан модернистик яңарыш та XX гасырның икенче яртысы татар шигъриятендә лирик герой концепциясен үзгәртеп аваз сала. «Поэзиянең яңаруы шәхеснең яңаруы белән бергә барды, дөресрәге, рухи яңарыш шигъриятнең яңарышына китерде» [Бочаров, 1989, б. 21], – дип билгели бу тенденцияне А. Бочаров. Ул – максималист, романтик-көрәшче лирик герой, шәхеснең хөр рухын, биеклекләргә омтылучы холкын зурлау ягыннан, XX йөз башы татар поэзиясендәге гыйсъянчы-геройны хәтерләтә. Шушы герой яңа идея-фикер, тормышның яңа концепциясен формалаштырырга ярдәм итә: кешенең горурлыгын, рухи хөрлеген, шәхси азатлыгын-мөстәкыйльлеген саклау – кешелеклелекне саклау ул; чикләүләрдән котылу, азат булу, тормышны үзгәртә алу өчен, башта һәр кеше үзен рухи яктан азат итеп тоярга тиеш, дигән фикер белдерелә. Р. Фәйзуллин алып килгән шәхес концепциясе 1960–1980 еллар татар авангард әдәбиятының нигезен тәшкил итә [Заһидуллина, 2, б. 31].

Чыннан да, Р. Фәйзуллин идеологик кысаларга кертеп урнаштырылган, шул чикләрдә үскән-үзгәргән лирик герой концепциясен максималист, кешенең шәхси бөеклеген югары күтәргән көрәшче, романтик лирик герой белән баета. Мисал өчен:

*Мәйдан олы икән:*
*Буының ныкмы дип*
*Сорап тормый икән...*
*Канун, гадәтләрне*
*Чыккан өчен атлап,*

*Кире беткән чиру*
*Китмәк булды таптап...*
*Ә без карыштык.*
*«тамак-өс кенә –*
*Безнең җанга, – дидек, –*
*Булыр кечкенә!»*
*Ә без көрәштек*
*Нәни йөрәк белән!*
[Татар поэзиясе антологиясе, 1992, б. 248].

Нәни йөрәк белән зур көрәшкә кергән лирик герой татар әдәбияты традицияләрен дәвам итеп, мәйданга чыга. Шушы лирик герой «Гадиләргә гимн» (1963), «Кер чайкыйлар кызлар» (1964), «Җанының ваклыгын...» (1967), «Көрәшчеләр» (1968), «Сорады миннән төштә торткын кош» (1979) кебек шигырьләрендә «гомерләре җыр булалган кешеләр – иң бәхетлеләр» дип санаган шагыйрь кеше рухын биеклеккә әйди, югары күтәрелергә чакыра:

*Чын җырларны – җилфердәргә –*
*Биеккәрәк, биеккәрәк*
*Эләргә иде!*
[Татар шигърияте, 2007, б. 239].

Лирик герой иҗат алдына олы максатлар куя, иҗат кешесен кыю, нык булырга, «чын җырларны биеккәрәк күтәреп», хаклык, хакыйкать өчен көрәшергә өнди. «Җанының ваклыгын...» (1967) шигырендә шушы фикер хөрлек көрәше, кылыч, җан ваклыгы кебек образлар каршылыгына җыйнап тәкъдим ителә. Хөр фикерле, кешелекле булып кала алу кеше җанының иң бөек ноктасы югарылыгына күтәрелә.

Интеллектуальлек сыйфаты да XX гасырның икенче яртысы татар шигъриятендә шәхес концепциясенә бәйле ачылып китә, төп игътибар күңел кичерешләреннән бигрәк, зиһен, акыл мөмкинлекләренә юнәлтелә, җәмгыятьтәге, яшәештәге хәл-халәткә каршы тору юлларын кешенең үз, шәхси мөмкинлекләреннән, аң-акылыннан эзләү башлана. Ул «Җиргә таянып, / Күккә омтылган рух»ка ия максималист, кеше акылын югары күтәргән, кешенең бөеклеген җырлаган шәхес булып аваз сала. Беренчеләрдән булып, Р. Харис әсәрләрендә «Прометейның изге утын / Тотып туган чын Кеше» буларак мәйданга чыккан бу герой да яңа идея-фикерне, тормышның яңа концепциясен формалаштырырга ярдәм итә: дөньяның асылын, яшәеш кануннарын кеше билгели, кеше акылы алга илтүче көч хезмәтен үти. Шуңа да мондый лирик герой концепциясенә йөз торткан әсәрләрдә кеше фәлсәфәсе (антропологик фәлсәфә) көчле яңгыраш ала. Бу лирик герой тормыштагы һәрнәрсәне кеше акылы, кеше бәясе барлыкка китерә һәм саклый дип аваз сала. Мисал өчен, Р.Харисның «Өянке» шигырен алыйк:

*Өскә үсмәсен әле, дип,*
*Баш ботагымны киссәң,*

*Мин бит ян-якка үсәм!..*
*Киңлеккә китмәсен, диеп,*
*Ян-якларымны киссәң,*
*Мин куелыкка үсәм!..*
*Куелыкка үсмәсен, дип,*
*Ябалдашымны киссәң,*
*Мин тамыр якка үсәм!..*
*Бәгыреңә чабыймчы, диеп,*
*Казып тамырыма төшсәң,*
*Кабрең өстендә үсәм!*

[Харис, 2006, б. 18].

Гражданлык лирикасы үрнәге булган әлеге шигырьдә өянке образы, бер яктан, милләт язмышын чагылдырырга мөмкинлек биргән образ булып танылa. Риторик диалог формасында өянкенең «янякка үсәм, куелыкка үсәм, тамыр якка үсәм, кабрең өстендә үсәм», дип, үз-үзен раславы аша тоталитар режим шартларында татар милләтенең, гомумән, халыкның яшәешкә омтылышы ачыла. Икенче катламда исә шәхсиләшеп, ул аерым кеше булып кабул ителә һәм кешеләр җәмгыятендә үзен саклап калырга омтылган, үзен раслап яшәгән шәхес төсен ала.

Р. Харисның мондый лирик герой алга чыккан шигырьләре, нигездә, аллегорик сурәтлелеккә нигезләнеп иҗат ителә. Күп кенә шигырьләрдә аллегорик сурәт лирик геройның яшәеш кануннарын билгеләүгә юнәлтелә. Мисал өчен, «Диңгез янында уйлар олылана...» шигырендә диңгез, тау, урман, дала образлары хөрлеге белән бөек, рухының олылыгы белән олпат шәхес булып кабул ителә. Андый шәхесләр үзләре тирәсендәгеләрне дә алга әйди, рухи яктан баета, интеллектуаль яктан камилләштерә дигән фикер әсәрне үтәли кисеп бара:

*Диңгез янында уйлар олылана...*
*Таулар янында алар биекләнә...*
*Урман эчендә алар куелана...*
*Далалаларда алар иркенләнә...*

[Харис, 2006, б. 155].

Мондый шигырьләрдә лирик герой – сөйләүче, аралашучы, әңгәмәдәш кенә түгел, ә бәлки эзләнүче, яшәешнең һәр мизгелен күзәтеп, нәтиҗәләр ясаучы, тормышның һәр мизгеленә бәйле сорау куючы. Классик фәлсәфи лирикадагы хакыйкатьне тапкан лирик геройдан аермалы буларак, ул –уйланучы, икеләнүче һәм үз фикерен сурәт итеп «ясаучы».

И. Юзеев шигырьләрендә Кеше җанын Галәмгә каршы кую сыйфаты интеллектуаль лирик герой концепциясенә үзгәреш алып килә. «Салкын җирне җылыткандыр кеше» (1977), «Әй, кеше» (1976), «Диңгезнең ярлары бик ерак» (1977), «Мин табарга тиеш» (1975) кебек шигырьләрдә шагыйрь кеше һәм галәм фәлсәфәсен тергезә һәм кеше белән Галәмнең һәркайсын мөстәкыйль бербөтен, үзкыйм-

мәтләр буларак аерып чыгара. Аерым әсәрләрдә ул үзен дөньядан аерып куйган лирик герой булып тоела. Мисал өчен, «Гадәт-холкым белән кыр казы мин» (1982) шигырендә «оча, йөзә, сагына, әрни алган» лирик герой үзен «очмаучыларга, сәер, ятларга, аны аңлый алмаучыларга» ят дип белдерә. Мондый әсәрләрдә җанында һәр тереклек иясенә мәхәббәт йөртүче, җир һәм галәм гармониясен тәэмин итүче Камил кеше (камил инсан) итеп иҗатчы күтәрелә. Мисал өчен, «Ай сонатасы» (1971) шигырендә Ай җыры – Ана җыры янәшәлеге хасил була: ана җыры балага көч һәм яшәү бирсә, Ай җыры Җиргә тормыш бүләк итә. Өнә шулай кеше һәм галәм тормышы бербөтенгә әверелә. Шагыйрь җырны, иҗатны романтикларча тормыш-яшәеш чыганагы дәрәҗәсенә куя. «Аның җыры» (1980), «Шигъриятнең хәле» (1989) кебек шигырьләрдә иҗатның җәмгыятьтәге әхлакый кыйммәтләр үзгәрүгә каршы тору мөмкинлеге ачыклана. «Бер җырладым...» (1982) шигырендә иҗатның кыйммәте табигыйлектә дигән фикер ассызыклана.

Шуның белән янәшәдә мондый лирик герой алга чыккан әсәрләрдә кеше рухының бөеклеге, кешенең яшәү көче, ныклыкның тамырлары-нигезе хакындагы уйланулар калкулана. Бу тенденция беренчеләрдән булып И. Юзеевнең «Сакмы йокың, Кеше?» (1962) шигырендә күзәтелә. Авыр хезмәт белән арыган Ана йоклап китә, уйный-уйный баласының карават читенә килеп җитүен сизми кала. Бала егылып төшәм дигәндә, ана кинәт уяна һәм баласын имгәнүдән саклап кала. Әлеге күренеш аша шагыйрь Җир шары һәм кеше мөнәсәбәтләре турындагы зур гомумиләштерүгә килә:

*Әй, син, Кеше, сакмы йокың,*
*Сакмы соң?*
*Кулларыңнан җир шары ычкынмасмы соң?*
*Юк!*
*Кеше хәзер Җир-анадан*
*Көчлерәк.*
*Кеше – ана, ә Җир сабый*
*Төслерәк*

[Юзеев, 1982, б. 44–45].

Шагыйрь Кешене югары күтәрә, аны үз-үзе, гаиләсе, баласы, язмышы өчен генә түгел, гомумән, Җир шары өчен җаваплы дип билгеле. Галәм алдында үзен җаваплы санаган лирик герой кеше рухының бөеклегенә, хөр фикергә, батырлыкка, мәхәббәткә – дан, дөньядагы һәртөрле явызлыкка, шәфкатьсезлеккә, ялганга нәфрәт хисләрен белдерә. Шуңа да әсәрләрдә кешенең бөеклеге, яшәү көче, ныклыкның тамырлары-нигезе хакындагы уйланулар аерым бер әһәмияткә ия. Мәсәлән, «Әйтегез, җан нидән яралган» (1964) шигырендә кешенең кечкенә йөрәге белән Галәм җаны каршылыгы тудырыла. Җан яралган вакытта Җир-Галәмнең бөтен үзлекләрен үзенә сеңдергән, шуңа да ул Җирдәге һәр күренешкә сизгер. Әлеге сурәт ярдәмендә кеше

җанының Галәм белән бердәмлеге турындагы фәлсәфә җиткерелә. «Мин табарга тиеш» (1975) шигырендә буыннар яшәеше, ил язмышы өчен уйлану хәсрәткә әйләнә. Лирик герой үзен үткәннәр һәм киләчәк каршында җаваплы тоя, ләкин буыннар арасында бәйләнешнең өзелүе сызлану уята.

Шул рәвешле, 1960–1980 еллар татар шигърияте, алдагы чорларда ирешелгән традицияләргә яңа казанышлар өстәп, эчтәлек һәм форма ягыннан катлауланугa һәм камилләшүгә килә. 1960 елларда башланган бу яңарыш татар шигъриятендәге эчтәлек үзгәрешенә генә көчле тәэсир ясап калмый, лирик герой концепциясенең трансформациясенә, үзгәрешенә, аның яңа типлары формалашуга, тармаклануына китерә. Нәкъ менә төрле лирик герой типлары XX гасырның икенче яртысы татар шигъриятендә автор фикерен җиткерүнең отышлы юлына әверелә.

**Әдәбият**


*Әгъләмов М.* Исәнме, йөрәк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 160 б.

*Әгъләмов М.* Кан тамырын кистем. Казан: «Рухият» нәшр., 2001. 656 б.

*Бочаров А.* Покушение на мираж // Перспектива – 89. М.: Перспектива, 1989. С. 20–23.

*Галиуллин Т.Н., Йосыпова Н.М.* Басынкы елларның дәртле шигърияте // Татар шигърияте: 1960 – 80 еллар. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 3–26.

*Даутов Р.* Балачак әдипләре. Казан: Мәгариф, 2006. 223 б.

*Заһидуллина Д.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

*Зөлфәт.* Адашкан болыт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 223 б.

Илдар Юзеев: истәлекләр, әңгәмәләр, шигырьләр / төз.: Р. Миңнуллин, Т. Юзеева. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 199 б.

*Кукулин И.* О русской поэзии 1990-х годов. От перестроечного карнавала к новой акционности // Новое литературное обозрение. 2001. № 5. С. 251–253.

Татар поэзиясе антологиясе: 2 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 512 б.

Татар шигърияте: 1960–1980 нче еллар. Казан: Мәгариф, 2007. 319 б.

*Харис Р.* Сайланма әсәрләр: 7 томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. 511 б.

*Юзеев И.Г.* Мәхәббәт китабы: шигырьләр, җырлар, поэмалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 352 б.

*Юсупова Н.М.* Поэзия // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 6 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. Б. 245–272.



***Юсупова Нурфия Марс кызы,***
*филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Г. Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбенең татар әдәбияты кафедрасы профессоры, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге доценты*

УДК 82-2

***Ф.И. Габидуллина***

# Ф. БӘЙРӘМОВАНЫҢ «КЫҢГЫРАУ» ПОВЕСТЕНДА «КЫҢГЫРАУ» ОБРАЗ-СИМВОЛЫ

В статье анализируется повесть Ф. Байрамовой «Колокольчик» в аспекте раскрытия идейно-эстетических функций образа-символа «колокольчик». Основываясь на функциональные особенности понятия «символ», выявляются различные смысловые его оттенки, связанные с основными событиями и судьбами героев данной повести. В связи с этим образом-символом также определяются черты характера основных образов и их действий.

**Ключевые слова:** татарская проза, Ф. Байрамова, колокольчик, тема, проблематика, образ-символ, характер.

In the article the story of F. Bayram's «Bell» is analyzed in the aspect of revealing the ideological and aesthetic functions of the image-symbol «bell». Based on the functional features of the concept of «symbol», its various semantic shades associated with the main events and fates of the heroes of this story are revealed. In connection with this image-symbol, the character traits of the main images and their actions are also determined.

**Keywords:** tatar prose, F. Bayramova, bell, theme, problematics, image-symbol, character.

XX–XXI гасырлар чиге татар әдәбиятын үзенең повесть-романнары, драмалары, публицистик һәм документаль язмалары белән баетып, аның интеллектуаль юнәлештә үсеп китүенә, шулай ук тарихи-публицистик эчтәлекнең тирәнәюенә, үткән һәм бүгенге бәйләнешен гаять бай, төрле алым-чаралар белән ачуга зур өлеш керткән әдипләрнең берсе – Фәүзия Бәйрәмова. Ул күренекле җәмәгать эшлеклесе, галимә буларак та танылу алып, үткен каләме, туры сүзе белән тормышның гаять гыйбрәтле күренешләрен чагылдыруга алына, аларны яшәеш фәлсәфәсе белән тыгыз бәйләнештә укучыга җиткерә. Язучының беренче китабына язган кереш сүзендә күренекле әдип Ә. Еники, аның иҗатын югары бәяләп, телгә талымлыгын, вакыйгаларны җанлы итеп күз алдына бастыра алуын, образларының хәтергә уелып калуын ассызыклап үтә [Еники, 1986, б. 3]. Ә. Еникинең фатихасы уңышлы туфракка төшә, 1980 елларда иҗатка килгән Ф. Бәйрәмова – бүген инде 50 якын китап авторы, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый, шулай ук Һ. Атласи исемендәге премияләр лауреаты. Башлангыч чор иҗатын тәшкил иткән «Болын», «Битлек», «Күл балыгы», «Кыңгырау», «Канатсыз акчарлаклар» кебек әсәрләре татар әдәбиятына талантлы, милләт гаме белән янып яшәүче, кеше яшәешен әхлакый кыйммәтләр яссылыгында оста чагылдыручы язучы килүен хәбәр итә. Шул чорда ул каләмен драматургия өлкәсендә дә сынап карый һәм, нәтиҗәдә, «Аллалар ялгышы, яки Яңа матриархат», «Атылган йолдыз», «Сандугачның балалары», «Безне

онытмагыз» кебек пьесалары дөнья күрә, күбесе сәхнәләргә менә. Җәмгыятьтә үзгәртеп корулар башлангач, Ф. Бәйрәмова милли хәрәкәткә тартыла һәм үзен көчле публицист итеп таныта. Иҗаты да милли эчтәлек белән сугарылып, публицистик яңгыраш ала. «Мәйдан татарларны көтә», «Кара урман» әсәрләре үз чорында җитди бәхәсләргә китерә. Иман юлындагы әдибә алдагы елларда дини эчтәлек белән сугарылган әсәрләре белән киң танылу ала: «Соңгы намаз», «Бәхет ачкычы», «Алыплар илендә» һ.б.

XXI гасырга чыккач, Ф. Бәйрәмова Татарстаннан читтә яшәүче татарлар тормышын өйрәнүгә алына. Төрле төбәкләргә сәяхәт кылу, милләттәшләр тормышы белән якыннан танышу аша Россия дәүләте гасырлар дәвамында татар халкына карата алып барган сәясәтнең ачы нәтиҗәләрен чагылдырган әсәрләре языла: «Караболак», «Кырык сырт», «Нух пәйгамбәр көймәсе», «Гөләйза», «Сибирская цивилизация» һ.б.

Язучы сайлап алган тема-мотивлар төрле булган кебек, карашфикерләрен укучыларга җиткерүнең дә яңадан-яңа алым-чараларыннан иркен файдалана ул. Әдибә иҗаты тәнкыйди башлангыч белән сугарылган, әсәрләрендә романтик сурәтлелекне, шулай ук лирик-психологик, экзистенциональ агымнарны, үткән мәдәният эзләрен, кешенең чиктәш халәттә яшәвен, метафора булып килгән вакыйгаларга иркен мөрәҗәгать итүне һ.б. күрәбез. Әлеге мәкаләдә исә Ф. Бәйрәмованың «Кыңгырау» (1987) повестен шул исемдәге образ-символ чагылышына нисбәтле тикшерүне максат итеп куябыз.

Билгеле булганча, символ әйбер-күренешнең төп эчтәлеген күчерелмә мәгънәдә аңлатучы билге булып тора [Хализев, 2000, б. 3–34]. Аның әдәбиятта киң кулланылышының нигезендә зур гомумиләштерүгә ия булу сыйфаты тора [Ермилова, 1989, б. 4]. Һәр халык символларга мөрәҗәгать итә, әмма һәрберсе бер үк төрле символны төрлечә шәрехли. Бу аңлашыла да, чөнки теге яки бу символны аңлату халыкның тарихи, сәяси, иҗтимагый тормышына бәйле төстә озак еллар дәвамында формалашкан дөнья һәм тел сурәтенә, менталитетына, гореф-гадәтләре, йолаларына бәйле [Закирзянов, 2019, с. 112]. Бу мәсьәләне өйрәнгән А.Ф. Лосев фикеренчә, әйбернең символы, аның гадәти торышыннан күбрәк мәгънәне үз эченә ала [Лосев, 1976, с. 17]. Аңлашылганча, символ бик борынгы чорлардан ук кулланыла, шуңа да аны теге яисә бу мәдәни чорга бәйләп кую үзен акламый. Моңа үз вакытында ук Ю.М. Лотман да мөрәҗәгать итә һәм аның борынгыдан килеп, киләчәккә юнәлгән булуын билгели [Лотман, 1992, с. 192]. Әлеге сыйфатлары ук символны универсаль алым дәрәҗәсенә куя. Шуңа да ул әдәбият-сәнгатьнең үсеш тарихында даими урын алып, эчтәлеге һаман саен байый бара. Бигрәк тә Урта гасырларда символларның роле зур була, һәм, гадәттә, алар әсәрләрдә төп идеяне ачуга хезмәт итә, ә инде Яңа заман әдәбиятында символизм дип аталган әдәби агымны мәйданга китерә [Әдәбият белеме, 2007, б. 171]. «Символизм» төшенчәсе хакында сүз алып барганда, аның ике яссылыкта кулланылуын истә тотарга кирәк: бер яктан, ул –

аерым бер мәдәни җәмгыятьләрдә генә формалашкан дөньяга караш, Яшәешне танып белү системасы. Икенче яктан, әдәби (мәдәни) агым, милли иҗатчылар әдәбиятка алып килгән алымнар тупланмасыннан файдалану. Символлар кеше гомеренең фанилыгын, чиклелеген Яшәешнең гадәти бер кануны – табигатьтә ел фасыллары, көн белән төн алмашыну кебек табигый закон төсле аңлатуга катнашалар [Заһидуллина, 2003, б. 7].

Милли әдәбиятта үзенең тирәнлеге һәм киң семантик кырга ия булуы белән «кыңгырау» образ-символы аерылып тора. Әлеге образ суфичылык чоры шигъриятендә үк очрый. Суфи шагыйрьләр тарафыннан ул Аллаһ турындагы белемнәрне арттырырга чакыручы, дөньяның, җир тормышының бер көнлек булуын искә төшерүче символик образ буларак калыплаштырыла. XX гасыр башында романтик әдәбият үсешенә нисбәтле символларга гаять тирән эчтәлек салынып, мондый эчтәлекле әсәрләр тулы бер агымны – символизмны тәшкил итә [Йосыпова, 2016, б. 44]. Аның уңышлы бер үрнәге булып, Дәрдемәнд иҗаты тора [Саяпова, 2006].

XX гасырның икенче яртысында илдә барган тарихи вакыйгалар шаукымы әдәбияттагы символларның эчтәлегенә үзгәреш кертә. Нәтиҗәдә, татар әдәбиятында кыңгырау образ-символының да эчтәлеге үзгәрә. Бу елларда ул Хәтер символы буларак аңлашыла башлый (Ә. Еники, А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев әсәрләре). Ә инде XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында «кыңгырау» символы милли хәтер буларак та чагылыш таба (Ф. Бәйрәмова, В. Имамов, М. Галиев, Р. Зәйдулла һ.б.).

Әдәбиятта символ төшенчәсенең кулланылышы, аның чагылыш үзенчәлекләре даими рәвештә өйрәнелеп килә. XX гасыр башы татар әдәбият белемендә үк аның үрнәкләре белән Г. Сәгъди, Г. Ибраһимов язмаларында очрашабыз. Ә инде XX гасырның икенче яртысы әдәбият фәнендә һәм яңа гасыр башында бу мәсьәләне Р.К. Ганиева, Й.Г. Нигъмәтуллина, А.Я. Сәяпова, Ч.А. Зарипова-Четин, Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Н.М. Юсупова, Г.Р. Гайнуллина һ.б. өйрәнә.

XX гасыр ахырында язучыларыбыз тормыш хакында сөйләшүне тарихи, фәлсәфи, әдәби аналогияләр белән баету фонында, язучы белән укучының интеллектуаль, акыл яссылыгында сөйләшүен тәэмин итеп, сурәтлелеккә, үзенчәлекле поэтика тудырырга омтылу теләге белән әледән-әле символларга мөрәҗәгать итә. Моның ачык мисалын без Ф. Бәйрәмованың «Кыңгырау» повестендә күзәтә алабыз.

Повестьта «кыңгырау» символик образы көчле позициягә – әсәрнең исеменә чыгарылган һәм ул башлам өлешеннән алып, ахырына кадәр әсәрнең сюжет-композициясен тоташтыруга хезмәт итә. Әсәрдә «кыңгырау» XX–XXI гасырларда Европа һәм бигрәк тә Россия халыклары әдәбиятларына хас булган сәяси эчтәлеккә ия. Э. Лассан фикеренчә, кыңгырау чыңы турындагы текстлар шуны күрсәтә: кыңгырау чиркәү музыка коралы һәм дискурс объекты буларак, Россия җәмгыятендә сәяси вакыйгаларда катнаша һәм билгеле бер мәгънәдә

аңланган социаль идеаллар өчен көрәштә союздаш яки оппонент ролен башкара [Лассан, 2014, с. 63]. Әдәбиятта «кыңгырау» образының мондый төр семантикага ия була башлавы – илдә барган тарихи вакыйгалар, дәүләт эчендә яшәүче һәр милләтнең (икенчел характердагы халыклар буларак бәяләнүче) эчке трагедиясе белән бәйле. Ф. Бәйрәмованың бу повестендә «кыңгырау» кисәтүче һәм һәрвакыт уяу булырга, күптән түгел булып узган зур трагедияләр турында онытмаска өндәүче символ буларак укыла. Моның асылын аңлау өчен әсәрнең эчтәлегенә мөрәҗәгать итик.

«Кыңгырау» повесте – Сталин чоры репрессияләренә дучар булган татар хатын-кызлары хакында. Язучы нахакка гаепләнеп, төрмәгә ябылган һәм анда ачы газаплар кичәргә мәҗбүр булган Айсылу язмышы мисалында татар халкы һәм, гомумән, бөтен ил кичергән трагедияне күтәрә.

Повесть ретроспекция алымына корылган. Әсәр башында Айсылу карчык моннан ярты гасырга якын элек булган вакыйгаларны исенә төшерә. «Кыңгырау» – хатирәләр яңарту чарасы буларак кабул ителә. Аның чыңы Айсылуны гомеренең буеннан-буена озатып бара. Әмма ул җылы истәлекләр хатирәсе буларак түгел, ә шомлы еллар шаукымы рәвешендә Айсылуның хәтерендә яңара. Димәк, «кыңгырау чыңы» – үткән белән бүгенгене тоташтыручы чара да булып тора.

Биредә «кыңгырау» символына бәйле парадокс белән очрашабыз: төп героиня Айсылу – революциягә кадәр үк Казанда Ф. Аитованың кызлар мәктәбен тәмамлый, аннары укытучы булып эшли. Бүгенге көндә дә аны укучылары хөрмәт итә. Авыл халкының яртысы – аның укучылары. Әлеге күрсәткеч беренче рус революциясенең татар хатын-кызлары өчен яңа мөмкинлекләр, аларга мәгърифәт дөньясына юл ачуын ассызыклый. Бу вакыйгалар чолганышында «кыңгырау чыңы» да революция китергән шифалы җилләрнең уңай якка исүен – үзгәрешләргә китерүен сурәтләүгә булышлык итә. Кыңгырау чыңы – Айсылу көн саен ишетеп торган тавыш. Бигрәк тә элегрәк чорда мәктәпләрдә чын мәгънәсендә металлдан яки башка материалдан ясалган кыңгыраулар чыңы балаларны дәрескә чакырган һәм дәрес тәмамлану турында хәбәр иткән. Димәк, бу Айсылу өчен үтә табигый тавыш була. Ул аңа инде күнеккән. Кыңгырау чыңы бу канлы вакыйгаларга кадәр аның өчен яраткан эшенә чакыру буларак кабул ителгән. Мәктәптә укыткан чакта ул сөйгән яры – булачак ире Галимҗан белән таныша. Аларның беренче очрашуы да кыңгырау чыңы белән бәйле. Автор биредә егетнең портретын бик тәфсилләп тәкъдим итә: *«Кара кашлары астыннан яшькелт үткен күзләре карап тора, ничектер яратып, баласытып карыйлар. Йөзе, тәне каракучкыл, әллә җил-яңгырдан шундый төскә кергән, әллә тумыштан шулай. Чәчләре бөдрә-алкаланып, маңгаена ук төшеп тора. Егетнең йөзе, карашы бөркетне хәтерләтә – нык, кырыс, горур, серле-сихерле»* [Бәйрәмова, 2000, б. 164]. Айсылу белән Галимҗан арасында җылы хис барлыкка килә. Алар шундук бер-берсенә гашыйк була. Язучы Галимҗанның

яшь чактагы портретын махсус бирә, чөнки яшьлектәге Галимҗан белән әсәр ахырындагы Галимҗан – ике төрле кеше. Алар арасында 10–15 ел ара гына булса да, әсәр ахырындагы Галимҗан танып булмаслык дәрәҗәдә үзгәргән. Автор шулай нахакка гаепләнеп, зинданда гомер уздыручы кешене сындырулары аның рухи халәтендә генә түгел, тышкы кыяфәтендә дә аермачык сизелүен күрсәтергә тели. Бу вакыйгалар соңрак була, ә әлегә яшьлек еллары... Бу еллар – Айсылу тормышының иң матур чоры. Шуңа күрә повестьнең бу өлешендәге «кыңгырау чыңы» 60 нчы еллар татар әдәбиятындагы традицияләргә бәйле төстә – күңелле вакыйга хәбәрчесе буларак аңлашыла. Әмма бервакыт кинәт бу чың трагик төсмер ала башлый.

Айсылу бер гаепсезгә төрмәгә утыртыла. Монда ул ун ел гомерен уздырырга мәҗбүр була. Иле өчен фидакярләрчә хезмәт иткән, балалар тәрбияләп үстергән укытучы тимер рәшәткәләр артында кала. Әмма яшь хатынның газаплары бу гына булмый. Аның бөтен гаиләсе эзәрлекләнә. Айсылуның ире Галимҗанны чит ил шпионы булуда гаепләп кулга алалар, эштән чыгаралар, квартирларының бер бүлмәсен күршеләренә бирәләр. Үзен 20 елга сөргенгә сөрәләр. Алып китәселәрен Галимҗан сизә кебек: гаиләсен авылга, Өтернәскә, кайтарып кую теләге көчле аңарда. 13 яшьлек уллары Газизҗанның да күзләрендә борчу-сагыш. Ул уйчан, эндәшми, сөйләшми башлый, үз эченә бикләнә. Бу урында Ф. Бәйрәмова тоталитар режимның ни рәвешле яңа буынны үз сүзен әйтергә курыккан «телсезләр» буыны итеп тәрбияләвен ассызыклый. Автор фикеренчә, нәкъ шушы чордан башлап гомуми милләт куркуы тамыр җәя башлый.

Әмма авылда да Айсылулар артыннан күзәтү оештырылган була. Авыл советы рәисе – үзе дә сәясәт корбаны, Айсылуның укучысы Кыяметдин ана белән балага Казанга китәргә куша. Ф. Бәйрәмова Айсылуларның авылдагы тормышын сурәтләп, болай дип яза: *«Августның кояшлы, җылы бер көнендә, әнисе Асылбикә карчыкны елатып, улы Газизҗанны җитәкләп, Айсылу кабат юлга чыга. Үзләренең элеккеге йортларына барып керәләр. Ул төнне дә бөтен Казанны каплап, котырып яңгыр яуды. Ана белән бала яңгыр тавышыннан бераз тынычлангандай булып йокыга киттеләр. Ана белән бала, бер-берләренең сулышын тыңлап, бер түбә астында соңгы төннәрен йоклыйлар иде»* [Бәйрәмова, 2000, б. 173]. Бу юлларда никадәр зур трагедия! Эзәрлекләүләргә, мыскыл итүләргә, нахакка яла ягуларга да түзә алган ана йөрәге өчен иң зур һәм авыр сынау әзерләнгән – газиз һәм бердәнбер баласы белән аерылышу газабы.

Әсәрнең бу өлешендә яшенле яңгыр метафорасына басым ясала. Биредә яшенле яңгыр тоталитар режимны символлаштыра. Ул – мәрхәмәтсез, иң бәхетле гаиләләрне генә суга, гүя илдә бәхетле һәм газапларсыз кеше булырга тиеш түгел. Тоталитар режим вәкилләре бер гаепсез кешедән дә гаеп таба ала, үзе булмаса, гаиләсендәге бер туганыннан яки әби-бабаларыннан гаеп эзләп, инде бу җирдә булмаган кешеләрне дошман итеп, аларның нәселен корыту бернигә

дә тормый. Чыннан да ипле генә тормыш белән яшәп ятучылар өчен мондый гаепләүләр килеп төшү аяз көнне яшен суккан сыман була. Аларның күпчелеге бу гаепләүләрнең кайдан килеп чыкканлыгын, аларны ни рәвешле кире кагарга, үзләрен, гаиләләрен яклар өчен нинди сүзләр әйтергә кирәклеген дә белми. Кешеләр шок хәлендә була. Үзләренең, балаларының киләчәктә сәясәт корбаннары булып игълан ителәселәрен дә әле алар белми. Хакимият вәкилләре кешене көтмәгән вакытта алырга киләләр: төнлә, сабыен кочаклап, тәмле йокысын йоклаганда, җиде төн уртасында алып чыгып китәләр. Бу вакытта кеше ни булганын да аңлап бетерми. Үз-үзен яклау түгел, әле генә нинди хәлгә тарыганын да адекват кабул итә алмый. Ф. Бәйрәмова бу аянычлы төнне болай итеп тасвирлый: *«Яшен сайлап алып кына сукты. Иң бәхетлеләрне, яшәргә омтылганнарны, иң ышанганнарны... Яшен яшьни. Яшен хәтернең бөтен почмакларына барып җитә... Яңгыр, бөтен авыл өстенә җәелеп, котырынып ява. Яңгыр пәрдәсен ярып, тагы яшен яшьни, тагын күк күкри»* [Бәйрәмова, 2000, б. 159].

Шушы төндә Айсылуны төрмәгә алып китәләр. Бу урында «кыңгырау чыңы» авыр хәбәр килүе турында кисәтергә ашыга. Иреннән ваз кичсә, аның чит ил шпионы икәнлеген танып кул куйса – Айсылуны чыгарырлар иде. Күпләр шулай эшләгәндер дә, әмма Айсылу иреннән ваз кичми. Шпион икәнлегенә дә, чит илләр белән хат алыша дигәннәренә дә ышанмый, документларга кул куймый. Шулай итеп, бу гаиләгә халык дошманнары дигән хөкем чыгарыла. *«Аларны кайсын – ун, кайсын – унбиш-егерме елга Себергә сөрделәр, ә балаларын, аерып алып, балалар йортларына, дәүләт тәрбиясенә тапшырдылар. Төрмәләр, каберлекләр, ятимнәр һәм җүләрләр йортлары шыплап тулды»* [Бәйрәмова, 2000, б. 181]. Бу юлларга дистәләгән кешенең аянычлы язмышы сыйган. Әлеге вакыйгалардан соң, илдә җинаять саны артуга да шушы хәлләр сәбәпче була, дип әйтергә тели автор, чөнки исән була торып та, ата-аналарыннан мәхрүм ителгән һәм балалар йортына яки ерак туганнары кулына калган балаларның күңелендә зур җәрәхәт барлыкка килә, алар каты бәгырьле кешегә әйләнә һәм һәр нәрсәгә карата нәфрәт хисе белән яши. Шуның нәтиҗәсендә, алар хакимияткә генә түгел, бар дөньяга каршы көрәш башлый. Күбесе туры юлдан тайпылып, җинаять юлына баса. 1990 елларда тамыр җәйгән бандитлар һәм җинаятьчеләр буыны барлыкка килүнең сәбәпчесе дә әнә шушы вакыйгалар була.

Төрмәдән кайткач та, Айсылуның тормышы җиңел булмый. Ул гаять авыр эшләр башкара. Әмма иң ачысы – улының сугышта хәбәрсез югалганлыгын ишетү. Ире турында шулай ук бернәрсә дә билгеле түгел. Айсылу кабат эзәрлекләнә башлагач, иреннән ваз кичәргә мәҗбүр була, чөнки тормыш дәвам итә. Ул яшәргә тиеш. Хәбәрсез югалган ире һәм баласы өчен булса да яшәргә тиеш.

Айсылу, әнисе киңәше буенча, өч балалы тол ир – Вәлиуллага кияүгә чыгып кына иректә кала ала. Бу, әлбәттә, без әсәр башында очрашкан мәхәббәт хисе түгел. Бу – бары тик уйланылган план. Ирек-

тә булу, исән калу планы. Айсылу Вәлиуллага рәхмәтле. Шулай ук Вәлиулла да, үз чиратында, Айсылуга рәхмәтле, чөнки аңа берүзенә өч баланы аякка бастыру, тәрбияләү бик авыр була. Айсылу исә, элеккеге укытучы буларак, балалар психологиясен яхшы белә, алар белән бик җиңел уртак тел таба.

Күп еллар узгач, Айсылу бер күзе сукырайган ире белән очраша. Биредә без Галимҗанның икенче портретын күрәбез. Ун-унбиш ел элек яшәгән дәртле һәм көч тулы ир затының эзе дә калмаган. Ул шушы еллар эчендә танымаслык булып үзгәргән, карт бабайлар кыяфәтенә кергән. Рәнгыя исемле мәрхәмәтле хатын аны үз канаты астына алган. Ахырда Галимҗан вафат була. Бу урында шул ук «кыңгырау» символы фокус ролен башкара. *«Шулай итеп, хәтердәге ай нуры да өзелде, чулпы чыңы да тынды, ялгыз, хәтерсез буш гомер генә калды»* [Бәйрәмова, 2000, б. 207]. Биредә хәтердәге ай нуры өзелү – соңгы өмет чаткысының сүнүе, чулпы чыңы тыну – хәтернең җуелуы буларак аңлашыла. Хәтерсез тормыш исә буш гомергә тиң. Хәтере булмаган халыкның киләчәге дә юк. Үткәнен оныткан халык инкыйразга юл тота. Дөрес, Айсылу исән, әмма аның тормышы хәзер инде кыңгырау чыңы кебек дәртле һәм күңелле моңга тулмаган, аның тормышы мәгънәсез, хәтер – җуелган, чулпылар – тынган.

Бу урында повестьтагы «кыңгырау» образының тагын бер эчтәлеге ачыла: кыңгырауны Айсылуга сөекле ире Галимҗан бүләк иткән була. Ул Айсылуның чәч тәңкәләреннән, чулпыларыннан кыңгырау койдырып кайта. Эченә кара алтын белән «Айсылу» дип яздырта. Соңгысы, бер яктан, романтик вакыйга буларак укылса, икенче яктан, биредә трагиклык та яшерелгән: чулпыларны эретеп, алардан кыңгырау кою – ул татар хатын-кызларының – милләт аналарының гасырлар дәвамында яшәп килгән милли булмышын юкка чыгарып, татар халкының тамырын чабарга омтылу. Әмма кыңгырауга «Айсылу» исеме языла.

Димәк, татар хатын-кызлары явызлык хөкем сөргән елларда да үз асылын югалтмыйча, барлык көчләрен учка җыеп яши, балалар тәрбияләп, милләтне үстерүен дәвам итә. Элек аларның тавышы чулпы чыңы сыман гына тыныч, чылтырап чыккан булса, хәзер инде алар үз сүзен кистереп әйтә ала, аларның авазы кыңгырау шавы булып яңгырый.

Икенче яктан, бу күренештә башка эчтәлек тә бар. Чулпы – татар хатын-кызларының борынгы бизәнү әйбере. Ул аларның үрелгән озын чәчләренә тагылган. Бүгенге көндә без чулпыларны музейларда гына очрата алабыз. Элек ул сакраль эчтәлеккә ия булган: чулпы чыңы яшь кызлардан начар көчләрне этәрүче булып саналган. Әсәрдә Айсылуның чулпыларын эретеп, алардан кыңгырау кою күренеше шулай ук тарихи үткәнне онытырга тырышу фаҗигага китерә, дигән фикер уята. Галимҗан бу эшне башкарганда төптән уйлап бетерми: чулпының Айсылу өчен никадәр әһәмиятле булуын да, әбиләреннән килгән васыять, хәтер символы булуы турында да уйламый. Нәтиҗәдә, аны борынгылар хәтере җәзалый: гаилә өстенә зур-зур авырлыклар төшә башлый. Айсылуның яман көчләрдән яклаучы чулпылары югала –

илдәге тоталитар режим вәкилләре кыяфәтендәге начар көчләр ябырыла аңа. Аларның беренче корбаны булып, чулпыларга кул күтәрүче Галимҗан үзе җиңелә, ахырдан – Айсылу һәм улы.

Шулай итеп, чулпыларның эретелеп, кыңгырау итеп коелу күренешенә татар халык мифологиясенә якын сакраль эчтәлек салынган. Ф. Бәйрәмова повестендә «кыңгырау» символик образының эстетик мәгънәсе – кешенең дөньяга карашын гармонияләштерү, рухи яктан үз-үзеңне яхшырту юлына кире кайту, һәркемнең җанына мөрәҗәгать итү буларак тәгаенләнә. Шулай ук язучы «кыңгырау» символы аша сак булырга, күптән түгел булып узган аянычлы вакыйгаларны онытмаска кирәклеген кисәтә, хәтта без аны сискәндерүче Хәтер символик образы дип атый алабыз.

Шул рәвешле, әсәрдә «кыңгырау» – төп фокус, ягъни текстның иң тынгысыз җире. Ул төрле мәгънә ала, үзенә төрле өлешләрнең эчтәлеген җыя. Әлеге мәгънә киң формада Хәтер буларак аңлашыла. Ф. Бәйрәмова дөнья әдәбияты дискурсында мәгълүм булган «кыңгырау» символик образының эчтәлеген милли җирлеккә күчереп, татар халкының, татар хатын-кызларының гаделсез сәясәт корбаннары булуын сурәтләүгә ирешә.

**Әдәбият**


Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

*Бәйрәмова Ф.* Күңел карлыгачларым: повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 272 б.

*Еники Ә.* Кереш // *Бәйрәмова Ф.* Болын: повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 200 б.

*Ермилова Е.В.* Теория и образный мир русского символизма. Москва: Наука, 1989. 176 с.

*Закирзянов А.М.* Современное татарское литературоведение: традиции, закономерности и новые поиски. Казань: ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 2019. 372 с.

*Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 255 б.

*Йосыпова Н.М.* Габдулла Тукай шигъриятендә символик образлылык // Фәнни Татарстан. 2016. № 4. Б. 43–50.

*Лассан Э.* Колокол как политической символ русской культуры // Политическая лингвистика. 2014. № 2. С. 62–70.

*Лосев А.Ф.* Проблема символизма и реалистическое искусство. Москва: Искусство, 1976. 367 с.

*Лотман Ю.М.* Символ в системе культуры // Избранные статьи в трех томах. Том 1. Статьи по семиотике и типологии культуры. Таллинн: «Александра», 1992. С. 191–199.

*Саяпова А.М.* Дардменд и проблема символизма в татарской литературе. Казань: Алма-Лит, 2006. 246 с.

*Хализев В.Е.* Теория литературы. Учеб. 2-е изд. М.: Высш. шк., 2000. 398 с.



***Габидуллина Фәридә Имаметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты доценты*

УДК 82.091

***Ә.Р. Мотыйгуллина***

# Н. ЯҺУДИННЫҢ «АТЛЫ КАЗАКЛАР» РОМАНЫ: ТАТАР КАЗАКЛАРЫ ТОРМЫШЫНА БЕР КАРАШ

Статья посвящена изучению темы казачества в татарской национальной среде Оренбурского края. Рассматривая исторические стадии формирования татарского казачества как особый этнической общности на основе исторических, художественных и публицистических источников, приводятся сведения об укладе жизни казаков деревни Новочеркасск Оренбуржья, формах воинской обязанности, особенности организации их службы и быта.

В историческом аспекте изучается летопись деревни Новый Черкас Оренбургского края. Основное внимание уделяется анализу романа Нафика Ягудина «Конные казаки» (1941), где автор описывает события из жизни героя произведения Минлебая на фоне коренных жителей деревни. Также знакомимся с эпизодами сохранения народных традиций в семьях казаков-татар.

**Ключевые слова:** роман, национальная среда, уклад жизни казаков, народные традиции, персонаж, литературная условность.

The article is devoted to the study of the phenomenon of the Cossacks in the Tatar national environment of the Orenbursky region. Considering the historical stages of the formation of the Tatar Cossacks, as a special ethnic community, on the basis of historical, artistic and journalistic sources, information is given about the way of life of the Cossacks in the village of Novy Cherkassk, Orenburg region, the forms of military duty, the features of the organization of their service and life. In the historical aspect the chronicle of the village of Novy Cherkas in the Orenburg region is studied. The main attention is paid to the analysis of Nafik Yagudin's novel «Equestrian Cossacks» (1941), where the author describes the events from the life of the character of Minlebay's work against the backdrop of the indigenous inhabitants of the village. We also get acquainted with the episodes of the preservation of folk traditions in the families of Cossack Tatars.

**Keywords:** novel, national environment, way of life of Cossacks, folk traditions, character, literary convention.

Төрле төбәктә яшәүче, төрле катлау кешеләренең язмышы татар әдәбиятында даими яктыртылып торса да, әдәбиятта татар казаклары язмышы турында язылган әсәрләр читтәрәк калып килә. Әлеге теманы эпик киңлеккә күтәреп, роман кысаларында тасвирлаучы – Нәфыйк Яһудин. Аның «Атлы казаклар» романы – татар дөньясында аз билгеле, әмма ил иминлеге өчен гаять әһәмиятле булган хәрбиләрне тәрбияләп үстерү мәсьәләсен күтәргән әсәр.

Романның язылу һәм басылу тарихы әдипнең язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Әмма авторга әсәрнең басылып чыгуын күрергә насыйп булмый.

Ул Оренбург өлкәсе Яңа Черкас авылында туган. Яшьли ятим калган, шуңа күрә җәй көннәрендә авыл көтүен көтеп, кыш көннәрендә

бай авылдашларына ялланып эшләп тамак туйдырган. Өч ел Каргалыда балалар йортында тәрбияләнгән. 1928–1930 елларда Оренбург педагогика техникумында белем алып, аннары ике ел башлангыч мәктәп мөдире булып эшләгән. 1932–1936 елларда Казан дәүләт педагогия институтында Шәйхи Маннур һәм Сибгать Хәким белән бер төркемдә укыган. Институтны тәмамлагач, Әтнә районы Олы Мәңгәр авылына мәктәп директоры итеп билгеләнгән. Сугыш башланганда Олы Әтнәдә район мәгариф бүлегендә инспектор булып эшләгән. Сугышта катнашкан. 1942 елның июленнән – «Ватан өчен» исемле фронт газетасында корректор. Җәрәхәтләнеп, госпитальдә дә ятып чыккан. Шулай да яңадан сафка кайтып, 1945 елга кадәр фронтта булган. 1946 елда Әтнәгә кайтып эшли башлаган. 1949 елда Башкортстанга күчеп киткән һәм соңгы көннәренә кадәр шунда яшәгән.

1930 елларда Н. Яһудинның күпсанлы хикәяләре һәм очерклары «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналында басылып чыга. «Атлы казаклар» романын 1939–1941 елларда яза. Аны бастырып чыгарырга әзерләү сугыш башланган чорга туры килә. Шуңа күрә кулъязма рәвешендә калган роман турында аны тикшерү-бәяләү вакытында язылган тәнкыйди мәкалә-язмалар гына сакланып калган. Әсәрне, беренчеләрдән булып, М. Әмир, А. Шамов, М. Максуд һ.б. укыйлар һәм бәя бирәләр. Алар әсәрнең тематик яңалыгын да билгеләп уза, авторның әдәби осталыгын да бәяли, шунда ук романның кытыршы якларын да күрсәтәләр. Аларның кайберләре, әйтик, «диалогларны аз бирү, тасвирлау урынына сөйләп узу» кебек җитешсезлекләр әле дә күзәтелә [Шамов, 2017, б. 83]. Әмма тематик төрлелек ягыннан караганда, татарлар арасындагы казаклар язмышын ачу, аларга махсус әдәби әсәр багышлауны әдипнең әдәбият тарихына керткән яңалыгы дип бәяләү дөрес булыр.

Роман «Казан утлары» журналының 2017 елгы 11 нче санында басылып чыга. Барлык материалларны җыючы, әсәрнең төп нөсхәсен карап, төзәтеп чыгып, журналга тәкъдим итүче – Нәфыйк Яһудинның улы Марс.

Әсәрнең исеме гадәти булмавы белән аерылып тора. Казак сүзенең этимологиясенә игътибар итсәк, аны төрлечә аңлатуларга тап булабыз. Халык арасында таралган гыйбарәләрдән «Нәрсә атлы казак шикелле басып (катып) торасың?» дигәне сакланган. Әдәби әсәрләрдән Г. Исхакыйның «Зөләйха»сында атлы казаклар килү турында хәбәр ителә. Кайда гына очраса да, татар телендә *казак* сүзе хәрби юнәлеш белән бәйләп карала. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә сүзнең өч төрле аңлатмасы бирелә. Шуларның икесендә безне кызыксындырган аңлатманы очратабыз: «1. XVIII йөзләрдә Россиянең Дон, Кубань, Терек, Оренбург өлкәләрендә махсус гаскәри частьларда хезмәт иткән өчен җирдән льготалы файдаланган хәрби сословие вәкиле. Шушы катлау вәкилләреннән торган хәрби частьта хезмәт итүче рядовой. 2. Элеккеге хәрби өлкәләрдә туып үскән крестьян. *Дон казаклары*» [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 1979, б. 20].

Күреп үткәнебезчә, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә дә әлләни киң мәгълүмат юк. Бу исә хәрби кешеләрне әзерләү эшенең, бер яктан, сер астында булуын дәлилләсә, икенче яктан, казак дигәндә өлгер, җитез һәм каршылыклы качакларның да күздә тотылуын онытмаска кирәк. Дон казаклары язмышын өйрәнеп, махсус китаплар язган А. Гордеев биргән белешмәләрдә дә казакларның иң элек югары катлау хатын-кызларының иминлеген саклап, далалар аша озатып бару өчен җыелган егетләр төркемнәре буларак оешуларына басым ясала. Автор аларны, урыннарына карап, төрлечә атап йөртүләрен билгеләп үтә: «черными клобуками, эшкетинами, бигерами, эчкенами, казаками, черкасами и т.д.» Ә чик буен саклаучы нугайларны казаклар яки нократлар дип атаганннар [Гордеев, 1992, т. 1].

Рус әдәбиятында һәм публицистикасында казаклар темасы шактый тирән яктыртыла. Казаклар тормышын чагылдырган зур күләмле әсәрләрне А.С. Пушкин («Казак», «Капитанская дочка», «Под буркою казак, Кавказа властелин…»), Н.В. Гоголь («Тарас Бульба», «Вечера близ хутора Диканьки»), Л.Н. Толстой («Казаки»), М.Ю. Лермонтов («Казак», «Казачьей колыбельной песни»), К. Рылеев («Наброски поэмы из кавказского военного быта»), С. Нечаев («Воспоминание»), А. Шидловский («Гребенский казак»), Е. Хамар-Дабанов («Проделки на Кавказе»), Н. Мартынов («Гуаша», «Герзель-Аул»), Г. Семенихин («Новочеркасск»), А. Серафимович («Железный поток»), И. Бабель («Конармия»), П. Загребельный («Я, Богдан» (о Богдане Хмельницком)), К. Седых («Даурия»), М. Шолохов («Донские рассказы», «Тихий Дон», «Поднятая целина» һ.б.) Хәтта В.И. Даль үзенең язучылык юлын «Казак Луганский» тәхәллүсе астында башлап җибәрә. Ул XIX гасырда Уралда яшәгән казакларның тормышын чагылдырган «Уральский казак» тарихи-этнографик очеркын тәкъдим итә. Хезмәт тикшеренүчеләр арасында аеруча зур кызыксыну уятып, аның нигезенә салынган казакның характер үзенчәлекләрен ачуга мөнәсәбәттә күпсанлы бәхәсләр кузгала. Очерк үзәгенә куелган Маркиан Проклятов – хәрби хезмәттәге казак тормышының барлык якларын ачып биргән образ. Шуңа күрә тикшеренүчеләр В.И. Дальның тасвирый осталыгын, милли характерны ачу алымнарын югары бәялиләр [Даренская, 2017, с. 374].

Югарыда аталган әдәби әсәрләр тикшеренүчеләрнең игътибарын һәрвакыт җәлеп итеп килгән. Казаклар темасын эзлекле өйрәнеп, А.А. Гордеевның дүрт томнан торган күләмле «Казаки» дигән хезмәтен үзәккә алып, Ян Сумэй һәм Н.В. Лукьянчикова казакларның килеп чыгышын бер системага салырга омтылып карыйлар. Әйтик, А.А. Гордеев *казак* сүзенең этимологиясен өйрәнү барышында түбәндәгеләрне ачыклаган: фарсыларда казаклар дип – казна тарафыннан түләүле хезмәттәгеләрне (газ-ак), гарәпләрдә пәйгамбәр законнарын һәм хаклыгын яклап көрәшүче җайдакны атаганнар, монгол телендә *казых* яки *казак* сүзе «ирекле көрәшче»не аңлаткан. Тикшеренүчеләр фикеренчә, «анализируя предложенные объяснения происхождения

названия «казак», отмечаем, что множественность предлагаемых вариантов отражает, на наш взгляд, специфические взаимоотношения казачества с государством: стремление к воле, независимости – служба. Так казаки были наиболее известными землепроходцами, казаки защищали русские земли на границах от вторжений. В то же время с казачеством связаны события наиболее крупных восстаний [Ян Сумэй, Лукьянчикова, 2020, с. 122]. Моннан тыш казаклар тарихын өйрәнүчеләр аларның елдан-ел оешып, берләшеп баруын ассызыклый: «К началу XX в. в России существовало одиннадцать казачьих войск: Донское, Кубанское, Терское, Астраханское, Уральское, Оренбургское, Семиреченское, Сибирское, Забайкальское, Амурское и Уссурийское» [Лаптева, Рожкова, 2012, с. 65].

Күреп үткәнебезчә, казак сүзе хәрби юнәлеш белән бәйле. Татар халык авыз иҗатында казаклар белән бәйле җырлар сакланган. «Атлы казакъ, татар, башкорт, калмык (ойрот) полклары Рәсәйгә 1812 елгы Ватан сугышында да зур ярдәм иткән, шуның турында татар халык фольклорында, җырларында мондый юлларны таба алабыз:

*Казак китә, озатыйк*
*Ком аякка җиткәнче;*
*Кояш баеп, эңгер кабар,*
*Без аерылып киткәнче.*
*Казак булып китеп барам,*
*Кара каеш билләрдә;*
*Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз*
*Туып-үскән илләргә»*

[Галимҗанов, Безнең гәҗит. Интернет-ресурс].

Татарларда казак язмышы хәрби хәрәкәтләр белән бәйләп карала. Оренбург өлкәсе Россиянең иминлеген саклауны тәэмин итүче төбәк буларак мәгълүм. Шушы өлкәнең Яңа Черкас авылында дөньяга килгән, балачак елларын уздырган Нәфыйк Яһудин үзе туып-үскән җирлекне «Атлы казаклар» романында (1941) сурәтли. Яңа Черкас авылы Оренбург өлкәсендә мәдәни яктан да, белем бирү системасы ягыннан да аерылып тора. Авылның беренче нигез ташларын 1743 елда есаул Черкасов һәм казак Владимиров сала. Шул ук исемдәге Новочеркасск шәһәре Ростов өлкәсендә дә бар. Ул 1805 елда атаман Матвей Платов тарафыннан төзелә. Рус язучысы, журналист Геннадий Семенихин шул шәһәрдә туып үскәнлектән, шәһәргә нигез салучы М. Платов образын үзәккә куеп, «Новочеркасск» әсәрен (1977) иҗат итә.

Ике әсәр дә казаклар тормышын чагылдыруы белән әһәмиятле. Тарихи мәгълүматлардан күренгәнчә, Дон казаклары, Зопорожье казаклары белән беррәттән, Оренбург казаклары да булган. Аларны кайбер чыганакларда Урал казаклары дип атау да очрый.

«Ни өчен казакларны Оренбург төбәгендә яшәүче татарлар арасында гына тәрбияләгәннәр соң?» – дигән сорау туа. Без аның бер-

ничә сәбәбен күрсәтә алабыз. Беренчедән, патша Россиясе вакытында Оренбургта Неплюев исемендәге кадет корпусы ачыла. Анда укучыларга башка фән нигезләре белән беррәттән, татар телен өйрәтүгә зур игътибар бирәләр. Татар әдәбияты тарихында беренче басылып чыккан хрестоматияләр дә шушы корпуста укучыларны татар фольклоры, мәдәнияте белән таныштыру өчен языла [Фатеев, Зайцев, с. 102]. Икенчедән, «Оренбургтагы кадет корпусы тарихта зур эз калдырып, татар телен укыткан шәхесләре белән аерылып тора. Бу училищеда озак еллар эшләгән М. Бекчуринның 1859 елда дәреслеге басыла һәм ул 1869 елда кабат дөнья күрә» [Сафиуллина, 2001, б. 21].

Моннан тыш Оренбург төбәге татар әдәбиятына Мирхәйдәр Фәйзи, Дәрдемәнд кебек классик язучылар да бирә. Татар шагыйре Г. Тукайны да тормыш җилләре шушы якларга китереп ташлый. Оренбург өлкәсендәге татарлар язмышын өйрәнгән, Парижда яшәп иҗат иткән дон казагы А.А. Гордеев фикеренчә, татар казаклары үзләренең телләрен һәм ислам традицияләрен саклаганнар. Моның ике сәбәбе булган: беренчедән, Җаек казакларында чит диндәге кешеләрне үзләренекенә күчерү омтылышы булмаган. Икенчедән, татар казаклары бистәләргә тупланып, бер-берсе белән аралашып яшәгәннәр (Глининский, Мустаевский, Мухорский, Мухрановский Озерский – шундыйлар.) Бу якларга (Җаек ягына) Казан артыннан күчеп килүчеләр дә үзләренә якын булган дини, мәдәни традицияләр һәм тел сакланган мохиткә килеп эләккәннәр. Җаек татар сәүдәгәрләре өчен икътисади яктан да уңайлы урын булган. Моннан тыш Җаекта 4 мәдрәсә, татар класслары, әйләнә-тирә авылларда да күпсанлы мәктәпләр эшләп килгән. Монда Россиянең күп шәһәрләреннән – Самара, Саратов, Оренбург, Әстерханнан укырга килгәннәр. Монда Г. Тукай белем алып, шагыйрь булып җитешкән. К. Мотыйгый, Г. Кариев, Н. Җиһанов, Г. Кайбицкая, С. Зарова татар театры, журналистикасы, музыка сәнгате үсешенә зур өлеш керткәннәр [Гордеев, Интернет-ресурс].

Шушы төбәктән чыккан Н. Яһудин үзенең «Атлы казаклар» романында Яңа Черкас авылы кешеләренең XIX гасыр ахыры – XX гасыр башындагы тормышын тасвирлый. Әдип авыл халкының мәдәни, иҗтимагый, рухи яшәешен колачларга омтыла. Романның үзәгендә казак язмышы булып, барлык вакыйгалар Миңлебай исемле казак белән бәйләп бирелә.

Әсәр Сабантуйга әзерлек вакыйгалары белән башланып китә. Милли бәйрәмнең нигезен татарча көрәш, ат чабышы тәшкил иткәнлектән, автор шул күренешләргә игътибарын күбрәк юнәлтә. Гомергомергә янәшә яшәгән ике гаилә башлыгы Хисамый белән Җәләй карт көч сынашырга җыена. Шуңа күрә Сабантуйга әзерлек эше психологик яктан киеренке итеп сурәтләнә. Ул бил алыш, көч сынашудан бигрәк, ике ир-ат арасындагы үзара аңлашуны, бер-берсенә юл куюны, хәтта көрәшнең фәлсәфи асылын ачудан гыйбарәт.

Сабантуйдагы көрәшнең иң матур тасвирын автор ир-атлар бәйгесе аша җиткерә. Әсәрдә тасвирланган көрәш, көч сынашудан

бигрәк, характерны сынау, кешенең эчке дөньясын ачу чарасы буларак тасвирлана. Озак еллар көрәш батыры булып килгән, хәтта Оренбургта мәйдан тоткан Җәләй сабыр холыклы кеше итеп күрсәтелә. Ул көрәш серләрен тирән белүче буларак башкаларга юл куя, шул ук вакытта үз мәнфәгатьләрен кайгыртып та артык таушалмый. Оренбургтан килгән Җаппар пәһлеванны Хисамый белән көрәштерә. Шуңа күрә ир-атлар көрәшендә Хисамый батыр калса да, Җәләй үзенең рухи яктан өстен булуын аңлый.

Сабантуйның тагын да кызыклы бәйгесе – ат чабышы. Авыл кешеләре үзләренең чабышкыларын алдан әзерли. Җәләй картның чабышкысында Миңлебай утыра. Әле генә көрәштә җиңелгән Гарифҗан белән алар тагын ярыша. Ат белән идарә итүдә Миңлебай барысын узып, беренчелеккә чыга. Әмма җиңүләр артыннан Хисамый гаиләсен борчу-мәшәкать тә көтеп тора. Бил алышуда өстен чыккан Хисамый җәмгыять кануннары алдында көчсез, дигән тормыш антитезасына тап булабыз. Шул көнне үк аның улын хезмәтчелеккә алып китәләр. Дәрәҗәле казаклар арасына керү өчен, ата-ана баласын 10 яшеннән хәрби хезмәткә әзерли башларга тиеш. Бу исә ел саен казнага 10 сум акча күчереп бару дигән сүз. Ә Хисамый соңгы өч елда ул акчаны түли алмаган. *«Закон буенча, һәрбер казак үзенең улын кече яшьтән үк патша хезмәтенә әзерләргә тиеш. Әгәр дә ул моны берьюлы гына алмый икән, ул ун яшькә җиткәннән алып егерме дүрт яшенә җиткәнче елына ун сум хисабыннан казна банкына акча сала барырга бурычлы санала. Бу акчалар хезмәт итәргә барачак яшь казак егетенә ат, ияр, камчы, хезмәткә бару өчен атап тегелгән яңа чикмән, итек һәм башкаларны сатып алу өчен тотыла. Әнә шул билгеле сумманы да үз вакытында түләп бара алмаучы була икән, аның улын бирәр бай казакка эшкә бирәләр»* [Яһудин, 2017, б. 11–12]. 14 яшьлек улы Миңлебайны гаиләдән аерып, авыл алпавыты Котырык Муллагалиенә хуҗалык эшләренә бирергә мәҗбүрләр.

Миңлебай – Хисамыйның олы улы. Аның артында тагын икесе – Гатау белән Барый – үсеп килә. Шуңа күрә автор казак язмышын күрсәтүне дә Хисамый гаиләсенә йөкли. Кайчандыр шул юлны узган ир, кануннарга буйсынып, казачиның тышкы портретын күзалларга ярдәм итә:*»Чын-чынлап казачи булу өчен нәрсә кирәк? Көмеш кашлы ияре, җиз саплы камчысы, чуклы йөгәннәре белән чуклы ат, бүресен дә, куянын да тота торган озын танаулы эт, шуның өстенә тормыш итүеңнең рәте-башы булырга тиеш»* [Яһудин, б. 9].

Миңлебай берничә буын казаклар тәрбияләнгән авылда туып-үсә. Шуңа күрә ул шул ук традицион рухта тәрбияләнгән булуы белән дә, менталь яктан да аерылып тора. Ләкин аның ата-анасының казнага акча күчереп бара алмавы гына малайны хезмәткә әзерләүне туктатмый. Яңа Черкас авылы кешеләре яшь буынга хәерхаһлы. Авыл старостасына да казакларның җыелу, өйрәнү урыннарын, вакытын алдан белеп, хәбәр итеп торалар.

Ярлы гаиләдән чыккан булуга да карамастан, Миңлебайның үз аты бар. Ул хәрби өйрәнүләргә шуңа атланып бара. Гомумән, казаклар, аларның җитәкчеләре, атаман, аның ярдәмчеләре – барысы да атта йөри. Шуңа күрә автор казак белән беррәттән атны да әсәр исеменә чыгарып, «Атлы казаклар» дип куйган.

Атлы казак булу – яшьләр өчен дәрәҗә дә, кеше арасында абруй да. Казак хезмәтенә әзерләнүчегә үз халкының гореф-гадәтләре, йолалары да чит түгел. Барлык яшь егетләр кебек үк Миңлебайның да яраткан кызы бар. Әмма ул – гадәти кыз түгел, ә ата-аналарның ризалыгы белән колагы тешләнгән кыз. Ягъни төрки халыкларда таралган йола буенча, балаларны кече яшьтән бер-берсенә ярәшеп куйганнар. Шулай итеп, еллар дәвамында аларның гаиләләре бер-берсен өйрәнә, ярдәмләшеп яши, киләчәктә туганлашуны, нәсел җепләрен бергә бәйләүне көтә.

Бу мәсьәләләрне автор Миңлебай белән Мәрьям арасындагы мөнәсәбәтләр аша ача. Мәрьям – Җәләй картның бердәнбер кызы. Ул башка авыл кызлары кебек үк хуҗалык эшләреннән азат түгел. Аны автор әтисе белән болында печән әзерләү вакытында тасвирлый: «*Мәрьямнең кояшта янган бит урталары, өлгереп пешкән пар алма шикелле, кып-кызыл булып янып торалар иде. Ап-ак яулыгын артка каерып бәйләгән. Чит-читләре зәңгәр белән каелган кесәле, гармун итәкле ак алъяпкычы Мәрьямнең нечкә гәүдәсен килешле генә тулыландырып тора»* [Яһудин, 2017, б. 27].

Мәрьям – Миңлебайның рухи дөньясын ачарга ярдәм итә. Алар арасында дини кануннар таләп иткән мөнәсәбәтләр саклана. Шул ук вакытта егет мәхәббәт хисләренең сагында торучы буларак та күрсәтелә. Печән әзерләү вакытында су буена төшкән Мәрьямне Гарифҗан күреп алып, аңа үзенең хисләрен аңлатырга тели. Әлеге очрашуны читтән яшеренеп карап торган Миңлебай аларның арасына керә, кызны яклый. Шул вакытта егет белән кызның романтик очрашуы, бер-берсе белән аралашуы да тасвирлана: *«Мәрьямнең шатлыгы эченә сыймый иде. ... кыюсыз гына Миңлебай янына килде. ...Ә Миңлебай, барысын да аңлыйм, сүзнең кирәге дә юк инде хәзер, дигән шикелле елмайды да аның алъяпкыч бавы кысып торган нечкә биленнән иләп кенә кочаклап алды. Бу – ничәмә еллар буена сөешеп, хатлар аша һәм төннәрен тәрәзә пыяласы аркылы гына вәгъдәләр бирешеп йөргәннең соңында – беренче мәртәбә шулай бер-берсенә якын килү, беренче мәртәбә шулай тиңе булмаган ләззәт һәм рәхәтлек табу иде»* [Яһудин, 2017, б. 30].

Яшьләр арасындагы хисләрне ачу чарасы буларак хатларга зур урын бирелә. XIX гасыр уртасында бу – иң үтемле чара, шул чор әдәбиятында да (М. Акъегетзадә. «Хисаметдин менла» һ.б.) уңышлы алым. Моннан тыш егет һәм кыз арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салуда туган-тумачалары да катнаша. Бу исә Миңлебайга хәрби өйрәнүләр вакытында рухи яктан җиңеллек алып килә.

Романда авыл тормышын сурәтләүгә зур урын бирелә, авыр физик хезмәт бәрабәренә берәүләрнең байлык җыюы, ә башкаларның

очын очка ялгап яшәве сурәтләнә. Н. Яһудин күрсәтергә омтылган милли бизәкләр тормыш авырлыкларына күмелеп, төссезләнеп тә кала. Милли асылны ачу барышында әдип татарлар белән даими аралашып яшәгән башкорт халкы вәкилен дә читтә калдырмый. Миңлебай белән бергә Муллагалигә башкорт Акмырза да хезмәт итә. Алар авыр эш белән генә ялыкмыйлар, ә хуҗаларның түбәнсетеп каравы, әледән-әле төрлечә кыерсытуларыннан да җәфа чигәләр. Гарифҗан Миңлебайның маңгаена каткан кизәк ата, ә үзен салкын су белән коендыргач, Муллагалинең карт хатыны Хәят тә аны кимсетә, җәберли. Хезмәткә килүчеләрне сарык бәрәннәре арасында яшәтү, һәртөрле түбәнсетүләр аларда рухи һәм физик кимсенү хисе тудыра.

Әсәрдәге тел-сурәтләү чаралары автор игътибарының үзәгендә. Ул һәр бүлекне, геройларның кичерешләрен табигать белән, әйләнә-тирә мохит белән бәйләп сурәтләргә омтыла. Миңлебайның авыр тормышын, Котырык Муллагали йортында кичергән газапларын бөтен авыл өстенә төшкән бәла-казалар белән чагыштырып, Н. Яһудин кыш алып килгән мәшәкатьләрне дә бирә. *«Кышкы ачы җил котырына. Ишегалларын әйләндереп алган читәннәр яки такта коймалар селкенгәләп, үзләренең хәлләре өчен кемнәргәдер ләгънәтләр укыган шикелле итеп, рәнҗеп һәм калтыранып утыралар. Бик нык тузгытып җибәрелгән карлар, бер-берсен узарга теләгән шикелле, очсыз-кырыйсыз киң дала буенча сибелеп йөриләр-йөриләр дә авыл ярлыларының кечкенә өйләрен һәм читән алачыкларын – Котырык Муллагалинең дала уртасында кышлап калган печән һәм ашлык кибәннәрен күмгән шикелле үк итеп – күмеп китәләр»* [Яһудин, 2017, б. 22].

Миңлебайның хезмәте дә табигать мизгелләре белән чагыштырып, гомумиләштереп бирелә: «*Җаек сулары өзлексез агып торган кебек, Миңлебайның көннәре һәм еллары да, бер-берсенә үрелеп, әнә шулай акрын гына үтә тордылар»* [Яһудин, 2017, б. 26].

Көз көнен автор геройлары өчен авыр вакыт буларак тасвирлана: «*Көз. Печән эшләре күптән беткән һәм онытылып бара инде. ...Муллагалинең Карбыз тавы битендәге утыз алты дисәтинә җире көзге чәчүгә калдырылган иде. Акмырза, Петлюк һәм Миңлебай, ике атнадан бирле әнә шул җирне сөреп, авылга бөтенләй кайтмыйча, салам куышта яшиләр. ...Миңлебайның хезмәткә бара торган аты да шунда үзе белән, ләкин ул аны җикми дә, атланмый да* [Яһудин, 2017, б. 31].

Миңлебай кышын үгезләр җигеп, печән, салам ташый, язын, көзен җир сөрә, җәен печән чаба, җыя, кибәнгә куя. Шул рәвешле аның хәрби хезмәткә – казаклыкка әзерләнүе сизелми дә кала.

Казак буларак ул махсус әзерлек тә узып тора. Аларның берсе начгиз уены дип атала. Бу вакытта ул аты белән станицага бара. Уен берничә этаптан тора. Романда иң соңгы тал кисү этабы сурәтләнә. *«Сафка тезелгән атлар да, алар өстендәге казаклар да торган урыннарында катып калды. Сотник, айгырның корсагын шпорала-*

*ры белән тиз-тиз кытыклап, үзен мәйдан уртасында көтеп торган атаманга таба чаптырып китте. ...Станицага җыелган яшь казаклар арасында Миңлебай ай буенча беренчелекне алып килде. Моңа бай балаларының ачулары чыга һәм аларның көнчелек тамырлары өзлексез рәвештә кузгалып тора иде»* [Яһудин, 2017, б. 43]. Бу өйрәнүләр вакытында Миңлебай Гомәров атаман биргән кылыч белән бүләкләнә.

Яшь татар казагы Миңлебайның тормышы һәрдаим авыл белән бәйләп бирелә. Романда казаклар өчен һәртөрле этнографик күренешләр, дини, гаилә йолаларының чит булмавын күрсәткән дәлилләр күп китерелә. Шундый йолаларның берсе – туй. Ул кыз сорау, килен төшерү, бәет әйтү һ.б. өлешләргә бүлеп тасвирлана.

Шулай итеп, «Атлы казаклар» романында Н. Яһудин казак язмышын тасвирлап, илнең сәяси тормышын, иҗтимагый вакыйгаларын күрсәтергә омтыла. Автор романында төгәл вакыт чикләрен күрсәтмәсә дә, без аларның XIX гасырның соңгы чирегендә һәм XX гасыр башында булуын аңлыйбыз.

Романның эчтәлегенә нигезләнеп, тарихи һәм мәдәни яссылыкта түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин. Роман татар халкы тарихында моңа кадәр өйрәнелмәгән татар казагы язмышын ачуга багышлана. Әсәрдә сурәтләнгән реалистик персонажлар – Яңа Черкас авылы кешеләре һәм Оренбург тирәсендәге төрле станицаларга таралып урнашкан кешеләр. Автор әдәби шартлылык шартларында да тарихи чынбарлыкны, аеруча 1880–1904 еллардагы вакыйгаларны сурәтли. Оренбург казаклары язмышы алар яшәгән төбәктән аерылгысыз. Шуңа күрә авыл тормышы, халыкның элек-электән килгән дини-мәдәни традицияләре саклануның матур үрнәге бирелә. Татар халкының туй, Сабантуй йолалары, төбәккә бәйләп, тирәнтен ачыла. Сабантуйның күңел ачу ягы гына түгел, ә кешенең психологиясе белән бәйле яклары мисалларга таянып яктыртыла.

**Әдәбият**

*Әмир Мирсәй.* Сугышчан сәлам белән // Казан утлары. 1975. № 5.

*Бекчурин М.* Начальное руководство къ изученію арабского, персидского и татарского языков, съ короткимъ объяснением существующих в Оренбургском крае наречий башкиръ и киргизов и съ приложением къ нему русско-персидско-татарских словъ, разговоров и прописей. – составил Мир-Салих Бекчурин, преподаватель восточных языков. Изд. 2-е, доп. Казань, 1869. С. 159, 4 л. прописей.

*Гаджиева Л.И.* Мир казачества в изображении Н.В. Гоголя, Л.Н. Толстого, М.А. Шолохова. М., 2007.

*Галимҗанов А.* Тарихи һәм лирик җырлар («Казак озату» җыры). Казан, 1988. Б. 77. Чыганак: [Интернет-ресурс] http://beznenmiras.ru/torki-khalyklarnyn-atly-uennary/

*Гордеев А. А.* История казаков. В 4-х частях. М.: Изд-во «Страстной бульвар», 1992.

*Гордеев А.А.* Яицкие казаки. Чыганак: Интернет-ресурс. http://idel.kz/yaickie-kazaki/

*Даль В.И.* Уральский казак // Даль В.И. Избранные произведения. М., 1983. С. 101–116.

*Даренская В.Н.* Очерк «Уральский казак» В.И. Даля как опыт художественной этнографии // Вестник Удмуртского университета. Серия «История и филология». Языкознание и литературоведение. 2017. Т. 27. Вып. 3. С. 370–376.

*Ерохин И.Ю.* Представления российских исследователей об этническом облике и корнях казачества: краткий историко-этнографический дискурс // Гуманитарные, социально-экономические и общественные науки. 2016. № 12. С. 45–49.

*Лаптева Е.В. Рожкова Л.П.* К вопросу об истории российского казачества // Вестник финансового университета. Гуманитарные науки. 2012. № 4. С. 60–67.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. Казан: ТР «Хәтер» нәшр., 2001. Б.5–66.

*Фатеев Д.Н., Зайцев Н.А.* Русские, татарские и башкирские хрестоматии середины и второй половины XIX в. в контексте национального просветительского движения // Историко-культурное наследие народов Урало-Поволжья. Филология. Литературоведение. 2020. № 1 (8). С. 100–106.

*Шамов Афзал*. «Казаклар» романына рецензияләрдән // Казан утлары. 2017. Б. 83.

*Ян Сумэй, Лукьянчикова Н.В*. Казачья литература как культурный феномен // Мир русскоговорящих стран. 2020. № 3 (5). С. 122–138.

*Яһудин Марс.* Еллар аша әти тавышын ишетәм сыман // Көмеш кыңгырау. 2000. 7 апрель.

*Яһудин Нәфыйк*. Атлы казаклар. Роман // Казан утлары. 2017. Б. 8–82.

***Мотыйгуллина Әлфия Рухулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Идел буе дәүләт физик тәрбия,*
*спорт һәм туризм университетының*
*чит телләр һәм тел белеме кафедрасы доценты*

УДК 82.091

***А.Н. Хәсәнова***

# «ДӘФТӘРЕ ЧЫҢГЫЗНАМӘ» ӘСӘРЕНЕҢ ИДЕЯ-ЭСТЕТИК КЫЙММӘТЕ

В данной статье раскрывается основная идея произведения и замысел анонимного автора. Мы остановились только на трех эпосах, в которых описаны взаимоотношения государства, правителя и народа; иными словами, писатель сосредотачивается на этих трех основных аспектах, и через его размышления раскрывается основная идея произведения − показ и освещение современникам «золотого века» империи Джучидов и тех причин, которые привели к ее краху.

**Ключевые слова:** «Дафтар-и-Чингиз наме», дастан, И. Хальфин, М. Усманов, исторический источник, Чингиз-хан, Хромой Тимур, Амат, сын Айсы.

This article aims to reveal the main idea and intent of the anonymous author. We have focused only on three epics and they all cover the relations of the state, the ruler, and the people; in other words, the writer focuses on these three main issues and through his reflections the main idea of the work is revealed.

**Keywords:** Daftar-and Genghis nameh, dastan, I. Khalfin, M. Usmanov, historical source, Genghis Khan, Lame Timur, Amat, son of Aisa.

«Дәфтәре Чыңгызнамә» XVII гасыр ахыры татар тарихи чыганаклары арасында күренекле урын алып тора. Ул шул чорда язмада теркәлүе белән тагын да әһәмиятлерәк. Бу ядкяр – Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларындагы тарихи язмаларга һәм риваятьләргә нигезләнеп, билгесез автор тарафыннан төзелгән. «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең авторы дип 1670–1671 еллардагы Крестьян сугышында катнашкан дин эшлеклесе Идрис Хафиз фаразлана. Әсәр Чыңгыз хан нәселенең, Аксак Тимер, Гайсә углы Амәт, Идегәйнең, төрле ханнарның яшәү урыны, биләмәләре турындагы алты повесть-бүлектән тора; соңгы өлеше «Татар елъязмасы» буларак та мәгълүм [Татар энциклопедиясе, 2010, 2 т., б. 239]. Бер мәҗмуга тәшкил иткән Чыңгыз, Аксак Тимер, Амәт турындагы дастаннарның төрдәшләре төрки халыкларның күбесендә бар. Әсәрнең теле гади һәм тасвирлы, әйтемнәргә, фразеологизмнарга бай. «Мәҗмуга»ны беренче мәртәбә 1822 елда Казан университеты укытучысы И. Хәлфин Көнчыгыш факультеты студентлары һәм Казанның Беренче ир балалар гимназиясе укучыларына татар телен өйрәнү өчен дәреслек итеп бастыра [Хәлфин, 1822, 91 б.]. «Мәҗмуга»ның сүз башыннан аңлашылганча, И. Хәлфин дастаннарның берничә кулъязмасын чагыштырып, аларның ышанычлыракларын сайлап бастырган, ягъни тәнкыйди текст төзергә омтылган. Икенче бер нөсхәсе шулай ук Казанда 1882 елда Р. Җиһаншин тарафыннан нәшер ителгән. Җыентыктагы материалларның аерым кисәкләрен Х. Френ, К. Фукс, И. Березин, Н. Катанов,

И. Покровский, Җ. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим дә укучыларга текстологик яктан эшкәртеп тәкъдим итәләр. Тарихчы галим М. Усманов башка татар тарихи чыганаклары белән беррәттән, «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрен өйрәнүгә дә үзеннән зур өлеш кертә. Ш. Абилов, В. Хаков, М. Гайнетдинов, М. Әхмәтҗанов, С. Гыйләҗетдинов, Д. Исхаков, М. Иванич, И. Мөстәкыймов һ. б. галимнәр үз хезмәтләрендә әсәр эчтәлегендәге фольклор, әдәби, тарихи, этник һәм генеологик мәгълүматларны анализлап бастыралар. Фольклорчы галимнәр хезмәтләрендә әлеге ядкәр халык иҗатының эпик жанры буларак карала. «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәренә кергән дастаннар халык иҗаты буенча академик томга кертелгән [Татар халык иҗаты, 1984, б. 102–105]. Соңгы чор фольклорчы галимнәр хезмәтләрендә исә «Дәфтәре Чыңгызнамә» китаби дастаннар категориясенә кертеп тикшерелә [Мухаметзянова, 2014, б. 256; Мөхәммәтҗанова, 2018, б. 44]. «Мәҗмуга» әле дә күп тикшеренүчеләрнең игътибар үзәгендә кала бирә.

Хәзерге вакытта архивларда, китапханәләрдә, музейларда һәм шәхси коллекцияләрдә төрле күләмле (тулы, берничә бүлектән һәм тулы булмаган) 67 берәмлек билгеле. Аларның күбесе (44 берәмлек) Казанда саклана. Күптән түгел «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең бер күчермәсе нигезендә әсәрнең киң таралган вариантыннан дастаннарының саны һәм эчтәлеге (шул исәптән, төрки-татар дәүләтләре, аеруча Кырым йортының башлангыч дәвере тарихы турында үзгә мәгълүмат бирүе) җәһәтеннән аерылып торган тагын бер варианты (редакциясе) барлыгы турында фараз әйтелде [Мустакимов, 2009, с. 122–131]. Бу фикер ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фондында «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең бер кулъязмасы саклану белән раслана. Бу күчерелмәдә Әстерхан ханлыгы тарихы турында, буталчык булса да, үзенчәлекле мәгълүматлар теркәлгән (кызганыч, кулъязма начар сакланган) [Язма мирас үзәге, 39 ф., 44 сакл. бер.]

«Мәҗмуга» Чыңгызның фантастик чыгышы, Аксак Тимер[1] һәм Гайсә углы Амәтнең маҗаралары бәян ителгән дастаннардан, Идел буена һәм Касыйм ханлыгына бәйләнешле вакыйгалар, нәсел-нәсәп шәҗәрәләре турында сөйләгән фасыллардан тора. Кулъязмаларның кайберләрендә теге яисә бу дастан яки фасыл төшеп калган.

Һәр дастан мөстәкыйль сюжетлы булып, алар арасында яисә ахырдан вакаигънамәләр, шәҗәрәләр китерелсә дә, мәҗмуга бербөтен әсәр булып санала.

Беренче дастан Чыңгызның шәҗәрәсе белән башланып китә һәм кулъязмаларда «Дәфтәре Чыңгыз», «Дәфтәре Чыңгызнам» яисә «Дәфтәре Чыңгызнамә» дип, төрлечә исемләнә.

«Мәҗмуга» үзенең характеры белән Әбелгазый Баһадурханның 1665 елларда тәмамланган «Шәҗәрәи-төрек» әсәреннән аерыла.

[1] Аксак Тимер (1336–1405) – Алтын Урданы җимерүче.

Әбелгазый хәбәр итүенчә, аның кулында Чыңгыз һәм Аксак Тимер турындагы әсәрнең берничә күчермәсе булган.

Шулай да Чыңгыз һәм Аксак Тимер турындагы ярым фольклор, ярым әдәби әсәрләрнең аерым кулъязмалары белән «Мәҗмуга» авторы таныш булган, дип уйларга кирәк. Алай гына да түгел, әсәрдә хикәяләнгәнчә, татар авторы Чыңгыз нәселе хакында монголлардан килә торган легендаларны да белгән.

«Дәфтәре Чыңгызнамә», бербөтен әсәр буларак, XVII гасырның соңгы чирегендә иҗат ителгән дип санала. Чөнки автор әсәрдә Себер ханнарының Чыңгыз токымыннан килгән шәҗәрәсен 1653–1654 елларда христиан динен кабул иткән Касыйм ханы Борһан солтан белән чикли. Шуңа күрә бу җыентык XVII гасыр татар тарихи чыганагы буларак өйрәнелә. Бу тарихи ядкяр кечкенә генә керештән һәм 6 бүлектән – дастаннардан гыйбарәт.

«Мәҗмуга»да «Дастаны нәсле Чыңгыз» дип аталган беренче бүлек башкаларына караганда күләмлерәк. Аннан Аксак Тимер һәм Гайсә углы Амәт дастаннары бәян ителә. Баштагы ике дастан хыялый легендаларны үз эченә ала. Бу хәл автор файдаланган Урта Азия һәм көньяк-көнчыгыш чыганакларындагы фольклор материалларыннан килә. Татар халкының рухи мәдәнияте үсеше тарихында турыдан-туры Чыңгыз ханны данлаган фольклор әсәре билгеле түгел. Бу табигый. Чөнки болгар-татар халкы үзен һичкайчан да Чыңгыз нәселе белән бәйләнешле дип санамаган. Ул Чыңгызны Болгар илен җимерүче, халкын һәлак итүче буларак каһәрләгән.

Автор дастанда Чыңгызның тууына, балалык вакытына бәйләнешле фантастик риваятьләр, легендалар белән генә эш итә; аны күп өлкәләрне үзенә буйсындырган хан дип белдерү белән чикләнә. Күрәсең, ул Чыңгыз ханның канлы яулары турында сүз йөртеп, мәсьәләне куертырга теләмәгән. Әсәрдән аңлашылганча, язучы андый максат куймаган да. Үз карашларын үткәрү өчен аңа гомуми фон кирәк булган. Әгәр дә әсәрнең Касыйм ханлыгында яисә Идел буенда, ягъни рус дәүләте карамагында яшәгән вакытта язылганлыгын искә алсак, моны аңлау кыен булмас. Язучы Мәскәү патшалыгы белән Касыйм ханлыгы, татар морза-алпавытлары арасындагы мөнәсәбәтләрне катлауландырырга теләми. Аның максаты – теләсә кайсы заман хөкемдары гадел булырга тиеш, дигән идеяне үткәрү.

Автор фикеренчә, хөкемдар тәҗрибәле, халык белән элемтәдә, аның язмышы турында кайгыртучы кеше булырга тиеш. Шулай булмаганда, ул үзен генә сөюче бер кешегә әверелә.

Димәк, илне идарә итүче күпне күргән, эшчәнлек күрсәткән, мөстәкыйль фикерле, тәҗрибәле кеше булырга тиеш.

Илнең бөлгенлеккә төшү сәбәбен автор гаделсезлектә, золымда, бердәмлекнең булмавында күрә. Ул Себернең Күчем нәселеннән килгән, әмма төп халык белән бәйләнеше булмаган Касыйм ханнарына ишарәли; аларның ил мәнфәгатеннән читтә, принципсыз, максатсыз

яшәүләрен шелтәли. Әдип бик сак фикер йөртә; ул еш кына укучыга мөрәҗәгать итеп, дәүләтне идарә итүченең нинди сыйфатларга ия булырга тиешлеген сөйли. Дәүләт һәрчак халыкның ышаюен, үзенең иминлеген кайгыртырга, дөньяга капкаларын киң итеп ачарга тиеш, дигән фикер үткәрә.

Авторның үгет-киңәшләре аша аның дөньяга карашын, уй-теләкләрен дә ачык тоемлап була. Ул аерым хөкемдарларның гамьсезлеге, хирыслыгы, эгоизмы аркасында бөтен дәүләтләрнең җимерелүен, ә халыкларының туздырылуын искә ала. Шушы уңай белән автор Мәскәү дәүләте хакында да сүз кузгата һәм Мәскәүне какшамас дәүләт төсендә тасвирлый. Биредә Мәскәү дәүләте үрнәк итеп куела. Автор артык идеаллаштыруга бармый, җыйнак итеп, чама белән сөйли. Аның бар максаты – үзен уратып алган тирәлектә дә шундый мул, җитеш, тотрыклы тормыш шартлары булдыру.

«Мәҗмуга»дагы икенче дастан Аксак Тимер турында: аның туганнан алып үлгәнчегә кадәр булган маҗаралары хикәя ителә. Бигрәк тә балачагын сөйләгәндә, автор Урта Азия легендаларыннан файдаланган булырга тиеш. Идел буена караган вакыйгалар, әлбәттә, болгар-татарларның үз риваятьләренә нигезләнгән.

Бу дастан да документаль тарих түгел. Ул – легендалардан, риваятьләрдән файдаланып язылган әдәби әсәр. Шулай да белгечләр, тарихи чыганакларга таянып, Аксак Тимер гаскәрләренең Болгар илендә булганлыгын таныйлар. Авторның әйтергә теләгән фикере шул: дәүләт җимерелеп, шәһәрләре туздырылса да, бөтенләйгә юкка чыкмый, ул яраларын төзәтеп, яңа шартларда яшәвен дәвам итә.

Дастанда Аксак Тимер – бер яктан, яулап алучы, җимерүче, ә икенче яктан, ихтыярлы, вакыты белән гаделлек күрсәтүче хөкемдар да. Язучы Тимернең җиңүгә ирешү сәбәбен аның көчендә генә түгел, ә аңа каршылык күрсәтергә тиешле халыкның бердәм булмавында да күрә. Автор Тимерне нәсел буенча тапшырыла килгән ханлыкка утыручы итеп түгел, ә үзенең тырышлыгы белән аңа ирешкән хөкемдар итеп күрсәтә.

Җыентыкта өченче булып килгән Гайсә углы Амәт дастаны аеруча киң таралган. Аның төрле вакытларда җыйналган һәм хәзер дә табыла килгән кульязмалары да күп һәм ул берничә тапкыр басылып та чыккан.

Дастанның сюжеты Алтын Урдада XIV гасыр урталарында урын алган вакыйгаларга барып тоташса да, үзенең теркәлүе ягыннан, Чыңгыз һәм Аксак Тимер турындагы дастаннар белән бергә, XVII гасыр татар әдәби ядкяре итеп карала. Әлбәттә, автор карамагында дастанның борынгы язмалары һәм риваятьләр дә булган.

Дастан нигезендә билгеле чорның мәгълүм вакыйгалары ятса да, аны фольклор һәм автор иҗаты аралашудан туган әдәби әсәр итеп карарга кирәк. Шуның өчен андагы геройлар тарихи шәхесләр дип түгел, ә әдәби образлар итеп каралырга тиеш.

Җанибәк хакимият сөючән эгоист, ул үз кызын үтерү фикеренә барып җитә. Авторның әйтергә теләгәне – хөкемдар халык белән тату яшәргә тиеш.

Өч дастан да дәүләт, хөкемдар, халык мөнәсәбәтләрен үз эченә ала; икенче төрле әйткәндә, язучы шул төп өч мәсьәләне игътибар үзәгендә тота. «Мәҗмуга»ның Россия империясендә колониаль һәм милли изүләрнең көчәйгән һәм социаль золымга каршы массаларның чыгышлары активлашкан вакытта иҗат ителгәнлеген искә алсак, язучының позициясен ачыграк төшенергә мөмкин. Әлбәттә, автор, нигездә, үз халкы яшәгән өлкәне күз алдында тота, ә гаделлек мәсьәләләре гомумән илгә карата куела. Димәк, язучы үз заманының битараф кешесе булмаган, җәмгыятьне борчыган сораулар белән янып яшәгән.

Колониаль һәм милли изүләргә каршылык күрсәтү фонында автор дәүләткә гомумхалык мөнәсәбәтен дә күздән ычкындырмый. Мәсәлән, ул аерым кузгалышларга катнашырга тиешле көчләрнең читтә калуларын һәм Аксак Тимергә каршы торырга кирәк вакытта халыкта бердәмлек булмавын әйтә. Ләкин болар әле язучыны заманының алдынгы идеяләре өчен актив көрәшче дип тә, дастаннар мәҗмугасы патша хакимиятен дер селкеткән крестьяннар хәрәкәте идеясен популярлаштыру өчен язылган дип тә бәяләргә нигез бирмиләр. Җыентыкта киң массаларны турыдан-туры актив көрәшкә чакыру идеясе дә юк. Автор – объектив шартларда патша хөкүмәтенә, аның социаль һәм милли сәясәтенә оппозициядә булган татарның феодаль аристократиясе вәкиле. Шунлыктан ул, крестьяннар яисә башкорт кузгалышларына теләктәшлек белдерсә дә, аларны еракта гына күзәткән.

Автор фикеренчә, хөкемдар белән халык бер теләктә булырга тиеш. Язучы, шуңа бәйле рәвештә, колониаль изүне дә йомшартырга тырыша, әмма ул үзенең фикерләрен дини формага төреп бирә. Күренә ки, язучының дөньяга карашы катлаулы һәм каршылыклы. Безнең өчен аның халыкка, киң катлау массага симпатия белән каравы, аның ихтыяҗларына теләктәш булуы мөһим.

Авторның дәүләт, хөкемдар һәм халык мөнәсәбәтләре турындагы уй-фикерләре аша әсәрнең төп идеясе ачыла: дәүләт нык булсын өчен, аның белән гадел хөкемдар идарә итәргә һәм ул, халык белән элемтәдә булып, аның язмышын кайгыртып яшәргә тиеш.

**Әдәбият**

*Мәрданов Р.Ф.* Чыңгызнамә: тарихи дастаннар. Казан: Милли китап, 2019. 287 б.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Дөнья цивилизациясендә татар дастаннары. Казан: ТӘһСИ, 2018. 280 б.

*Мустакимов И.А.* Об одном списке «Дафтар-и Чингиз-наме» // Средневековые тюрко-татарские государства. Сборник статей. Вып. 1. Казань, 2009.

*Мухаметзянова Л.Х.* Татарский эпос: книжные дастаны. Казань, 2014. 380 с.

Татар халык иҗаты. Дастаннар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Ф.В. Әхмәтова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

Татар энциклопедиясе: 6 томда. 2 т.: Г-Й. Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2010. 656 б.

ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИның Язма мирас үзәге, 39 ф., 6403 сакл. бер.

*Усманов М.А.* Татарские исторические источники XVII–XVIII вв.: «Сборник летописей», «Дафтар-и Чингиз-наме», «Таварих-и Булгария», татарские шаджара. Казань: Изд-во Казанского университета, 1972. 221 с.

*Хәлфин И.* Әхвәле Чыңгыз хан вә Аксак Тимер. Казан: Университет типографиясе, 1822. 91 б. (И. Готвальдның кулдан язылган искәрмәләре белән). (Халфин И. Жизнь Джингиз-хана и Аксак-Тимура. Казань: в Университетской типографии, 1822. 91 с. (с рукоп. прим. И. Готвальда)

***Хәсәнова Айгөл Наил кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 398

**Г.С. Хафизова**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АЗНАКАЙ РАЙОНЫ ТАТАР АВЫЛЛАРЫНДА БАЛА ТАБУГА БӘЙЛЕ ЙОЛА ФОЛЬКЛОРЫНЫҢ БҮГЕНГЕ ТОРЫШЫ

В данной статье рассматривается фольклор родильной обрядности, бытующий у татар Азнакаевского района Республики Татарстан. Временные рамки представленных материалов характеризуют обрядовую традицию татар на современном этапе ее развития. Их основу составили тексты, записанные автором в 2021–2022 гг. в татарских населенных пунктах исследуемого района на основе специально подготовленных вопросников. В ходе анализа собранных материалов автор приходит к выводу, что обрядовый фольклор, соотносимый по структуре и семантике с традиционной родильной обрядностью татар, довольно активно бытует по сегодняшнее время.

**Ключевые слова:** фольклор, традиция, обряд, обычай, родильный фольклор.

This article discusses the folklore of the natural and postnatal stages of maternity rituals, common among the Tatars of the Aznakaevsky district of the Republic of Tatarstan. The presented materials characterize the ritual tradition of the Tatars of the second half of the twentieth century. They were based on texts recorded by the author in 2021–2022 in the Tatar settlements on the basis of specially prepared questionnaires. During the analysis of the collected materials, the author comes to the conclusion that ritual folklore, correlated in structure and semantics with the traditional maternity rites of the Tatars is quite actual to this day.

**Keywords:** folklore, tradition, rite, custom, maternity folklore.

Халык авыз иҗатының иксез-чиксез хәзинәсен танып белми торып, шушы халыкның үзен, аның телен, холык-фигылен өйрәнү мөмкин түгел. Кешелек элек-электән өлкәннәрнең акыллы сүзләрен, төпле фикерләрен истә тотып яшәгән. Әүвәлгеләрнең тормыш тәҗрибәсе кешеләргә яшәү дәверендә төрле кыен хәлләрдән чыга белү юлын күрсәткән. Буыннан-буынга күчеп яши торган әлеге кыйммәтләр бүгенге көндә дә зур әһәмияткә ия. Халыкның йола фольклоры бу җәһәттән аерым урын алып тора.

Татар халкының гореф-гадәт, йолалары да элек-электән ныклы бер системаны тәшкил иткән. Әлеге мәкалә кысаларында максатыбыз – Азнакай районы татар авылларында җыелган фольклор материаллары нигезендә татар халкының бала туугa бәйле йолаларының бүгенге көндәге торышына бәя бирү. Шушы максаттан чыгып, бала туганчы, бала тугач үткәрелә торган йолаларга кагылышлы материалларга таянып, әлеге төбәктә сакланып калган йола фольклоры барланды, бу өлкәдәге кайбер проблемалар билгеләнде,

җирле масштабтагы күренешләренең гомумтатар йола фольклоры мәсьәләләре белән уртаклыгы күрсәтелде.

Иң әүвәл бала табуга бәйле йола-гадәтләргә хас күренешләр системасын билгеләп үтик. Баланың дөньяга килүе, бер яктан, яңа кешенең яшәеш башлангычы, икенче яктан, яңа туган бала – нәсел дәвамчысы, аның киләчәккә терәге. Шуңа күрә бу вакыйга кайсы гына милләт гаиләсенә кагылмасын, иң мөһиме, көтелгән сөенеч булып исәпләнә. Бала тууга бәйле төрле йола-гадәтләр кешелекнең иҗтимагый үсеш юлы барышы башлангычында ук формалашканнар. Аларның күбесе бүгенге көндә дә татар акылының, дөньяви күзаллавының нигезе булып торалар. Әлеге йола-гадәтләрнең асылы бүгенге көндә дә гомумтөрки калыпка утыртылган катлаулы йолалар, ышанулар, фольклор текстлары һ.б. элементлардан тора.

Галимнәр кеше гомеренең бу этабына бәйле күренешләрне өч: бала табу алды, бала табу, бала тапканнан соңгы этапларга бүлеп карыйлар [Брусько, с. 14; Бикбулатов, Фатыхова, с. 86; Поповичева, с. 31; Власкина, с. 16–26]. Без, бу бүленешкә нигезләнеп, мәкаләбездә бала табу һәм аннан соңгы этапка бәйле күренешләргә тукталырбыз. Мәкалә өчен кулланылган материалларның нигезен 2021–2022 еллар дәвамында мәкалә авторының Азнакай районы авылларында яшәүчеләр белән махсус әзерләнгән сораулыкларга җавап алу форматында оештырылган интервьюлары тәшкил итте. Информантларыбыз – 1930–1950 еллар аралыгында туган кешеләр, шуны истә тотып, тупланган материаллар, нигездә, XX гасырның икенче яртысына, бигрәк тә 60–70 нче елларына карый дип әйтә алабыз, ягъни безнең тикшеренү объекты булып шушы вакыт аралыгында Татарстанның Азнакай районында тупланган йола фольклоры материаллары тора.

Бу төбәктә яшәүче халыкның тарихи килеп чыгышы, рухи мәдәнияте, тел үзенчәлекләре галимнәрне электән үк үзенә җәлеп итеп торган. Төрле елларда Азнакай районына диалектологик, археографик, фольклор экспедицияләре оештырылган. Беренче мәгълүматларны немец галиме, энциклопедист, сәяхәтче П.С. Палласның 1773 елда басылып чыккан «Россия дәүләтенең төрле провинцияләре буенча сәяхәт» дигән хезмәтендә очратырга була. Азнакай районының Ык елгасы буе авылларына узган гасырның 1940 елларыннан башлап 1990 елларына кадәр Эдуард Касыймов, Халидә Гатина, Ленар Җамалетдинов, Риф Мөхәммәтҗанов, Марсель Әхмәтҗанов, Флера Баязитова кебек күренекле галимнәр катнашында экспедицияләр оештырылган. Шул ук вакытта Азнакай белән чиктәш Башкортстан территориясендә Ык елгасының икенче як ярында яшәүче татарларның йола иҗатын системалы рәвештә өйрәнү галим Риф Мөхәммәтҗанов исеме белән бәйле [Мөхәммәтҗанов, б. 7]. Аның хезмәтләрендә күбесенчә туй һәм календарь йолаларга караган мәгълүматлар анализлана, ә бала тууга бәйле йола фольклоры игътибар үзәгенә алынмый.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты XXI гасырның

2019 һәм 2021 елларында Азнакай районының татар авылларына комплекслы экспедицияләр оештырды. Язып алынган фольклор үрнәкләренең кайберләре экспедиция составында катнашкан галимнәрнең фәнни мәкаләләрендә, аерым фәнни хезмәтләрдә дөнья күрде [Калейдоскоп культур, с. 12–18, 19–26, 47–66; Мөхәммәтҗанова, б. 19–26]. Әлеге телгә алынган фактларга таянып, халык традициясендәге йолалардан бала табуга бәйлеләренең Азнакай районы татар авылларында әле XXI гасыр башында да шактый актив саклануы турында нәтиҗә ясарга мөмкин.

Азнакай белән чиктәш Башкортстан территориясендә Ык елгасының икенче як ярында яшәүче татарларның йола иҗаты галим Риф Мөхәммәтҗанов хезмәтләрендә тикшерелгән [Мөхәммәтҗанов, б. 7]. Аларда күбесенчә туй һәм календарь йолаларга караган мәгълүматлар анализлана, ә бала тууга бәйле йола фольклоры игътибардан читтә кала. Татар халкының йола комплексында бала табуга бәйле йолаларның әле бүген дә гамәлдә булуы аларны махсус фәнни өйрәнү ихтыяҗының актуальлеген раслый.

Җыеп алынган материаллардан XX гасырның икенче яртысында бала табу алды белән бәйле күп кенә ышанулар, ырымнар, йолаларның киң кулланышта булганлыгын күрәбез. Ана булу – кияүгә чыккан һәр хатын-кызның иң зур теләге. Кайбер кияүгә чыккан кызлар, гаилә корып яши башлагач, төрле сәбәпләр аркасында авырга уза алмыйлар. Элегрәк бу хәл татар гаиләсендә зур бәхетсезлек саналган. Баласыз хатыннар багучыларга, кендек әбиләренә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булганнар, төрле ырымнар, им-томнар кулланганнар. Бу хакта информант түбәндәгеләрне җиткерә:

*«Элегрәк бала таба алмаучы катыннар кендек әбиләренә бара торганнар ыйы, алар аның эчен сылап дәвалыйлар, "эч төшкән" вакытта "чүлмәк салалар" ыйы. Чүлмәк салуның эчке әгъзаларга да файдасы тия торган ыйы. Кендек әбиләренең сулышы да файдалы, – дия торганнар ыйы инәйләр ул заманнарда. Үзебез дә әллә ниләргә ышана ыйык, яшь чак җүләр чак булган инде. Әгәр төштә итәк тутырып йомырка күрсәк, авырга җурый торган ыйык. Тәрәзәдән күгәрчен очып кергәнен күрсәк тә, эре-эре балыклар күрсәк тә, авырга җурый торган ыйык. Инәйләргә сөйләгәч, алар тиздән авырга узачаксың алайса, малай булачак дип әйтәләр ийе. Авырга узган катыннар ул заманнарда кызмы, малаймы икәнен белмәгәннәр. Хәзер генә ул Аллаң рәхмәте, бөтенесен алдан белеп торалар. Җураулар булган ине ул заманнарда, хәзерге кебек врачлар әйтмәгән. Төштә олы мал күрү, малның ихатага килеп керүе, тана булса – кыз, үгез булса – малайга җурый ыйык»* (Илаева Галия Сабирҗан кызы,1944 елгы, Сөендек авылы). Әлеге материал татарларда бала табуга бәйле йоланың башлангычы әле бала туганчы, хәтта хатын-кыз балага узганчы ук күпкә алдан башлануы хакында бай мәгълүмат бирә.

Бала туганчы ук хатын-кызларны баланың нинди җенестән булуы кызыксындырган. Шуңа бәйле рәвештә төрле юраулар, ырымнар,

сынаулар үткәргәннәр. *«Авыры, көмәне җәелгән җомры булса – кыз, көмәне очлы булса – ир-бала туачак, дип җурый торганнар ыйы. Тагын өлкәннәр авырлы катынның битен тут басса – кыз була, тегеләй тутсыз булса – малай була, дигәнне дә ишеткән бар»* (Рәхимова Хаҗәр, 1939 елгы, Ирекле авылы). Биредә бала табу йолаларының фольклорның башка жанрлары белән тыгыз керешкән булуы күзәтелә. Әйтик, бала табу мәшәкатьләренә юраулар, ырымнар кушылып китү күренеше гаять кызыклы. Халыкта киң таралган бу төр фольклор, йолалар кебек үк, гаять борынгылыгы белән җәлеп итә, шул ук вакытта фольклорның синкретиклыгы тормышның төрле өлкәләренә тирән үтеп кергән һәм хәзерге көндә дә яши. Безнең тарафтан язып алынган түбәндәге материаллар да шуны раслый:

*«Авырлы вакытымда эшкә килгәч, Мәрьям исемле катын утырырга кушты да, утыргач торырга кушты. Мин торгач малай синең, малаең туа, – диде. Каян белдең, дигән ием, уң якка таяндың, малай була, диде. Сулы булса, кыз булыр ыйы, менә шулай диде. Малаем туды, дөрес булды»* (Дәүләтова Бибинур Әһелулла кызы, 1938 елгы, Куктәкә авылы).

«*И-и ул заманнарда кыланмаганнар калмады ине. Җепкә энә саплап, уч төбенә төбәп торасың, буйга селкенә башласа – кыз, аркылыга булса – малай. Ничә мәртәбә селкенүенә карап, туачак бала санын билгели ийек. Малай булсын дип, баш астына чүкеч, балта салып җоклаган чаклар да булды ине. Кыз теләүчеләр ак төстәге күлмәк салып йоклыйлар ыйы»* (Сафина Рима Сергей кызы, 1941 елгы, Мәнәвез авылы).

Белгәнебезчә, XX гасырның икенче яртысының беренче егерме елы илне Бөек Ватан сугышыннан соң төзекләндерү чоры буларак бәяләнә. Икътисади яктан шактый кытлык, бала тудыру йортлары әле төзелеп кенә килә, авылларда медицина хезмәткәрләре тарафыннан бала туганнан соң оештырыла торган патронаж эше башланмаган, шунлыктан кендек әбиләре институты һәм алар белән бәйле күп кенә гореф-гадәтләр әле саклана:

*«Авылда кендек әбиләре бар ыйы, аларны һәркем белә ийе. Бала туар алдыннан аңа әйтеп куялар ыйы, ул хәлне белеп сорашып тора. Аннан балага чирли башлагач, кендек әбисен тизрәк китерәләр. Теләкләр тели ине, котлый атасын-анасын. Минем әни дә килгән ине. Кендек әбигә сөенеч бүләкләрен ул бирде. Яулык ине ул вакыт. Бала тапкан хатын, сабый хәлле калса, шунда ук бирәләр. Анасын имә башласа, бала рәтле була ине. Аны кендек әби дә, сабыйның үз әбисе дә авызландыра ала. Кендек әби көтеп тормый китсә, әбисе бал каптыра. Теләкләр тели. Кем нинди теләк әйтә ала, шуны тели. Мин оныкларыма:*

*Бәхетле бул, ризыклы бул,*
*корычтай нык, чыршыдай төз,*
*каендай сыгылмалы булсын!*
*Бар саның сан булып,*

*Әтәй-инәле булып үсәргә насыйп булсын!*
*Бабаңны бабаң диң, әбине әби диң,*
*Олыларны олы ит, кечеләрне кече ит!*
*Бәхетең ташып торсын,*
*Дәртең кайнап торсын,*
*Арысландай гайрәтле,*
*Лачындай җитез бул!, –*

*дип телдәдем»* (Шәрипова Фагыймә Хәбиб кызы, 1929 елгы, Әсәй авылы).

Күргәнебезчә, XX гасырның икенче яртысында да кендек әбиләре башкара торган гамәлләр сабыйның сәламәт булуын тәэмин итүгә, гигиена таләпләренә туры китереп башкаруга юнәлтелгән. Гомумтөрки традиция нигезендә сөенче бирү дә сакланган, шул ук вакытта сабыйның беренче биләве буларак этисе күлмәген куллану да традицияләрнең дәвамы буларак бәяләнә ала. Әтисенең күлмәгенә биләү «баланы атага, ата нигезенә, нәселгә якын итү өчен дип башкарылган» [Брусько, б. 22].

Бала туган көннең икенчесендә беренче тапкыр бәби мунчасы ягыла. Бәби мунчасына махсус әзерләнгән бәби себеркесе пешерәләр, аның исен чыгаралар. Мунча бик кызу ягылмый, аны бәби кергәч, ташына бераз су салып, кайнарлап алалар, себеркене пешекләп, бәбине пешерелгән себеркегә яткырып, кендек әбисе, әгәр дә кендек әбисе булмаса әбисе, гадәттә, анасының анасы башыннан аягына таба сыпыра, башларын әвәли. Бәби сабыны белән бераз гына ышкып ала. Бераз парландыргач, коендыра. Коендырганда теләкләр теләнә.

*«Балаларны инәй җуындыра ине.Ускәнче почти гел бергә керәләр ийе. Такмаклар әйтә-әйтә җуындыра ийе инәй. Үзем дә шулай итеп такмаклап коендыра ием балаларны җуындырганда, хәзер оныкларны шулай җуындырам такмаклап:*

*Ак булсын, пакь булсын,*
*Су кебек чиста булсын!*
*Гомере озын булсын,*
*Тәүфыйклы бала булсын! –*

*дип сүлим. Башларыннан сыпырып, теләкләр телим. Инәйләр дә шулай итәләр ийе»* (Гәрәйшина Галия Гәрәй кызы, 1948 елгы, Югары Стәрле авылы).

*Суы сарыксын, үзе калыксын,*
*Таза булсын, сау булсын,*
*Тормышы да бай булсын!*
*Аллаһының рәхмәтендә*
*Озын гомерле булсын!*
*Аны үстергән ата- анага*
*Игелекле җан булсын!*
*Сау-сәламәт бәхетле,*
*Тәүфыйклы булып,*

*Озын гомерле булсын!*
*Бәхете булса, тәүфыйгы иярә аның.*

(Лотфуллина Әдибә Юныс кызы, 1936 елгы, Әгер авылы).

*Атаң кискән утын түгел,*
*Анаң яккан мунча түгел,*
*Аюдай ага бул,*
*Бүредәй бөгә бул,*
*Аю баласы, бүре баласы,*
*Мунча ташы, бүрәнә башы.*
*Арыш сабы кадәр озын булсын,*
*Солы кебек сылу булсын!*
*Үзе калыксын, суы сарыксын!*

(Габдуллина Рима Мирсәгыйт кызы, 1963 елгы, Тымытык авылы).

Кендек әбисе бәбине коендырып бетергәч, сабыйның аяклары камытланмасын өчен кысып бәйли, сулар эчертеп, өйгә кертеп җибәрә, аннан соң бәбинең анасының эчләрен баллар белән сылап, аналыгын урынына утырта. Бу гамәл бер генә тапкыр башкарылмый, атналарга барырга мөмкин. Утыру-утырмавын кендек әби үзе чамалый.

Азнакай районы авылларында да кендек әбисенә аерым хөрмәт күрсәтелә, бәби чәйләренә ул беренчеләрдән чакырыла, бала белән бәйле бер генә йоладан да калдырмыйлар аны (бигрәк тә исем кушу, никах йолаларыннан). Җомгаларда садәка да бирелә, яңа ризыктан авыз иттергәндә дә аны онытмыйлар. Дингә бәйле ашлар үткәргәндә дә аны чакырмый калмыйлар, вафат булса, аның рухына дога кылдыралар. Болар барысы да татар халкының әхлак кануннары белән аваздаш һәм шулар нигезендә тормышка ашырыла килә.

Бала туганнан соңгы этапка караган фольклор материаллары арасында ышанулар шактый. Шулар арасында баланы бишеккә салу, кырык көнгә кадәр саклауга караганнары төп урынны били. Чөнки татар халкы баланың кырыгына кадәр булган вакыт аралыгына зур игътибар бирә, халык телендә «Бала туганнан соң кырык көн» дигән сүз дә бар. Бу вакытта баланы күз тиюдән саклыйлар, чит кешегә күрсәтмиләр. Азнакай районындагы татар авылларында яшәүче апаларыбыз бишекне матчага элергә ярамау, бала башын сала торган урынга Коръән сүрәләре кую, бишек өстенә миләш, шомырт ботагы бәйләү, кырык көне тулганчы, баланың үзен генә калдырмау, чыгып китәсе булганда, бала бишегенә тимер кайчы салу яисә башка гамәлләр турында сөйләделәр. Болар барысы да сабыйны җен зәхмәтеннән саклау өчен башкарыла. Имеш, җен баланы үзенең елак, үтә дә ямьсез баласына алыштыра.

Кырык көн тулгач, атасы баланың чәчен ала, аны ташларга кушмыйлар, кәгазьгә төреп саклыйлар яисә яндыралар. 40 көн буена яңа туган баланы гына түгел, аның әнисен дә өзлегүдән сакларга кирәк. Борынгылар «бала тапкан хатынның гомере кыл өстендә» дип әйт-

кәннәр. *«Баланың кырыгы тулганчы чәчен алалар ыйы, аны саклыйлар ыйы. Минем кызымның чәче әле дә бар. Ир баланы кырыгы тулганчы бабайга бирәләр ийе, 40 көнгә чаклы шуңа ыштан киертмиләр ийе. Кырыгына чаклы балага, мулла чакырып, исем куштыралар ыйы. Азан ишетмәгән исемсез бала янына шайтан килә дип әйтә торганнар ыйы. Кыз балага багышлап – 1 корбан, ә ир балага багышлап 2 корбан чалып, исем куштыралар. Бу әле дә шулай башкарыла»* (Мөхәммәтгәрәева Рәзинә Зәкиҗан кызы, 1940 елгы, Сәпәй авылы). Анализ өчен алынган материаллардан күренгәнчә, татарларда бала туу белән бәйле йолалар ислам белән тирән керешеп үскән.

Бала тапканнан соң башкарыла торган йола-гадәтләр арасында төп урынны алып торганнарының берсе – бәби ашы, бәби күчтәнәче, бәби котлау. Бу йола әле дә сакланып калган. Туган-тумача, күрше-күлән бәбиле йортка тизрәк котлап күчтәнәч алып керергә ашыга. Никадәр тизрәк керсәң, шул кадәр савабы күбрәк була, дип исәпли азнакайлылар. *«Бәби котлап керү бар ине бездә. Тиз керәсең ине. Без бәби тапканнарда ачлык диярлек бит. Кибетләр сыгылмый әле ул вакытта. Пенсия дә юк әбиләрдә. Камыр ризыгы кертә ийек ине, тизрәк пичкә ягып көлчә кертәсең инде, катык кертә идек, сөт төшсен дип, сөтле аш та кертә ийеләр. Талкан да, солы кесәле дә кертәләр ийе. Ак оны, чүпрәсе булган кеше коймак кертә ине. Табикмәк бит ине бездә, аны кертәләр ийе. Хәллерәк кешеләр тәкә пешереп кертә ийе, бәрәңге, җиләк, кабак тәкәсе. Әле тары табикмәге дә кертәләр ийе. Бала-чага керә әле анда, аларга бәби тәпие күрсәтәләр. Алар шул бәби ашын ашап чыгып китә ине. Сөенеч бит, ашаталар сабыйларны. Савап бит ине ансы да»* (Хәкимова Мәүгыйдә Ибраһим кызы, 1948 елгы, Мөслим авылы).

*«Элек бөтен авыл китерә ийе бит ул бәби ашын. Хәдер бит күрше-күршегә керми дигән сыман, шундыйга әйләнде. Бәлеш, коймак, тәкә, тәбикмәк пешереп кертә торганнар ыйы. Бүлнискә кадәр бәлешләр пешереп җибәрде инәй белән бертуган түтәйләр әтәй аркылы ийе»* (Гәрәйшина Галия Гәрәй кызы, 1948 елгы, Югары Стәрле авылы).

*«Безнең якта кырыгына кадәр баланы карарга киләләр бит инде халык. Бала кырыена көмеш акча куеп китә торганнар ыйы. Шул көмеш акча белән кашларын сыза торганнар ыйы. Каш кош канаты шикелле кыйгач булсын өчен. Оста сызучы аерым кешеләр дә була торган ыйы* (Гәрәева Галия Хөсәен кызы, 1939 елгы, Сәпәй авылы).

Татар халкына хас булганча, Азнакай якларында да балага өч көн тулганчы исем кушарга кирәк дип саныйлар, соңга калсаң, *«бала тынычсыз була, тынычландырып булмый, күз тиючән була»*, диләр. XX гасыр – төрле сәяси-иҗтимагый, мәдәни вакыйгаларга бай чор. Бу, үз чиратында, татар антропонимик системасының үсеш-үзгәрешенә дә тәэсир итмичә калмый. «Гасыр башы шаукымы тәэсирендә татар антропонимиясендә гасырлар дәвамында сакланып килгән күчемлелек, дәвамчанлык традицияләренә тугры булып,

аерым бер йола-гадәтләр кысаларында гына яшәп килгән исем составында үзгәреш күзгә ташлана башлый. Халыкка авыр аңлашыла торган гарәби чыгышлы, кушма төзелешле һәм шулай ук иске татар катламын тәшкил итүче исемнәргә җиңел әйтелешле, мәгънәви яктан аңлаешлы фонетик яктан зәвыклы саналган исемнәр алмашка килә» [Хаҗиева-Демирбаш, 2018, б. 37]. Азнакай районы ЗАГС бүлегенең 1930–1940 еллардагы туу турындагы актлар язуыннан күренгәнчә, бу еллар аралыгында ир-атларга күбесенчә Әнәс, Әнис, Рәис, Нәфис, Рәфис, Фәнис, Индус, Илдус, Фәндәс, Атлас, Мөдәррис, Фаварис, хатын-кызларга Әнисә, Рәйсә, Халисә, Асия, Нәкыя, Наҗия, Гөлсинә, Тәнзилә, Зәйтүнә, Расиха, Тәслия, Иклимә, Фәүзия, Рәсимә кебек исемнәр кушылган. Информантлар сөйләвенчә, XX гасырның икенче яртысында да мөселман исемнәре кушуны хуп күргәннәр. Шулай да 1940–1960 елларда рус һәм Европадан кергән исемнәрне кушуга да өстенлек бирелгән. Мәсәлән, Азнакай ЗАГС бүлеге акт кәгазьләрендә Рима, Светлана, Флёра, Сиринә, Венера, Альберт, Марат, Марс, Эдуард, Роза, Рафаэль, Розалия, Эльза, Луиза, Роберт кебек исемнәрне шактый еш очратырга мөмкин. Галимнәр билгеләвенчә, мондый төр исемнәр татарлар арасына 1923 елларда килеп керә, моның сәбәбе – искелеккә каршы көрәшкә, яңа тормыш коруга юнәлтелгән идеология [Галиуллина, Илдарханова, б. 72–74]. Исем кушу йоласын Азнакай районы татар авылларында мулла башкара. XX гасырның икенче яртысында авылда мулла вазифаларын гарәпчә укый-яза белгән кеше үтәгән. Алар нинди дә булса махсус белемле муллалар түгел, чөнки бу чорда Советлар Союзында атеистик идеология өстенлек итсә дә, исем кушу йоласын традицион калыпларда башкару тыелмый. Билгеләнгән көнне мулла вазифасын үтәгән кеше килә, азан әйтеп, баланың ике колагына да исемен йомшак кына кычкыра. «*Исем кушканнан соң бала изрәп йокыга китсә, исемен килештерде»,* дип исәпләнә. Исем кушу йоласында кеше күп булмый: мулла, сабыйның әтиәнисе, ике яктан әби-бабасы, шушы йортта тора торган туганнары. Исем кушканнан соң, гаилә ипләп кенә бәби туена әзерләнә башлый. Бәби туен бала туып 40 көн үткәннән соң уздырырга тырышканнар. XX гасырның икенче яртысында, безнең информантларыбыз әйтүенчә, бәби туйлары бик сирәк гаиләдә уздырылган. Моның сәбәбе – тормыштагы кытлык, яшь хатыннарның тиз арада эшкә чыгарга тиешлеге.

Шулай итеп, Азнакай районы татар авылларында бала табу һәм аннан соңгы этапларда башкарыла торган йола-гадәтләр, башлыча, традицион кысаларда булып, балага узуга йогынты ясау йолаларын үтәүдән алып, хатыннар бәби тапканда кендек әби хезмәте, бала тугач, аны юындыру, бәби ашы кертү, бәби тәпие күрсәтү, исем кушу, бәбине кырык көнгә кадәр саклау кебек өлешләрдән тора.

Бала тууга бәйле йолаларның Азнакай районына хас үзенчәлекләрен барлау – милли үзенчәлегебезне, телебезне, шул исәптән фольклор байлыгыбызны саклап калу юлында бер адым. Татарлар

төрле җирләрдә төпләнеп яшәсәләр дә, зур бер милләтне тәшкил итәләр. Аерым бер төбәкнең – Татарстанның көнчыгышына урнашкан Азнакай районында халыкта сакланып калган йола-гадәтләр татар халкы яшәешенең хасиятләрен билгели, тулылыгын тәэмин итә. Мәгълүм булганча, бала табуга бәйле йолалар татарлар яши торган башка төбәкләрдә дә башкарыла. Бу йолаларның барлык татарларга да хас булуы халкыбыз үткән юлның уртаклыгы, йолаларның үсүенә яисә тоткарлыгына бер үк факторларның йогынты ясавы аның бердәйлеге хакында сөйли. Азнакай районында яшәүче милләттәшләребезнең соңгы чор иҗатында чагылыш тапкан йолалардан бала табу белән бәйлеләре, аларны үткәрү тәртибе татар милләтенең бербөтен булуын тагын бер кат раслый.

**Әдәбият**

*Баязитова Ф.С.* Әлмәт төбәге татарлары. Казан: Мәгариф, 2011. 67 б.

*Бикбулатов Н. В., Фатыхова Ф.Ф.* Семейный быт башкир XIX–XX вв. М.: Наука, 1991. 189 с.

*Брусько З.М. Завгарова Ф. Х.* В круге жизни. Казань: Ихлас, 2013. 224 с.

*Власкина Т.Ю.* Родильно-крестильный обряд в комплексе репродуктивных представлений донского казачества // Традиционная культура. 2004. № 4. С. 16–26.

*Галиуллина Г.Р., Илдарханова Ф.Ә.* Хәзерге татар гаиләләрендә исем сайлау традицияләре. Казан: Ихлас, 2010. 111 б.

Калейдоскоп культур: сборник материалов по результатам научных экспедиций по изучению культуры народов Республики Татарстан. Казан: Изд-во АН РТ, 2021. 280 с.

*Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты / төз.: И.И. Ямалтдинов, И.К. Фазлетдинов. Казан: ТӘһСИ, 2021. 228 б.

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Исеме үк җырлап торган Азнакай ул // Туган җир. 2020. 3/4. 209–220 б.

*Мухаметзянова Л.Х.* Фольклорное наследие татар Азнакаевского района (по материалам комплексной научной экспедиции) // Калейдоскоп культур. Сборник материалов по результатам научных экспедиций по изучению культуры народов Республики Татарстан. Казань: Изд-во АН РТ, 2021. С. 19–26.

*Поповичева И.В.* Структура и семантика родильно-крестильного обрядового текста (на материале томбовских говоров): дис. канд. филол. наук; Тамбовский госун-т им. Г.Р. Державина. Тамбов, 1999. 273 с.

***Хафизова Гөлсинә Сәетҗан кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының 2 курс аспиранты,*
*Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре*

УДК 94(470.41)

*Д.И. Әхмәтов*

# ТАТАРСТАН АССРДА БАЛИГЪ БУЛМАГАННАР АРАСЫНДА СУКБАЙЛЫК ҺӘМ КҮЗӘТҮЧЕСЕЗЛЕККӘ КАРШЫ КӨРӘШ ЧАРАЛАРЫ (1945–1953 ЕЛЛАР)

В настоящей работе рассматривается изучение системы ликвидации детской безнадзорности и правонарушений, сформированной в 1945–1953 гг. Материал изложен на основании специально-научных и общенаучных методов: сравнение изучаемых явлений, описание, а также элементы биографического анализа. При подготовке статьи использованы как общие, так и специальные методы исторического исследования: хронологический, логический, аналитический, историко-системный и др.

При подготовке исследования использованы документы Государственного архива Республики Татарстан, личные воспоминания ветеранов-сотрудников милиции, газеты и журналы. На основе анализа информации по данной тематике делается основной вывод о том, что проблемы детской безнадзорности, беспризорности и правонарушений среди несовершеннолетних были успешно решены на уровне советской власти в послевоенное годы в СССР, в том числе ТАССР 1945–1953 гг. В статье изложены основные мероприятия сформировавшейся данной системы, а также особое внимание уделено недостаткам в работе с безнадзорными детьми и подростками, склонными к совершению правонарушений.

**Ключевые слова:** ТАССР, беспризорность, детская безнадзорность, правонарушения, подростковая преступность, профилактика детской преступности опека, дети-сироты.

This paper examines the study of the system for the elimination of child neglect and delinquency, formed in 1945–1953, the analysis of the experience accumulated by the Soviet state to overcome these problems. The material is presented on the basis of a number of traditional general scientific and special scientific methods: comparison of the studied phenomena, description, as well as elements of biographical analysis. The analysis was carried out on the basis of the materials of the TASSR published and archival sources. The main conclusion is made that the problems of child neglect, homelessness and juvenile delinquency were successfully solved at the level of the Soviet government in the post-war years: the state in the post-war period proposed a system for the elimination of child homelessness and neglect, aimed at preventing and monitoring neglected children and dysfunctional families, ensuring the protection of children’s rights, as well as social assistance and prevention. The article describes the main activities of the formed system, accumulated during the positive experience of creating this system. At the same time, special attention is also paid to the shortcomings in working with neglected children and adolescents who are prone to committing offenses.

**Key words:** TASSR, homelessness, child neglect, offenses, juvenile delinquency, prevention of child delinquency, guardianship, orphans.

Һәр илнең киләчәге аның үсеп килүче буыны белән бәйле. Балалар һәм яшүсмерләр белән эш Россия җәмгыятенең иң йомшак якларының берсе булып кала. Хәзерге вакытта балигъ булмаганнарны опекага алу белән шөгыльләнүче махсус дәүләт структуралары бар, беренче чиратта, имин булмаган гаиләләрдәге балаларга сыйфатлы белем һәм ял алу мөмкинлеге тудырыла. Моңа бәйле рәвештә бүгенге көндә балалар проблемаларын хәл итү өлкәсендә тупланган тарихи тәҗрибәне фәнни яктан өйрәнү дә зур әһәмияткә ия.

Бу мәкаләдә бәян ителгән социаль процессларның объектив картинасын, балигъ булмаганнарга карата дәүләт сәясәтен формалаштырганда уңай һәм тискәре моментларны ачу өчен, тарихчыларның, социологларның һәм педагогларның күпьеллык фәнни хезмәтләре анализланды.

Өйрәнелә торган материаллардан күренгәнчә, балигъ булмаганнар арасында караучысызлык, сукбайлык һәм тәртип бозу кебек проблемалар XX гасыр урталарында уңышлы хәл ителгән булган. Без өйрәнә торган мәсьәләләр А.А. Славко, Э.З. Бикчурина, Д.Э. Кабиров, Д.В. Седова хезмәтләрендә чагылыш тапкан.

XX гасыр уртасында балалар йортларында тәрбияләнүчеләргә дәүләт тарафыннан, иң беренче чиратта, тәрбия һәм опекага игътибар көчәйтелә, шуңа бәйле рәвештә сукбайлык һәм күзәтүчесезлек кебек социаль күренешләр белән көрәш дәүләт органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган сәяси чаралар комплексы кысаларында башкарыла. 1945 елдан башлап балигъ булмаганнарны социаль яклау сәясәтенә яңа төзәтмәләр кертелгән, ятим балаларга социаль ярдәм күрсәтү, киң җәелдерелгән балалар йортлары системасын булдыру, югары квалификацияле педагогик кадрлар әзерләү процессын активлаштыру, шулай ук балаларны тәрбиягә ала торган гаиләләргә урнаштыру системасы камилләштерелгән.

1945–1953 елларда балаларны гаиләдә тәрбияләү проблемасы беренче планга чыга, моны башкару өчен җаваплы опека һәм попечительлек органнары булдырыла.

Сугыштан соңгы чорда күзәтүчесез калган балалар белән эшли торган комиссияләрнең вәкаләтләре киңәя башлый. Бу – яшүсмерләр белән социаль эшне оештыруда мөһим үзенчәлек булып, аларга кисәтү эшләре, халык арасында массакүләм аңлату эшен оештыру, махсус балалар учреждениеләре тарафыннан әлеге социаль эшне оештыруны жайга салу кебек вазифаларны үтәү йөкләнә. Мәсәлән, Казан шәһәренең Киров районында эшләүче әлеге комиссия тәрбиягә алынган балаларны, аларның тормыш шартларын оператив күзәтү максатында, сайлау округларындагы депутатларга беркетергә карар кылган [ГА РТ. Ф. Р-992. Оп. 1. д. 346. Л. 1].

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: совет чорында Татарстанда балигъ булмаганнар арасында сукбайлыкка һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш алымнары башка төбәкләрдән аз аерыла, алар, нигездә, бөтен ил өчен бертөрле була. Мондый хәл балаларның сукбайлыгын

һәм җинаятьчелекне булдырмауга юнәлтелгән чараларның гомуми норматив актлар белән үзәкләштерелгән һәм катгый регламентланган булуы белән бәйле. Рәсми документларда күп тапкырлар «...этисез, әнисез калган яки ялгыз ана булган яшь буынны тәрбияләү дәүләт контролендә булырга тиеш», – дип ассызыкланган [ГА РТ. Ф. Р-3610. Оп. 1. д. 553. Л. 78].

Сугыштан соңгы чорда дәүләтнең иң мөһим кайгыртуы – балаларны гаиләләргә урнаштыру. Мондый сәясәтне гамәлгә ашыру РСФСР Халык комиссариаты, РСФСР Юстиция Халык комиссариаты, РСФСР Юстиция Халык Комиссариатының патронлаштыру, опека һәм уллыкка алу турында инструкция нигезендә, башкарма хакимият органнары, үзәк һәм җирле партия органнары һәм турыдан-туры учреждениеләр дәрәҗәсендә башкарылган. 1943 елның 8 апрелендәге 325 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә ата-анадан мәхрүм калган балаларны опека, попечительлек һәм патронлаштыру, шулай ук уллыкка алуда эшче һәм колхозчы гаиләләренә өстенлек бирелгән[1].

Архив материалларын өйрәнү күрсәткәнчә, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны урнаштыру буенча җирле комиссияләр һәр җирдә дә сыйфатлы һәм нәтиҗәле эшләмәгән. Шундый хәл ТАССРда да күзәтелә. Кабул ителгән чаралар нәтиҗәсендә 1953 елда Татарстан Республикасының бик аз районнарында, мәсәлән, Казан, Яшел Үзән шәһәрләрендә, Лаеш районында оештырылган комиссияләр генә нәтиҗәле эшләгән. Бөгелмә, Буденово, Юдино, Корноухово, Буа, Арча районнарында, Бөгелмә шәһәрендә комиссияләрнең эше канәгатьләнерлек түгел, чөнки ТАССР Министрлар Советы каршындагы комиссия район комиссияләреннән эш таләп итмәгән. Республика комиссиясе барлык иҗтимагый оешмаларның эшен контрольдә тотмаган, балалар милициясенең Балалар бүлмәсе эше белән кызыксынмаган [ГА РТ. Ф. Р-3682. Оп. 2. Д. 291. Л. 62].

Шуны да күрсәтеп үтәргә кирәк: төрле предприятие директорлары тарафыннан сукбайларны һәм ятим балаларны эшкә урнаштыруга игътибар бирелмәгән, аларга тиешле матди ярдәм күрсәтелмәгән, аларны тулай торакларга урнаштырмаганнар. Бу аеруча Алабуга шәһәренең 39 нчы балалар йортында тәрбияләнүчеләрнең яшәү шартлары күрсәтелгән материалларда чагыла [ГА РТ. Ф. Р-3682. Оп. 2. Д.289. Л. 22, 23, 24] .

1945–1953 елларда балалар сукбайлыгы һәм җинаятьчелеккә каршы тору һәм көрәш өлкәсендә төп рольне НКВД органнары башкара. Аларның эшчәнлеге норматив документлар белән катгый регламентланган: урамнан алынган балалар милиция бүлмәләренә, балалар бүлмәләренә, бүлгечләргә китерелә. Рәсми мәгълүматларга караган-

[1] Постановление СНК СССР от 08.04.1943 г. № 325 «Об утверждении Инструкции Наркомпроса РСФСР, Наркомздрава РСФСР, Наркомюста РСФСР о патронировании, опеке и усыновлении детей, оставшихся без родителей» // Собрание постановлений и распоряжений Правительства РСФСР. 1943. № 3. Ст. 24.

да, 1944 елда Татарстанда ике кабул итү-бүлгеч бүлмәсе: берсе – Казанда, икенчесе Бөгелмәдә булган. Рәсми мәгълүматларга караганда, 1947 елның 1 гыйнварыннан 1 декабренә кадәр республикада 12635 бала тоткарланган, шуларның 1426 сы – сукбай, 11209 ы – күзәтүчесез бала, алар арасында – 82,4% ы укучы, 1514 е – беркайда да укымаган, 2,2% ы – балалар йортларыннан качып калган, 213 е – эштән читкә киткән балалар. Шул ук вакытта милиция бүлмәләренә эләккән балалар арасында 3113 яки 24,6% ы ун яшькә җитмәгән балалар булуын күрсәтеп үтәргә кирәк [ГА РТ. Ф. 15. Оп. 6. Д. 756. Л. 38].

Бу балалар, алга таба, яшьләренә карап, балалар йортларына, яисә ФЗӨ мәктәпләренә һәм һөнәр училищеларына җибәрелә, производствога эшкә урнаштырыла яки әти-әниләренә кире кайтарыла. Хокук бозучылар хезмәт тәрбиясе колонияләренә озатыла.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: сугыш вакытында ата-аналарын югалткан сукбай балалар, үз-үзләрен туендыру өчен, урлауга һәм талауларга «барырга» мәҗбүр булганнар, ә кайбер балалар, тиешле тәрбия һәм контроль булмау сәбәпле, җинаятьчелек тирәлеге йогынтысына эләккәннәр. Шулай итеп, 1946 елның икенче яртыеллыгында республика буенча 415 яшүсмер җинаять җаваплылыгына тартылган [ГА РТ (Государственный архив Республики Татарстан). Ф. 3610. Оп. 1. Д. 553. Л. 6–32].

Казан шәһәре Ленин районы Башкарма комитеты рәисе урынбасарының белешмәсендә күрсәтелгәнчә, 1948 елның беренче кварталында милициянең балалар бүлмәләренә 153 бала кергән, шул исәптән трамвайларда йөрү кагыйдәләрен бозган өчен – 80, хулиганлык өчен – 37, урам сәүдәсе өчен – 19, хәерчелек өчен 15 кеше тоткарланган. Тәрбиягә бирелгән күп кенә балалар теләнчелек белән шөгыльләнүләрен дәвам иткәннәр. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчының улы 9 яшьлек (үзенең апасында яшәүче) И. Чугунов, 1947 елның 17 апрелендә колхоз базарында милиция органнары тарафыннан тоткарлана [Народное хозяйство ТАССР, с. 160]. Аны сукбайлыкта йөрергә һәм теләнергә апасы мәҗбүр иткән булып чыга. Мондый фактлар республиканың күп кенә районнарында урын алган, бу хакимият структуралары тарафыннан опекадагы балаларның хәленә бернинди контроль булмау турында сөйли.

Балигъ булмаганнарның җинаятьчелек проблемасын өйрәнгәндә, бу категория гражданнарының җинаятьчелек күрсәткечләре арту социаль яки икътисади факторларга гына түгел, ә көрәш алып барыла торган чараларга да бәйле булуы ачыклана. Архив материалларын анализлау күрсәткәнчә, җинаять кылган яшүсмергә карата җәза-репрессия чаралары гына түгел, социаль-ориентлашкан һәм педагогик характердагы чаралар да кулланылган. Әңгәмәләр, аңлатмалар һәм ата-аналар, укытучылар, мәктәп директорларына карата кисәтүләр аеруча киң таралыш алган.

Совет чорында комсомол һәм профсоюз оешмалары, район халык мәгарифе бүлекләренең бу юнәлештәге эшчәнлектә роле аеру-

ча зур булган, алар мөмкин кадәр бала хокукларын саклау, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру буенча эш алып барганнар.

Балаларның караучысыз калуын һәм хокук бозуларын бетерү системасында ачыкланган уңай яклар һәм проблемалар бу мәсьәләне тарихи яктан фәнни өйрәнүне алга таба да дәвам итүне таләп итә.

Сугыштан соңгы чорда яшүсмерләр арасында киң таралган сукбайлык, күзәтүчесезлек, җинаятьчелек кебек тискәре күренешләрне юкка чыгарганда тупланган уңай һәм тискәре тәҗрибәне өйрәнү Россия җәмгыяте үсешенең хәзерге этабында дөрес стратегия һәм тактиканы әзерләүдә зур әһәмияткә ия.

**Әдәбият**

ГА РТ (Государственный архив Республики Татарстан). Ф. Р-992. Оп. 1. Д. 346. Л. 1.

ГА РТ. Ф. Р-3610. Оп. 1. д. 553. Л.78.

ГА РТ. Ф. Р-3682. Оп. 2. Д. 291. Л. 62.

ГА РТ. Ф. Р-3682. Оп. 2. Д.289. Л. 22,23,24.

Народное хозяйство ТАССР: Сб. ст. Казань, 1957.

ГА РТ (Государственный архив Республики Татарстан). Ф. 15. Оп. 6. Д. 756. Л. 38.

ГА РТ (Государственный архив Республики Татарстан). Ф. 3610. Оп. 1. Д. 553. Л. 6–32.

***Әхмәтов Данир Илгизәр улы,***
*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәк белеме институтының*
*3 курс аспиранты*

УДК 371.214.41=512.145

*М.М. Шәкүрова*

# М.Ә. ФАЗЛУЛЛИННЫҢ 1920–1930 ЕЛЛАРДА ДИДАКТИКА ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Данная статья посвящена исследованию научно-дидактического наследия М.А. Фазлуллина в 1920–1930 гг. В статье выделены основные идеи в области обучения и воспитания на родном языке, разработанные выдающимся методистом в области педагогики М.А. Фазлуллиным. В статье рассматриваются структура и содержание его трудов в историко-методическом плане, а также проведен анализ методической работы ученого.

**Ключевые слова:** научно наследие, преподавание татарского языка в начальной школе, структура и содержание методической работы, М.А. Фазлуллин.

This article is devoted to the study of the scientific and methodological heritage of M.A. Fazlullin in 1920–1930 The article highlights the main ideas in the field of education and upbringing in the native language, developed by the outstanding methodologist in the field of pedagogy M.A. Fazlullin. The article discusses the structure and content of his works in historical and methodological terms, as well as an analysis of the methodical work of the scientist.

**Keywords:** scientific heritage, teaching the Tatar language in elementary school, structure and content of methodological work, M.A. Fazlullin.

Бүгенге көндә илдә барган иҗтимагый яңарыш мәгариф өлкәсенә зур үзгәрешләр алып килде, шул исәптән XX гасыр башларында телгә өйрәтү методикасына үзләреннән өлеш керткән бер төркем методистларны барлау, аларның хезмәтләрен өйрәнү, чагыштыру кирәклеге дә ачыкланды. 1920–1930 елларда татар тел белемен үстерүдә, укыту методикасын камилләштерүдә, грамматик төшенчәләрнең терминнарын булдыруда бер төркем тел-әдәбият белгечләре киң эш җәелдереп җибәрәләр: Г.Г. Ибраһимов, Г.Х. Алпаров, Җ.Җ. Вәлиди, Г.Ш. Шәрәф, Г.Г. Сәгъди, М.Х. Корбангалиев, Г.Ш. Нугайбәк, Х.Г. Бәдигый, В.Н. Хангилдин, М.Ә. Фазлуллин һ.б. Аларны телнең фәнни эшләнеше һәм аны дәүләт дәрәҗәсендә куллану, татар әдәби теленең фонетик нормаларын эшкәртү, әлифба һәм язу өлкәсендә яшәп килгән каршылыкларны хәл итү һәм орфографик кагыйдәләрне бер тәртипкә китерү, педагогика һәм методика фәнен эшләү, укыту ысулларын ачыклау, укыту-тәрбия мәсьәләләре борчый.

1920–1930 еллар татар тел белемен яктыртуга вакытлы матбугат битләрендә, фәнни җыентыкларда зур урын бирелә: «Мәгариф» (1938 елдан «Совет мәктәбе»), «Безнең юл» («Атака», Совет әдәбияты»), «Татарстан» журналлары, «Кызыл Татарстан» газетасы һ.б. Газета-журнал битләрендә комплекслап укыту методы, Дальтон-план, бригада-лаборатория, проектлар методлары турында мәгълүматлар күренә башлый.

1920–1930 елларда мәктәпләр һәм уку йортлары өчен күпсанлы әлифбалар, татар теле дәреслекләре, тел үстерү буенча күнегүләр, дидактика кагыйдәләрен чыгаруда актив катнашучыларның берсе – профессор, филология фәннәре докторы, ТАССРның атказанган фән эшлеклесе, РСФСР ПФА мөхбир әгъзасы Мөхәммәтхан Әшрәфҗан улы Фазлуллинны атап үтәргә кирәк. Билгеле булганча, Мөхәммәтхан Фазлуллин 1883 елның 2 декабрендә Казан губернасы Чуел (Цивиль) өязе (Татарстанның хәзерге Яшел Үзән районы) Әрә авылында укымышлы гаиләдә дөньяга килә. Аның әтисе Әшрәфҗан Фазлуллин икенче мәхәлләнең имам-хатыйбы була. Туган авылындагы мәдрәсәдә башлангыч белем алганнан соң, 1895 елда әтисе Мөхәммәтханны Казандагы Апанай («Күл буе») мәдрәсәсенә бирә. Ул дүрт ел дәвамында мәдрәсә каршындагы рус классларында да укый, аннары Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. Казан дәүләт педагогия институтында укыта [Мортазина, 2016, б. 105] .

М.Ә. Фазлуллин татар мәктәпләре өчен татар теленнән программалар һәм уку-укыту планнарын төзүдә катнаша. Галимнең фәнни-методик эшчәнлеге күпкырлы: татар тел белеме, педагогика һәм методика мәсьәләләренә багышлап илледән артык хезмәт, мәкаләләр бастырып чыгара: «Иҗтимагый тәрбия» (1921), «Иҗтимагый тәрбияне ничек гамәлгә куярга?» (1921), «Тәрбиядә дәхле булган эчке һәм тышкы сәбәпләр» (1921), «Балаларны тәрбия» (1921), «Баланың теле ничек ачыла (Баланың психологиясеннән)» (1922), «Балаларда «кызыгу» тойгысын тәрбияләү» (1926), «Дикъкатьне тәрбияләү турында» (1926), «Дидактика кагыйдәләре» (1934) һ.б.

М.Ә. Фазлуллинның «Иҗтимагый тәрбия», «Иҗтимагый тәрбияне ничек гамәлгә куярга?», «Балаларны тәрбия» исемле мәкаләләре, бер-берсенең дәвамы булып, «Тәрбия нәрсә ул?» дигән сорауга җавап бирүне күз уңында тотып язылган. Әлеге мәкаләләрдә автор борынгы җәмгыятьтә тәрбия ничек алып барылганын, нинди принципларга нигезләнгәнлеген ачыкларга тырыша һәм бүгенге көндә «тәрбияне яңача – иҗтимагый планда бирергә кирәк» дигән фикер үткәрә: *«тәрбияне иҗтимагый планда бирә алырлык кешеләр дә кирәк, иске тип мәктәпләрдә, тәрбия йортларында укып чыккан кешеләр бу мәсьәләне хәл итә алмыйлар»* [Фазлулла, 1921, б. 29].

XX гасыр башларында «уку-укыту һәм тәрбия процессын заманча рухта алып барырга кирәк» дигән фикер М.Х. Корбангалиев, Р.С. Газизов, Х.Г. Бәдигыйларның кайбер хезмәтләрендә чагылыш тапты. Шулай ук М.Ә. Фазлуллин да «уку-тәрбия йортларын яңача корырга кирәк»лек турында «Иҗтимагый тәрбияне ничек гамәлгә куярга?» исемле мәкаләсендә кабат ассызыклап үтә: *«Мәктәпләребездә тәрбияне яңа ысулга, ягъни трудовой ысулга куярга кирәк, алар тормыш белән бик нык бәйләнгән булсыннар. Аларда да фән белән эш бергә алып барылсын»* [Фазлулла, 1921, б. 18–19]. Ул тәрбияне табигый тәрбиягә (*«Балалар олыларга карап һөнәргә-эшкә өйрәнгәннәр. Тәрбия эше эш-хезмәт ярдәмендә алып барылган һәм тәрбия бирүнең*

*төп максаты – баланы олы тормышка, мөстәкыйль тормышка әзерләү булган»*) һәм шәхси тәрбиягә бүлә («*Өйдә тәрбия алган бала, үзенә-үзе хуҗа булып, бөтен дөньяны буйсындырырга тели»*) [Фазлулла, 1921, б. 20–21].

«Бу эшне ничек тормышка ашырырга?» дигән сорауга җавапны М.Ә. Фазлуллинның «Балаларны тәрбия» исемле мәкаләсеннән дә табып була. Биредә автор тәрбия бирүнең алымнарына киңрәк туктала, бала психологиясенең үсеш үзенчәлекләрен анализлый, киңәшләр бирә.

М.Ә. Фазлуллин «Тәрбиядә дәхле булган эчке һәм тышкы сәбәпләр» дигән мәкаләсендә төрле шартларда балалар белән ничек эшләргә икәнен өйрәтә, «Ни өчен соң без никадәр тырышып тәрбияләсәк тә, безнең балаларыбызның кулы төрле әшәкелекләргә күтәрелә?» дигән сорауга җавап эзли, бала тәрбияләүдә җибәргән җитешсезлекләр турында яза, мохиттә, гаиләдә киткән хаталарга күзәтү ясый.

Автор мәкаләнең ахырында һәрбер укытучы, тәрбияче һәм ата-анага бала тәрбияләүнең ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген ассызыклый, киңәшләр бирә: «*Укытучылар һәм тәрбиячеләр менә бу югарыда күрсәтелгән нәрсәләргә әһәмият бирергә, тәрбия бабында дәхли булган нәрсәләрне яхшы белергә вә шуңа карап хәрәкәт итәргә тиешлеләр. Моңарчы безнең мәктәпләр балаларны бик изеп, ә укучылар сәламәтлекләрен югалтып килделәр; без моны инкяр итә алмыйбыз. Мәктәпләрдәге балаларның күбесе авыруга савыша, күбесендә кан азаю вә баш авырулары хасил була иде. Күзләре бозыла, күрүләре начарлана, әллә нинди авыруларга дучар булалар иде*» [Фазлулла, 1921, б. 56].

М.Ә. Фазлуллин тарафыннан XX гасыр башында күтәрелгән бу мәсьәләләр бүгенге көндә дә бик актуаль. Замана балаларын ничек тәрбияләргә? Нәрсә соң ул тәрбия? Тәрбияле бала нинди була? Ни өчен мәктәп яшендәге балалар арасында җинаятьчеләр көннән-көн арта гына бара? Наркотиклар кулланучы балалар ата-аналарны, укытучыларны, киң җәмәгатьчелекне борчуга салды. Укучылар күп вакытларын интернетта үткәрәләр, бер-берсе белән сирәк аралашалар, тормыш-көнкүреш аларны кызыксындырмый башлады.

Мөхәммәтхан Фазлуллин «Балаларда «кызыгу» тойгысын тәрбияләү», «Дикъкатьне тәрбияләү турында» исемле мәкаләләрендә Я.А. Коменский, Д. Локк, Ж.Ж. Руссо, К.Д. Ушинский кебек атаклы педагогларның фикерләренә нигезләнә, тел дәресләрен төрләндерергә, төрле алымнардан, уеннардан (бала белән ата-ана яки укучы белән укытучы үзләренең рольләрен алмашалар) файдаланырга киңәш бирә: «*Укучылар берничә дәрес рәттән укыганда арыйлар, аларның игътибарлары да башка әйберләргә юнәлә башлый. Дәресләрне төрләндерү исә – моннан котылу юлы. Бер дәрестә дә төрле алымнар белән эшләү шулай ук укучыларны арудан, аларның игътибарлары чит әйберләргә юнәлүдән коткара*» [Фазлулла, 1926, б. 87].

М.Ә. Фазлуллин татар телендә педагогика һәм дидактика мәсьәләләренә багышлап язган китапларыннан «Баланың теле ни-

чек ачыла (Баланың психологиясеннән)» (1922), «Дидактика кагыйдәләре» (1934) игътибарга лаек.

Галим «Баланың теле ничек ачыла (Баланың психологиясеннән)» дигән хезмәтен ата-аналар һәм тәрбиячеләр өчен кулланма итеп эшли. Хезмәтнең максатын ачык билгели: «*Бала иясе булган һәм бала тәрбия итә торган кешеләр бала теленең ачылуы белән мотлак таныш булырга тиеш, чөнки баланың теле ачылу бөтен-бөтенгә диярлек бала янында йөргән һәм аны тәрбия иткән кешеләрдән килә. Баланың яхшы телле яки начар телле булуында алар мәшгуль була. Шуның өчен алар бу турыда сак һәм белеп вә аңлап хәрәкәт итәргә тиешлеләр*» [Фазлулла, 1922, б. 3].

М.Ә. Фазлуллин әлеге китабында чит ил психолог һәм философларының фикерләренә теләктәшлек белдерә, аларның хезмәтләре белән бәйләп, баланың теле ачылуга бик матур мисаллар китерә (Генрих Стефани, Эдилбер Ир, Гундер Штирен, И. Вапф, Э. Мейман һ.б.). Педагог бала теле ачылуның тышкы һәм эчке сәбәпләрен тикшерә. «*Баланың сөйләшергә хәзерләнү дәверендә,* – ди галим, – *дүрт халәт сизелә: кычкыру, бетелдәү, авазлар бирү һәм сүзләрне аңлый башлау*». Һәр халәтне аерым-аерым анализлый һәм чит ил психологлары, философларыннан алган мисаллар белән дәлилли. Мәсәлән, Гундер Штиренның үз кызы турында язганнарына күз салыйк: «*Кызыбызга ун атна булып, унбер атнага киткәч, без шундый тәҗрибә ясый башладык: кәефе яхшы булганда аңа «трры-трры» дип әйтә торган идек тә, ул да безнең арттан шул авазларны чыгара торган иде, ләкин аның йөзенә кызыллык йөгерә, аның тырышып, көчләнеп әйткәне күренеп тора иде, чөнки, бердән, әле ул безнеке шикелле тавыш-авазларга гадәтләнмәгән, безнеке шикелле итеп чыгару аңа авыр, икенчедән, ул үзе теләгәнчә, үз ихтыяры белән бетелдәп өйрәнгән, аңа әле читтән килгән тәэсиргә буйсыну читен эш; шуның өчен ул көчләнә, аның көчләнүе шуннан килә иде*» [Фазлулла, 1922, б. 32].

Шулай итеп, М.Ә. Фазлуллинның «Баланың теле ничек ачыла (Баланың психологиясеннән)» дигән хезмәте бигрәк тә мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүчеләр өчен, шулай ук ата-аналар өчен кирәкле кулланма булып тора.

М.Ә. Фазлуллин «Дидактика кагыйдәләре»н 1908 елда Казан укытучылар мәктәбендә укыган вакытта ук яза башлый. 1911 елда «Йолдыз» газетасында берникадәр өлешен бастыра. Соңрак 1922 елда 43 биттән торган бу хезмәтне бастырып чыгара. Сүз башында укытучының вазифаларын да билгеләп үтә: «*Укыту эшенә өстән генә карарга ярамый, ...тирән карарга вә аның өчен бик күп хәзерләнергә кирәк. Ул шәкертләрне укырга, язарга өйрәтү, аларга төрле гыйлемнәр бирү дигән сүз генә түгел. Бәлки шәкертләрне укыту һәм шул ук вакытта тәрбия итү дигән сүздер. Бу икене һич вакытта бер-береннән аерырга ярамый.*» [Фазлулла, 1922, б. 3–4] М.Ә. Фазлуллинның «Дидактика кагыйдәләре» дигән хезмәтендә методика һәм

дидактика, дәрес бирү рәвешләре, дидактиканың төп кагыйдәләре җентекләп тикшерелгән һәм бүгенге көн укытучылары өчен дә файдалы бер кулланма булып тора. Методист укытучыны шәкертләр белән үзен ничек тотарга, ничек эшләргә өйрәтә, аларга ныклы белем һәм тәрбия бирү юлларын тикшерә. *«Укыту юлларын, дәрес бирү ысулларын күрсәткән фәнне "методика" дип атыйлар. ...Укыту юлларын "метод" (дәрес бирү ысулы) дип атыйлар. Укыту вә дәрес бирү өчен төрле методлар бар. Иң әүвәл аларны тәхаил (анализ) методы һәм тәркиб (синтез) методы дип, икегә бүләбез»* дип, автор һәр ысулга бәйнә-бәйнә туктала.

Бу китапта автор дидактиканың әсаси (төп) кагыйдәләрен дүрткә бүлеп тикшерә:

1) шәкертләргә гаид булган кагыйдәләр;
2) укытыла торган нәрсәләргә гаид булган кагыйдәләр;
3) укытучыларга гаид булган кагыйдәләр;
4) укытуның эчке һәм тышкы якларына гаид булган кагыйдәләр.

Галим «Шәкертләргә гаид булган кагыйдәләр»дә балаларның акыл, фикер дәрәҗәләре үсешенә игътибар итәргә куша һәм аларны өч төрле дәрәҗәгә аера: 1) 9–10 яшьләргә кадәр булган дәвер (бу дәвердә гакыл фәкать тышкы тойгы әгъзалары аркылы гына эш итә торган була); 2) 10–14 яшьләргә кадәр булган дәвер (бу дәвердә хәтер куәте бик яхшы була); 3) 14 яшьтән соңра дәвер (бу вакытта гакыл эш итә башлый, балаларның зиһеннәре ачыла, уй вә фикер йөртә башлыйлар, нәтиҗәләр төзеп, хөкем чыгаралар) [Фазлулла, 1922, б. 43]. Һәр кагыйдәдә диярлек «укытучы балаларны сөя һәм укыту эшен ярата торган булсын» дигән фикерләр чагыла. Чыннан да, бүгенге көндә үзенең фәнен, балаларны яратмый торган укытучылар да бар бит. Халыкның мәктәпкә мөнәсәбәте дә төрлечә. Шуның өчен М.Ә. Фазлуллинның «*мәктәп белән халыкны бер-берсеннән аермаска һәм бер-берсеннән ераклаштырмаска кирәк. Мәктәп халыкка якын торсын, халык аңа мәхәббәт итсен, үзенеке итеп карасын. Бер-беренә булыша, ярдәм итә алсыннар*» дигән сүзләрен һәрдаим кабатлыйсы килә.

М.Ә. Фазлуллинның педагогик һәм методик характердагы мәкаләләрен һәм китапларын тикшереп чыккач, шуны әйтәсе килә: ул – шәкертләрнең психологиясен яхшы белә торган оста педагог, уку-укыту һәм тәрбиягә караган мәсьәләләр белән бик теләп, яратып шөгыльләнгән, методика фәнен яхшы белгән тәҗрибәле укытучы. М.Ә. Фазлуллинның дидактика, методика өлкәсенә караган хезмәтләренең тарихи әһәмияте туган телебезгә, татарча укытуга игътибар бермә-бер арткан безнең заманда тагын да ачыграк күренә.

1920–1930 елларда «Мәгариф» журналында М.Ә. Фазлуллинның тел гыйлеме, телне өйрәнү методикасы һәм орфография, пунктуация белән бәйле мәкаләләре дә басылып чыга («Икенче баскыч мәктәпләрдә һәм педагогия техникумнарында грамматика күләме түбәндәгечә булырга тиеш» (1927), «Яңалифтә тыныш тамгалары» (1929),

«Хәзерге көндә мәктәпләрдә имланы үзләштерү ни дәрәҗәдә һәм аны ничек исәпкә алырга» (1930) һ.б.). Авторның «Икенче баскыч мәктәпләрдә һәм педагогия техникумнарында грамматика күләме түбәндәгечә булырга тиеш» дигән мәкалә-программасы аерым бер игътибарга лаек. М.Ә. Фазлуллин әлеге мәкаләдә тел материалын өч бүлеккә бүлә (аваз хәдисәләре (фонетика), сарыф хәдисәләре (морфология), җөмлә төрләре (синтаксис)) һәм һәр бүлекнең методикасын эшли, укучыларга кыен булган өлешләргә туктала, аңлатмалар бирә һәм грамматик материалны сыйныфларга (елларга) карап бүлә. Ул тел белеме һәм тел тарихыннан укучылар белергә тиешле материалны билгеле бер күләмдә тәкъдим итә: «*Сүзләрдә аваз һәм формаларның үзгәрү кануны. Яңа сүзләрнең һәм авазларның тууы. Телләр арасындагы кардәшлек. Телләрне сарыф һәм генеология (родословие) ягыннан төркемләү (классификация)»* [Фазлулла, 1927, б. 31].

М.Ә. Фазлуллинның «Икенче баскыч мәктәпләрдә һәм педагогия техникумнарында грамматика күләме түбәндәгечә булырга тиеш» (1927) дигән мәкаләсендә морфологиягә өйрәтү методикасы игътибар үзәгендә тора. Автор кайбер сүзләрнең берничә сүз төркеменә каравын билгеләп үтә: *кара* дигән сүз бездә язу карасы булганда бертөрле, *ка́ра* (фигыль – смотри) булганда икенче төрле, *кара́* төсе (сыйфат – черный) булганда башка төрле әйтелә [Фазлулла, 1927, б. 32] .

Методик күзлектән чыгып караганда, авторның синтаксисны өйрәтүгә караган фикерләре дә кызыклы: гаилә эчендә баш әгъзалар һәм иярченнәр булган кебек, җөмләдә дә баш һәм иярчен кисәкләр бар дип, әлеге мәсьәләнең чишелешен күрсәтә.

М.Ә. Фазлуллинның «Яңалифтә тыныш тамгалары» (1929) дип аталган мәкаләсе мәктәптә укучыларда пунктуацион грамоталылык тәрбияләүдә зур әһәмияткә ия. Автор тыныш тамгаларының төрләрен ике төркемгә бүлә һәм аларны кую кагыйдәләрен күрсәтә: нокта кую очраклары (3), өтер (10), нокталы өтер (8), өндәү билгесе (7), сорау билгесе (8), катнаш тыныш билгеләрен кую очраклары (3) [Фазлулла, 1929, б. 18–24]. Ул һәр тыныш билгесен кую очракларына туктала, кагыйдәләрне мисаллар белән ныгытып бара. Мәсәлән: «*Туктаулы тавыш белән әйтелгән сүзләр, тәгъбирләр, җөмләләр соңында нокта куела. Җөмләдә өзеп-өзеп кенә (пауза ясап кына) әйтелгән кисәкләр арасында өтер куела һ.б.*

1934 елда М.Ә. Фазлуллинның инструктив-методик материалы, ягъни башлангыч мәктәптә татар теле укытучыларына методик ярдәмлек буларак язылган «Башлангыч мәктәптә татар теле» дигән китабы чыга. Бу хезмәтнең сүз башында «Русский язык в начальной школе» дип аталган методик кулланмаларга нигезләп язылган булуы искәртелгән. Китап төп өч бүлектән тора:

1. Башлангыч мәктәпләрдә татар теле укытуның торышы һәм аның бурычлары.

2. Башлангыч мәктәпләрдә татар теле буенча эшләү өчен еллык үрнәк план.

3. Башлангыч мәктәптә татар теле дәреслекләре белән эшләү турында аерым күрсәтмәләр.

«Башлангыч мәктәпләрдә татар теле укытуның торышы һәм аның бурычлары» дип аталган беренче бүлек аеруча игътибарга лаек. Бу бүлектә сүз укырга, язарга өйрәтү, орфография, грамматика, сөйләү һәм язу телен үстерү турында бара. Бигрәк тә авторның укырга һәм язарга өйрәтү методикасына караган фикерләре кызыклы: «Уку өчен сүзләр сайлаганда башта бер иҗекле, аннары ике иҗекле, иң соңыннан гына күп иҗекле сүзләр сайланырга тиеш. Иҗекләр характеры ягыннан караганда да, башта ачык иҗекле, аннары ябык иҗекле сүзләр алыныр, *арт, карт, дүрт*... кебек күп хәрефле катлаулы иҗекле сүзләрне һәм *грамм, трамвай, крахмал, план, шкаф*... кебек янәшә ике тартык аваз килгән иҗекләрне ашыгып бирмәскә кирәк...» [Фазлулла, 1934, б. 7].

М.Ә. Фазлуллин татар мәктәпләрендә грамоталылык дәрәҗәсенең түбән булуын яңа әлифбага күчү, аны үзләштерү белән бәйле һәм сәбәпләрен дә күрсәтә:

1) грамматиканың укучылар тарафыннан үзләштерелмәгән булуы;

2) өйрәнелгән материалны алга таба кабатлап, ныгытып бармау;

3) яңа материалны ныгыту максатыннан чыгып бирелгән күнегүләрнең бертөрле, артык гади һәм җиңел булуы;

4) кулланылган метод һәм алымнарның өйрәнелә торган материалның, дәрес төренең характерына, эчтәлегенә һәм укучыларның хәзерлегенә туры килмәве;

5) теге яки бу метод-алымны кулланып эш иткәндә, ачыклык, эзлеклелек булмау;

6) программада бирелгән материалны дөрес планлаштырмау.

М.Ә. Фазлуллин күрсәткән сәбәпләр бүгенге көн татар теле дәресләренә куелган таләпләргә туры килә:

1. Дәреслектәге материалның программада бирелеше (программага туры килү-килмәү очраклары).

2. Дәреслек төзелү принциплары (фәннилек, системалылык, эзлеклелек һ.б.).

3. Дәреслекнең төзелеше:

а) дәреслек төзүнең максатлары һәм бурычлары;

ә) теоретик материалның бирелеше, бәхәсле очраклар;

б) дәреслектә тәкъдим ителгән күнегү төрләре (үткән материалны искә төшерү, кабатлау; теоретик материлны гамәли яктан ныгыту, иҗади характердагы күнегүләр, ныклы орфографик күнекмәләр булдыру күнегүләре һ.б.);

в) предметара бәйләнеш бармы?

г) бүлекара бәйләнеш (яңа материал тел гыйлеменең кайсы бүлекләре белән бәйләнгән?);

д) тәкъдим ителгән текстлар коммуникатив һәм тәрбияви максатка ярашлымы? Эчтәлеген ачыклау;

е) дәреслектә күрсәтмәлелекнең бирелеше (таблицалар, схемалар бармы, татар рәссамнарының эшләре урын алганмы? һ.б. [Фазлулла, 1934, б. 34].

М.Ә. Фазлуллин тел дәресләрендә инша, үзгәртеп эшләү, сорау-җавап формасы, бланклар һәм анкеталар тутырту, план төзү кебек эш төрләрен күбрәк үткәрергә тәкъдим итә. Ул бу эш алымнары укучыны дөрес язарга, аларның сүз запасын баетырга, дөрес һәм мәгънәле итеп сөйләргә өйрәтә дип саный.

Укыту ысулларына килгәндә, методист сөйләү-хикәяләү, күрсәтмәле-демонстратив ысуллар һәм алымнардан картиналар, сүзлекләр белән эшләү, диктант яздыру, иҗади эшләр башкаруны тәкъдим итә.

Әлеге хезмәтендә Мөхәммәтхан Фазлуллин гамәлдәге дәреслекләрнең методик аппаратын тикшерә һәм аларда киткән җитешсезлекләрне барлый:

1) күнегүләр бертөрле, системасыз рәвештә бирелгән;

2) бирелгән кагыйдәләр тулы түгел, укытучыга материалны үзенә тулыландырырга кирәк була;

3) таблица һәм схемалар юк;

4) шартлы тамгалар юк;

5) иллюстрация юк диярлек;

6) урын алган кагыйдәләр укучылар өчен авыр, аңлаешсыз тел белән язылган;

7) бирелгән материал системалы, эзлекле рәвештә түгел һ.б.

Шунысын да ассызыклап үтәргә кирәк: М.Ә. Фазлуллин үзенең «Башлангыч мәктәптә татар теле. (Инструктив-методик кулланма)» китабында укыту эшен тормыш белән бәйләп бирү һәм тәрбияви моментларны да күз уңында тотарга куша. Без хәзер дә дидактик принциплардан берсе булган укытуны тормыш белән бәйләп бирү принцибын татар теле дәресләренең нигез ташы итеп алабыз: бәйләнешле сөйләм телен үстерү дәресләрендә телевидение, радио телен тыңлау, анализлау, укучылар яратып укый торган газета-журналлар белән эшләү, спорт яңалыклары, табигатьне саклау, Казандагы ятимнәр йортлары, картлар йортлары турында сөйләү, туган илне ярату һәм саклау, туган җирләре, әби-бабалары турында иншалар яздыру кебек эшләр артык булмас иде.

1934 елда М.Ә. Фазлуллинның «Башлангыч мәктәптә тел үстерү» дигән тагын бер хезмәте дөнья күрә. Әлеге хезмәтнең кереш сүзендә башлангыч мәктәптә тел үстерүнең максат-бурычлары билгеләп үтелгән, аларны тормышка ашыруда файдалы киңәшләр бирелә:

1. Укучыны бу күнекмәләргә ия итү өчен, мәктәптә аның белән эзлекле һәм системалы күнегүләр ясарга кирәк. Бу күнегүләр, авырлыгы ягыннан үсә барып, бөтен уку елларына сузылырга һәм шуның белән бергә тел дәресләренең һәр төре (уку, язу, грамматика дәресләре) буенча алып барылырга тиешләр.

2. Укучыларның сөйләмә һәм язма телен үстерү бөтен педагогик процессның иң әһәмиятле өлеше буларак исәпләнергә тиеш.

3. Тел үстерү эшен алып барганда материалны дөрес сайларга кирәк. Материал (текст) кызыклы һәм башка фәннәр белән дә, өлкәннәр белән дә бәйләнешле булсын һ.б. [Фазлулла, 1934, б. 1].

Методист башлангыч мәктәптә сөйләү һәм язу телләрен үстерү, ныклы күнекмәләр булдыруның төрле юлларын күрсәтә:

1. Әйтү күнекмәләрен тудыру.
2. Сорауларга җаваплар бирү күнекмәләре.
3. Укылган текстка бәйләп, сөйләү теле белән эшләү.
4. Мәктәп коллективын иҗтимагый тормыш белән бәйләп, сөйләү телен үстерү.
5. Картина белән эшләү.
6. Балаларның мөстәкыйль язма иншаларын тикшерү.
7. Сүзлек белән эшләү.
8. Рәсми тел белән эшләү.

М.Ә. Фазлуллинның «Башлангыч мәктәптә тел үстерү» китабында текст белән эшләү механизмы да бар: сүзлек эшен башкару, укылган текст буенча сорауларга җавап бирү, эчтәлеген сөйләргә өйрәнү, баш куелмаган текстларга исем уйлап табу, укылган текстлар буенча иҗади эшләр башкару, кечкенә хикәя формасында язманы планлаштыру, укучылар җибәргән хаталарны җыеп чыгу, бүлү һәм төзәтү һ.б. [Фазлулла, 1934, б. 55].

Бу китапта галим укучылар җибәргән хаталарга анализ ясый, аларның төрләрен күрсәтә: 1) сүзлек материалын куллану ягыннан булган кимчелекләр, 2) җөмләләрне төзү ягыннан ялгышлар, 3) җөмләдә сүзләрне төзүдәге хаталар, 4) сыйфат формаларын һәм фигыль формаларын ялгыш куллану. Әлеге хаталар хәзерге тел методикасында лексик, грамматик, орфографик, стиль, логик хаталар дип карала. Соңгы елларда хәзерге заман сыйфат фигыльнең *-учы, -үче* формасы еш кулланыла башлады: *баручы машина, килүче автобус, эшләүче завод* һ.б. Бу күренешкә XX гасырның 30 нчы елларында М.Ә. Фазлуллин да игътибар иткән булган. Болардан тыш автор әдәби сөйләмне бозып сөйләү (*колидор, мөнкин*), сүзләрне әдәби телдәгечә кулланмау (*бүлекне идарә итү*), кирәкмәгән сүзләрне куллану (*бервакыт бер көнне без*), җөмлә кисәкләре арасында ярашу булмау, сүзләр арасында бәйләнеш булмау, җөмләләрне төрлечә аңлауга юл калдыру (синтаксик омонимнарны күздә тота. – *Ш.М.*) кебек хаталарның еш кабатлануын искәртә.

М.Ә. Фазлуллинның «Башлангыч мәктәптә тел үстерү» китабында тел дәресләрендә картиналар белән эшләү методикасы да бар: *«Кайбер кешеләр картина белән эшләү баланы реаль дөньядан читкә алып китә дигән карашларын әйтеп, картина белән эшләүне гамәлдән чыгардылар»* [Фазлулла, 1934, б. 26]. Автор диккатьне картинаның темасына, эчтәлегенә юнәлтә, сораулар нигезендә хикәя төзү, картинада сурәтләнгән вакыйгаларны аңлату, укучыларның әлеге вакыйгага мөнәсәбәтен ачыклау кебек эш юлларын күрсәтә, үзе бер картина урнаштырып, аның белән эшләү үрнәген бирә. Гомумән

алганда, картиналар белән эшләү методикасы бүген дә бик актуаль: укучыларны рәсем сәнгатен кабул итәргә әзерләү (рәссамның иҗаты белән таныштыру, картинаны сүзсез уку, терәк сүзләр белән таныштыру), картинада кулланылган төсләрне ачыклау, алгы һәм арткы план яссылыгын билгеләү, бер төстәге предметларны табу, предметара охшашлыкны билгеләү, картинаның идеясен ачу, план төзү, телдән хикәя төзетү, сочинение язу һ.б. [Шәкүрова, 2012, б. 58].

Мөхәммәтхан Фазлуллин башлангыч мәктәптә сөйләү һәм язу телен үстерүдә сүзлекләрнең әһәмиятен билгеләп үтә. *«Сүзлек хәзинәсе ярлы булган бала үз фикерен телдән дә, язма рәвештә дә төгәл, анык итеп әйтеп бирә алмый... Иншалар яза белү ул язучының (укучының. – Ш.М.) түбәндәге белемнәргә ия булуын күрсәтә:*

*– үзеңнең баштан кичкәннәреңне, күзәтүләреңне аңлатыр өчен кирәкле сүзләрне сайлый белү;*

*– бу сүзләрне мәгънәләренә карап төзеп, формалары ягыннан бәйләнгән, тәмам булган җөмләләр хәленә китерә белү;*

*– уйларыңны эзлекле рәвештә бәян итү-аңлату өчен аерым җөмләләрне үзара берләштереп, бербөтен хәленә китерә белү;*

*– язганнарыңны ялгышмыйча укырлык итеп орфографик яктан дөрес яза белү»* [Фазлулла, 1934, б. 39].

М.Ә. Фазлуллин «Башлангыч мәктәптә тел үстерү» дигән хезмәтенең икенче бүлегендә башлангыч мәктәптә сөйләү һәм язу телен үстерү сүзлек эше, грамматика дәресләре, орфография, стилистика белән тыгыз бәйләнгән булырга, сөйләү теле белән язу теле арасында, тел үстерү эше белән әдәби әсәрләр уку арасында ныклы бәйләнеш сакланырга тиеш дип саный. Автор бу бәйләнешләр арасында иң әһәмиятлесе итеп тел үстерү эшенең стилистика белән бәйләнешен күрсәтә. Стиль хаталарын булдырмау өчен, ул укучыларны төрле стильләр белән таныштырырга, дөрес, кыска, анык җөмләләр белән сөйләргә өйрәтергә тәкъдим итә:

1) җөмләләрне уй аңлашырлык итеп тәмамлау;

2) җөмләләрдә сүзләрне үз урыннарында дөрес кую һәм үзара дөрес бәяләү;

3) җөмләләрне үзара бәйләнешле итеп төзү;

4) теманы төгәлләү: уйны башлау, дәвам итү, нәтиҗәләү;

5) материалның эчтәлегенә карап, үзенә туры килгән стильне куллану;

6) тышкы бизәлеш: сөйләгәндә интонация, паузаларны дөрес кую, кызыл юлларны дөрес күрсәтү һ.б. [Фазлулла, 1934, б. 53].

М.Ә. Фазлуллин «Татар теле методикасы» китабының күп өлешен орфографиягә өйрәтү методикасы алып тора.

Шулай итеп, М.Ә. Фазлуллин методик-дидактик рухта язылган әлеге хезмәтләрендә күп еллар туплаган тәҗрибәсе белән уртаклаша: ул – оста педагог, методист, тел белгече. Кириллицага күчүдә зур өлеш керткәнлеге өчен тәнкыйтьләнеп, аның методик һәм лингвистик эшчәнлеге бик озак еллар күләгәдә калды [Кәримуллин, 1997, б. 20].

Авторның һәр мәкаләсен, һәр китабын диярлек җентекләп тикшереп чыккач, шундый фикергә килдек: Мөхәммәтхан Фазлуллинның педагогика, дидактика, татар телен укыту методикасы, тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге югары бәягә лаек.

**Әдәбият**

*Кәримуллин Ә.* Тел –милләтнең сакчысы. – Казан: Татар. Кит. нәшр., 1997. 256 б.

*Мортазина Л.Р.* Мөхәммәтхан Фазлуллинның фәнни-педагогик эшчәнлеге (1883–1964) // Фәнни Татарстан. 2016. № 3. Б. 105–110.

*Фазлулла М.* Иҗтимагый тәрбия // Мәгариф. 1921. №1–2. Б. 27–36.

*Фазлулла М.* Иҗтимагый тәрбияне ничек гамәлгә куярга? // Мәгариф. 1921. № 3–4. Б. 18–13.

*Фазлулла М.* Тәрбиядә дәхле булган эчке һәм тышкы сәбәпләр // Мәгариф. 1921. № 7–9. Б. 43–56.

*Фазлулла М.* Дикъкатьне тәрбияләү турында // Мәгариф. 1926. № 4. Б. 85–95.

*Фазлулла М.* Баланың теле ничек ачыла (Баланың психологиясеннән). Казан: Татгосиздат, 1922. 32 б.

*Фазлулла М.* Дидактика кагыйдәләре. – Казан: Татгосиздат, 1922. 43 б.

*Фазлулла М.* Икенче баскыч мәктәпләрдә һәм педагогия техникумнарында грамматика күләме түбәндәгечә булырга тиеш // Мәгариф, 1927. № 8. Б. 31–33.

*Фазлулла М.* Яңалифтә тыныш тамгалары // Мәгариф. 1929. № 1, 2. Б. 18–24, 39–42.

*Фазлулла М.* Башлангыч мәктәптә тел үстерү. (Инструктив-методик кулланма). – Казан: Татгосиздат, 1934. 55 б.

*Шәкүрова М.М.* Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры XX гасыр). Казан: Ихлас, 2012. 144 б.

***Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре,*
*Татарстан Республикасының атказанган укытучысы*

УДК 811.512.145

***Г.Г. Батыршина,***
***В.М. Гарипова-Хәсәншина***

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ВӘГАЗЬ ТЕКСТЛАРЫ БЕЛӘН ЭШ
## (Россия ислам институты мисалында)

В процессе преподавания татарского языка студентам-теологам одним из важнейших направлений в плане развития устной и письменной религиозной профессиональной речи является работа над текстами религиозного, проповеднического характера. Данный процесс включает в себя несколько этапов, охватывающих почти все основные области татарского языкознания. Работа над текстами проповеди направлена на развитие навыков профессиональной (религиозной) речи и является неотъемлемой частью занятий по татарскому языку у студентов-теологов. В статье авторами делается попытка анализа основных этапов работы в этом направлении, выделяются актуальные моменты на пути формирования у студентов теологического направления навыков устной и письменной речи.

**Ключевые слова:** проповедь, татарский язык, звуковой состав, теология, арабо-персидские заимствования, религиозная лексика.

In the process of teaching the Tatar language to students of theology, one of the most important areas in terms of the development of oral and written religious professional speech is the work on texts of a religious, preaching nature. This process includes several stages, covering almost all the main areas of Tatar linguistics. Work on the texts of the sermon is aimed at developing the skills of professional (religious) speech and is an integral part of the Tatar language classes for theological students. In the article, the authors make an attempt to analyze the main stages of work in this direction, highlight the actual moments on the way to the formation of students of theological direction of the skills of oral and written speech.

**Keywords:** sermon, Tatar language, sound composition, theology, Arabic-Persian borrowings, religious vocabulary.

Хәзерге вакытта телгә өйрәтүнең күптөрле ысул, алымнары бар. Алар телне өйрәнүченең (һәм шул исәптән өйрәтүченең дә) үз алдына куйган максат-бурычларына бәйле. Тәҗрибә шуны күрсәтә: бүген телне өйрәнүчеләргә көндәлек сөйләм нигезләрен үзләштерү генә җитми, алар еш кына теге яки бу һөнәр белән бәйле зуррак максатлар куялар. Һөнәри уку йортларында да бу мәсьәләгә аерым игътибар бирелә. Нигездә, телне һөнәри лексика һәм һөнәри сөйләм стиленә мөнәсәбәттә өйрәнү, бу өлкәдә белем һәм күнекмәләр формалаштыру, ныгыту телне үзләштерүнең алдагы этабы санала. Бу этапка телне өйрәнүче билгеле бер лексик-грамматик белемнәр белән, ягъни көндәлек сөйләм калыпларын һәм формаларын үзләштергән хәлдә килсә, күпкә яхшырак, билгеле. Һөнәри сөйләм лексикасы һәм калыплары шул база

нигезендә алга таба үстерелә, камилләштерелә. Ләкин чынбарлык, ягъни телне өйрәнүгә бирелгән вакытның чикле булуы бу процессны (ягъни татар телен җитәрлек дәрәҗәдә яхшы белгән дини кадр әзерләүне) интенсив төстә алып баруны таләп итә. Бу теология юнәлешендә укучы студентларга да кагыла. Студент-теологлар һөнәри лексика белән татар теленең беренче дәресләреннән ук таныша башлый. Авазларның дөрес әйтелешен ныгытуны максат иткән дәресләрдә дә дини сүзләр төп урынны алып тора. Алга таба аларның күләме арта бара. Бу очракта, булачак теологларга күпмедер дәрәҗәдә гарәп теле ярдәмгә килә, чөнки ислам тематикасына кагылышлы лексика, белгәнебезчә, чыгышы белән, нигездә, гарәп теленә мөнәсәбәтле.

Әлеге мәкаләбездә Россия ислам институтының теология юнәлешендә белем алучы студентларын телгә өйрәтү процессында вәгазь текстлары белән эшләгәндә актив кулланылган алымнарга, аларга кагылышлы актуаль мәсьәләләргә тукталып үтәрбез. Вәгазь текстлары белән эш, – бу очракта, сөйләмне шомарту, һөнәри лексиканы баетуның уңышлы һәм шул ук вакытта күп этаплы булган бер төре. Вәгазь текстларының лексик-грамматик һәм синтаксик-стилистик яктан шактый катлаулы булуы сәбәпле, әлеге эш бер генә яссылыкта алып барыла алмый, билгеле. Бу процесс, берничә этаптан гыйбарәт булып, үз эченә татар тел белеменең барлык юнәлешләрен дә диярлек ала.

Вәгазьләр белән эшләүнең башлангыч этабында, һичшиксез, структур-композицион яктан да, тел-стиль нисбәтеннән дә гадирәк булган текстлар сайлап алына. Бу этапта укытучы үз эшендә өлешчә аппроксимация принцибына да таяна.

Текстның гомуми мәгънәсен ачыклаганнан соң, иң беренче чиратта, текстның яңгырашы белән эш алып барыла. Бу этап турыдан-туры орфоэпия, просодика, орфография мәсьәләләренә барып тоташа. Телне өйрәнүчеләрдә, нигездә, консонантизмда татар теленең увуляр [к], [г], [ң] авазлары берникадәр авырлык тудыра. Бу очракта кече тел [қ], [ғ] тартыкларының әйтелешен ныгытуда студентларга гарәп теле ярдәмгә килә дип әйтә алабыз, чөнки алар гарәп телендә дә бар. Гарәп теле дәресләрендә яхшы үзләштерелгән булсалар, алар татар телендә әллә ни кыенлык тудырмый. Монда хәтта кайбер студентларның йомшак әйтелешле [г] авазын увулярлаштыруын да күзәтергә мөмкин. Мисал өчен, *түгел, нигез, гөнаһ* кебек сүзләрне студентлар еш кына [түғэл’], [ниғыз’], [ғонаһ] дип әйтәләр. Һәм, киресенчә, сүз башында *акыда, ашура, алим* кебек гарәпчәләштерү дә күзгә ташлана.

Вокализмга килгәндә, сузыклар арасында аеруча [а], [о], [ы] авазлары аерым игътибар таләп итә. Дөрес әйтелешне ныгыту максатында, татар теленең көндәлек сөйләменә караган сүзләр белән беррәттән, *Коръән, дога, ахирәт, васыять, кыямәт, рамазан, гыйбадәт, йола, фарыз, ышану* һ.б. кебек дини лексикага караган берәмлекләр дә актив кулланыла.

Сөйләмдә, белгәнебезчә, авазлар, нигездә, үзләре генә килми, башка авазлар чолганышында булып, «сөйләм агымында нинди аваз

белән янәшә булуына, нинди фонетик шартларда килүенә карап, авазлар төрле үзгәрешләр кичерәләр» [Татар грамматикасы, б. 30]. Шуңа күрә ассимилияция *(мөселманнар, мөэминнәр, Коръәннән, имамнан* (мөселманлар, мөэминләр, Коръәндән, имамдан түгел), *намазсыз)*, аккомодация (***ш****аһит* – ***ш****әһит,* ***м****охтаҗ* – ***м****өгаллим,* ***х****аҗ* – ***х****әдис, хи****җ****аб* – *ха****җ****и га****ф****ил* – *га****ф****у*), редукция *([күңле] – күңеле, [ба°рсы] – барысы, халкы, холкы, милке*), сингармонизм *(мәчет, мәхаллә, хәзрәт, җәннәт, фарыз, сөннәт, савап, тәүбә, тәкәббер, золымлык, нәфес һ.б.)* кебек күренешләрне дә читләтеп үтү мөмкин түгел.

Сингармонизмга килгәндә, дини текстларда кулланылучы *иман, ислам, исраф, китап* кебек алынма сүзләр сингармонизмга буйсынмасалар да, студентлар рәт гармониясен яхшырак үзләштерәләр. Ирен гармониясен әйтелештә хәтердә калдыру бераз авыррак бара. Аны ныгыту максатында өйрәнелүче текст кысаларында очраган сүзләр белән аерым эш алып барыла. Мәсәлән: «Беренче *мөселманнар* иманның тәмен татыганнар» [Шура. № 7. 2015. Б. 18]; «Аллаһ Раббыбыз һәрберебезгә *холык*-фигыльләребезне камилләштерергә ярдәм итсен» [Әс-сәләм. 2017. № 4. Б. 5 ]; «Дога – ...әлеге эшнең ахыры хәерле булуын, нәтиҗәләрнең файдасын күрүдә Аллаһка *өмет* баглау, ышаныч белдерү ул» (Шура. 2014. № 6. Б. 71); «*Тормышта* шуны күзәтеп була: үзләре кимчелекләр чокырына төшеп баткан усал һәм начар кешеләр башкалардагы яхшы сыйфатны күрә алмыйлар» [Шәрәфетдин, б. 51] ) җөмләләрендә билгеләнгән сүзләрнең (*[мөсөл'ман], [холоқ], [өмөт], [тормош]*) һ.б.. берәмлекләрнең дөрес әйтелешен орфоэпик нормаларга туры китереп өйрәтү сорала.

Орфоэпия кысаларындагы тагын бер юнәлеш – студентларның игътибарын әйтелеш белән язылыш туры килмәгән очракларга юнәлтү. Бу гарәп алынмаларында еш күзәтелә. Вәгазь текстларында еш очраучы шундый сүзләр: *вәгазь [wәғәз'], гыйбадәт [ғибәдәт], һидаять [һидәйәт], канәгать [кәнәғәт], шәригать [шәриғәт], сәлам [сәләм], гыйбарә [ғибәрә], мөбарәк [мөбәрәк], гадәт [ғәдәт]* һ.б. Мәсәлән: «Ислам дине Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән ризыкка, саулык-сәламәтлеккә, байлыкка, эш урынына *канәгать* булырга өнди» [Шура. 2014. № 7. Б. 37]; «*Гыйбадәт* рухыбызны баета, безне гөнаһлардан саклый һәм иң кыйммәтле нәрсәбезне – иманыбызны ныгыта» [Ислам дине нигезләре, б. 144].

Вәгазь текстлары белән эш барышында орфография шулай ук аерым өйрәнү объекты булып тора. Беренчедән, студентларга теге яки бу терминның һәр очракта да гарәп теленнән хәрефкә-хәреф күчерелмәвен аңлатырга кирәк. Икенчедән, вәгазь текстларында, дини язмаларда бер үк гарәп алынмасының төрлечә язылуы кыенлыклар тудыра. Хәзерге вакытта ислам диненең торган саен актуальләшә баруы дини эчтәлекле текстларда гарәп сүзләренең күләме артуга китерде, архаиклашкан берәмлекләр кире әйләнешкә керде. Алар арасында, апеллятив лексика белән беррәттән, антропонимнар да (Мәүлет – Мәүлед, Мөхәммәт – Мөхәммәд, Рәшит – Рәшид (Рашид),

Фәрит – Фәрид, Малик – Мәлик, Фатыйма – Фатима һ.б.), топонимнар (Гарәпстан – Гарәбстан, әл-Әкъса – әл-Акса, әл-Әзһәр – әл-Әзһар һ.б.) да бар. Аларның язылышларындагы орфографик төрлелек вәгазь текстларында да чагылыш таба. Әйтик, *вазгыять, хатыйп, вазифа, инкяр, рухи, фатиха, хәрам, тәүфикъ, һидаять, зәкят, фани, расүл, сәхабә, сәдака, тәһарәт* сүзләренең вәгазьләрдә ике төрле язылып йөртелгән очраклары шактый еш күзәтелә (*вәзгыять, хатыйб, вазыйфа, инкарь, рухый, фатыйха, хәрәм, тәүфыйк, һидәят, зәкәт, фаный, рәсүл, сәхәбә (сахабә, сахәбә), садака, таһәрәт (тәһәрәт) һ.б.*). Мәсәлән, «Кешенең *рухый* тәрбиясенә, иң беренче чиратта, көчле рухлы шәхесләр йогынты ясый» [Шура. 1914. № 7. Б. 13]; «Бу йорт кешеләренә ... фәрештәләр *фатыйха* бирер» [Шунда ук, б. 6]; «Шулай итеп, без бу *фаный»* дөньяда имтихан тотабыз [Шура. 1914. № 6. Б. 115]; «Аллаһы Тәгалә ... тәүфыйксызлыкта, намазсызлыкта, динсезлектә йөрүчеләргә *тәүфыйк-һидәят* ... насыйп кылса иде» [Шунда ук, б. 29]; «Бер генә бөек әхлак бар: ул – үзеңне *инкарь* итеп, Аллаһ ризалыгы өчен башкаларга игелек кылу» [Фазлыев, 2016, б. 528]. Бу сүзләрне бердәм язылыш нормаларына туры китерү – хәзерге вакытта актуаль мәсьәләләрнең берсе. Һичшиксез, «әйтелештәге бердәмлек, ягъни сөйләмнең әдәби нормаларга нигезләнгән булуы сөйләгәнне тиз һәм дөрес аңлауга китерә, аның матурлыгын һәм аһәңен ныгыта, шул нигездә телгә үзенең төп функциясен – аның аралашу чарасы булуын тулырак үтәргә мөмкинлек бирә» [Татар грамматикасы, б. 103].

Интонация һәм просодика мәсьәләләренә килгәндә, җөмлә ахырында килгән сүзләрдә ритмик буын ахырындагы сузыкларны сузу һәм интонациянең күтәрелеп китүе күзәтелә. Без моны гарәп теле тәэсире белән бәйледер дип фаразлыйбыз. Бу күренеш тә, һәр студентта очрамаса да, текст яңгырашында игътибардан читтә калырга тиеш түгел.

Вәгазь текстларының лексикасы – аерым бер этапны тәшкил итүче эш төре. Билгеле, телне өйрәнүче монда аңлашылмаган сүзләрне тәрҗемә итү белән генә чикләнми. Аның игътибары әлеге текст тукымасындагы алынма сүзләрнең, нигездә, гарәп-фарсы лексикасының тоткан урынына юнәлтелә. Гомумән, «Телнең үз сүзләре белән чит теллардән кергән (алынма) сүзләр нисбәте – шактый катлаулы һәм четерекле мәсьәлә» [Юсупов, б. 8]. Дини лексиканың нигезен тәшкил иткән гарәп алынмалары XX гасырда «татар лексик фонды эчендә стабильләшкән, киң семантик һәм структур системаны тәшкил итә торган төркемгә әвереләләр» [Татар лексикологиясе, б. 78].

Сүзнең семантикасы белән эшләгәндә, аларның контекстуаль мәгънәсен ачыклау теологлар өчен аеруча мөһим, чөнки тексттан алган мәгълүмат ике төрле аңлашылырга тиеш түгел. Монда студентларның игътибары җәлеп ителергә тиешле төп мәсьәләләрнең берсе – гарәп телендә күп мәгънәгә ия булган тегә яки бу лексик берәмлекнең татар телендә бер генә мәгънәдә кулланылырга мөмкин булуы. Мисал өчен, *тәкъвалык* сүзен алыйк. «Татар теленең аңлатма-

лы сүзлеге»ндә бу берәмлек «тәкъва булу, ягъни дингә бик бирелгән, диндарлык сыйфаты» мәгънәсендә килә [ТТАС, 3 т., 1981, б. 213]. Ислам дине күзлегеннән караганда, *тәкъвалык* – күпмәгънәле сүз. Ул «ислам алып килгән, иманга, гыйбадәткә, кешеләр белән мөгамәләгә, әхлакка бәйле булган бөтен нәрсәне үз эченә ала» [Шура. № 6. 2014. Б. 40]. Коръәндәге «Бәкара (Сыер)» сүрәсенең 177 нче аятендә: «Игелек (тәкъвалык) – йөзләрегезне Көнчыгыш яки Көнбатыш тарафына юнәлдерүегез түгел. Ләкин чын игелек – Аллаһка, Ахирәт көненә, фәрештәләргә, Китапка һәм пәйгамбәрләргә иман китергән; кадерле булганыннан (мал-мөлкәттән) туганнарына, ятимнәргә, мескеннәргә, юлда калганнарга, теләнчеләргә һәм коллар азат итүгә мал сарыф иткән; (фарыз) намазны укыган, зәкят биргән, вәгъдәләшкән чакта сүзләрендә торган, кыенлыкта, авырлыкта һәм афәтләр вакытында сабыр иткәннәр ул. Әнә шулар – (иманнарына) тугрылыклы кешеләр һәм әнә шулар (яман эшләрдән һәм көферлектән үзләрен саклаган) тәкъвалык ияләре» дип тәгаенләнә [Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә, б. 40] Әлбәттә, мондый күренеш студентларда беркадәр авырлыклар тудыра һәм игътибар таләп итә.

XX гасыр башларында, хәзерге татар әдәби теле аякка басканда кулланылыштан төшеп калган бер төркем алынма лексика XX гасыр ахырында актив сүзлек составына кире кайтты, әмма аларның барысы да тел кулланучыларның киң катламына аңлаешлы түгел, аларның мәгънәсенә төшенү өчен, сүзлекләргә мөрәҗәгать итәргә туры килә [Татар лексикологиясе, б. 88]. Мәсәлән, бүгенге студентларның күбесенә инде халыклашкан (яисә халыклашып бара торган) *кавем, форсат, могтәбәр, золым, мөкатдәс, мөгамәлә, сәгадәт, хасият, шигарь* кебек сүзләр дә таныш түгел. Дини текстларда очрый торган күп кенә гарәби чыгышлы лексик берәмлекләр шулай ук аңлашылмый. Мисал өчен *гафләт, хилаф, тәкълид, хитаб, шәрех, шөкрана, җәлаләтле, мөфәссир, мөҗтәһид, игътикяф, җаһил, фазыйләт, рия, гаһед* кебек сүзләрне күрсәтергә була. Әлбәттә, текст эчендә мондый берәмлекләргә аңлатмалар бирелгән очраклар да бар, «ләкин хөтбә-вәгазьләр телендә кулланылган барлык гарәп-фарсы сүзләрен дә шәрехләп бару мөмкин түгел. Күп очракта аларның татар телендәге бердәйлекләрен дә табу читенрәк» [Нуриева, б. 257]. Шуңа күрә мондый очракларда укытучы әлеге берәмлекләрне аңлатып китәргә тиеш. Мәсәлән, «Шура» журналында [2014, № 6] басылган кайбер вәгазьләрдәге җөмләләр: «Аның үлеме хакында *мөфәссирләр* төрле фикерләр, риваятьләр китергән» [б. 29]; «Әлеге сүзләр мәчеттә җәмәгать намазында катнашырга, анда *игътикяфта* булырга, ... вәгазьләрне тыңларга этәрә» [б. 50]; «Доганың *фазыйләтләре* байтак» [б. 72]; «Суфьян әс-Сәүри ... һәм аңа *тәкълид иткән* башка галимнәр дә бу мәсьәләгә шундый ук караштa булган» [б. 110]; «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләне зикер итү исә – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң *җәлаләтле*, иң камил, иң зур гамәл» [б. 25]; «Ләкин берәү... Алаһыга биргән *гаһден*, кешеләргә биргән вәгъдәсен үтәсә, ... ачлык яки сугыш

килгәндә сабыр итсә, Аллаһыга чыдамлык күрсәтсә, әнә шул эшләр – изгелекләр» [Әс-сәләм, №4, 2017, б. 5] һ.б. Биредә *мөфәссир* сүзенең – ‘аңлатучы, ачыклап бирүче’, *игътикяф* – ‘мәчеттән чыкмыйча берникадәр вакыт гыйбадәт кылу’, *фазыйләт* – ‘өстенлек’, *тәкълид итү* – ‘иярү’, *җәлаләт* сүзенең – ‘олылык, югары дәрәҗәлек’, *гаһед* сүзенең ‘йөкләмә; килешү; өскә алган бурыч; ант итү’ мәгънәләрендә кулланылганын аңлатып китү сорала. *Гаҗиз калу, гуаһлык бирү, дәфен ителү, шикаять итү, тәвәккәл кылу, зиярәт кылу* кебек конструкцияләр дә тәрҗемә һәм анализ таләп итәләр.

Хөтбә-вәгазь теле лексикасында төрки-татар сүзләре дә зур урын алып тора. Бу сүзләр әдәби телнең нигезен тәшкил итә, җәмгыятьтә, тормыш-көнкүрештә иң мөһим һәм кирәкле төшенчәләрне белдерә. Шулай да бу берәмлекләрнең кайберләре киң кулланылыштан төшеп калган. Телнең пассив сүзлек составына күчсәләр дә, аерым стильләрдә (мисал өчен, вәгазь телендә) алар шактый еш кулланыла. Бу да, үз чиратында, бүгенге студентка текстны аңлауны кыенлаштыра. Мәсәлән, *тәңре, ыру (ыруг), кардәш, угыл, кол, кемсә, ярлыкау, ярату (яралту), әйләү, сыгыну, ою, кылу, ошбу, олуг (олуглау), илә, кеби* һ.б. Шуларның кайберләренә тукталып китик.

Вәгазьләрдә *кылу* фигыле еш кулланылган. **Кылу** – 1. Кит. Нәрсә дә булса эшләү, нинди дә булса эш башкару. // Нәрсәне дә булса оештыру, үткәрү; ясау. 2. Ярдәмче фигыль функциясендә. 1) китү; 2) дини ритуалны башкару» мәгънәсен аңлата [ТТАС, II, 1979; б. 221]. Җ. Фазлыев вәгазьләрендә дә ул шул мәгънәләрдә кулланыла. Мәсәлән: «...Аллаһның кушканына риза булдылар һәм Аллаһка *тәвәккәл кылдылар*»; «Аллаһка гына *гыйбадәт кылырга* тиешлекләрен исләренә төшереп торсыннар...»; «Алар, биш төрле таудан таш китереп, шушы Кәгъбәтулланы бина *кылдылар*» (Фазлыев, 2016, б. 162); «Ибраһим галәйһиссәлам улы Исмәгыйльне корбан итеп чалырга барганда, аларга шайтан килә һәм Раббыларына буйсынмаска *вәсвәсә кыла* башлый» [«Шура», 2014, б.17]; «Гает намазы ни рәвешле *кылына*?» [Шунда ук, б.104] Шулай ук вәгазь текстларында *хаҗ кыла, дога кыла, насыйп кылса, шөкрана кылырга* һ.б. кебек дини стильдә генә кулланыла торган берәмлекләрне күрсәтергә мөмкин. Әйтергә кирәк: бу мисалларда *кылу* төрки-татар сүзе гарәп сүзләре белән килеп, тезмә фигыль хасил итә.

**Ярату** һәм **яралту** берәмлекләре хөтбә-вәгазьләрдә мәгънәдәш сүзләр буларак кулланыла. Татар теленең хәзерге сүзлек составында *яралту* сүзе юк. Ул аңлатмалы сүзлектә дә теркәлмәгән. Ә андагы *ярату* сүзенең «*барлыкка китерү, бар итү, тудыру*» һәм «яралу, ялатылу» фигыльләрендәге «Туу, барлыкка килү» мәгънәләре Аллаһы Тәгалә тарафыннан җиһандагы барлык тере һәм тере булмаган нәрсәләрнең барлыкка китерелүе төшенчәсенә туры килә [ТТАС, III, 1981, б. 645]. Мисал: «Аллаһ Раббыбыз җир һәм күкләрне, җир белән күк арасында булган мәхлүкатларның барысын нинди гүзәл итеп *яралткан*» [Фазлыев, б. 513]; «Аллаһы Тәгалә дөньяны юктан бар ит-

кәндә барча җаннарны да *яралткан...*» [Шунда ук, б. 540]; «Атабыз Адәм (г.с.) белән анабыз Һәва (р.г.) *яралтылгач* та җәннәттә яшәгәннәр» [Шура. 2014. №6. Б.122] һ.б.

**Кардәш.** Аңлатмалы сүзлектә ул: «1. Уртак ата-ана яки әбибаба буенча нәсел, туган кешеләр, иптәш, дус, тугандаш. 2. Аерым тезмәләр составында: уртак сыйфатлар буенча «якын, үз кеше» мәгънәсендә бирелә [ТТАС, II, 1979, б. 59]. Вәгазьләрдә бу сүз аерым да, *дин*, *мөселман* сүзләре тезмәсендә дә эндәшү, мөрәҗәгать итү гыйбарәләре булып хезмәт итә. Шулай ук алар олылау, хөрмәтләү сыйфатлары белән дә кулланылалар. Мәсәлән: *мөхтәрәм кардәшләрем, хөрмәтле дин кардәшләрем, газиз мөселман кардәшләрем* һ.б. «Газиз дин *кардәшләрем*! Раббыбыз безгә ... насыйп иткән икән, ураза тотып, гамәл-гыйбадәттә булып, Раббыбызның чиксез рәхмәтенә ... ирешергә һәрбарчаларыбызга да насыйп итсә иде» [Шура. 2014. №6. Б. 37]; «Бүген мөселманнар вак кына сәбәп өчен дә тарткалашырга, бер-берсен кимсетергә генә тора, начар сүзләр әйтешеп, ... үзләрен дә кимсетәләр, *кардәшләрен* дә рәнҗетәләр, мөселманлыкның да дәрәҗәсен төшерәләр» [Әс-сәләм. № 4. 2017. Б. 4.]

**Кемсә.** Хәзерге татар әдәби телендә архаик катламга күчкән бу сүз, борынгы әдәби телдәге «кем ирсә, кем әрсә, кем булса (шул)» гыйбарәсеннән кыскарып, *кемсә* рәвешендә кулланыла һәм «кемдер берәү» мәгънәсендә йөри [Әхмәтьянов, б. 131]. Аңлатмалы сүзлектә дә ул «кем» һәм «кеше» мәгънәләрендә бирелә [ТТАС, II, 1979, б. 84]. Вәгазьләрдә әлеге сүз шулай ук «кеше» мәгънәсендә кулланыла: «Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә утырган һәм басып торган *кемсәләрнең* саны кадәрле салават ирештер» [Шура. 2014. № 6. Б. 25]; «Аллаһдан башкаларга табынучы *кемсәләрне* сүкмәгез...» [Шунда ук, б. 118].

**Ярлыкау**. Дини сөйләмдә бу сүз «Гафу итү, аклау, кичерү, гөнаһларын йолу» мәгънәсендә йөри [ТТАС, III, 1981, б. 648]. Вәгазьләрдә дә ул шул мәгънәдә актив кулланыла. «Бу кичәләрдә күп итеп гыйбадәт кылырга, Аллаһыдан гөнаһларны *ярлыкавын* сорарга һәм тәсбих намазы укырга кирәк» [Шура. 2014. Б. 86]; «Аллаһ Раббыбыз әйтә безгә: кайсыгыз саташып, бәндәчелек белән берәр залимлек эшлиме, һәркем шул эшләгән начарлыгын танырга, Аллаһка мөрәҗәгать итеп, тәүбә кылырга тиеш, Аллаһтан башка беркем дә гөнаһларыгызны *ярлыкый* алмый» [Фазлыев, б. 357].

**Олуг.** Вәгазьләрдә күптәннән килгән төрки катламның кулланылышы *олуг* сүзендә дә чагылыш таба. Әлеге сүзнең этимологиясе һәм мәгънәләре турында Р. Әхмәтьянов болай дип яза: «Гомум төркидәге *улуг, уллуг* «олы, зур» сүзе борынгы төрки һәм монгол телләрендәге «дәрәҗәле кешеләр утырган махсус ястык» сүзләреннән килә» [Әхмәтьянов, б. 154]. Аңлатмалы сүзлектә ул «бөек, олы» мәгънәләрендә тәгъбирләнә [ТТАС, II, 1979, б. 467]. Шул мәгънәви җирлектә сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә *олуглау* (ихтирам итү, хөрмәтләү, хурлау), *олуглык* (зурлык, мәртәбәлек; олуг булу хәле) һ.б.

сүзләр дә ясалган. Вәгазьләрдән кайбер мисаллар: «Бергә яшәгән һәр минутны Аллаһтан *олуг* нигъмәт дип белик, шөкрана кылыйк, ягъни матур итеп яшик» [Фазлыев, б. 516]; «*Олуг* гает көнендә бәйрәм намазларын укырга, корбаннар чалырга, күңелләребездәге мәрхәмәт, ... тирә-юньдәгеләргә җиткерергә язсын!» [Шура. 2014. № 6. Б. 8]; «Без кешене иң яхшы кыяфәттә яраттык», – дип әйткән Аллаһы Тәгаләгә *олуглауларыбыз* булсын!» [Шәрәфетдин, б. 3] һ.б.

**Ошбу** берәмлеге хәзерге татар әдәби теле өчен искергән сүз булып тора, ул *бу, шушы* дигән мәгънәне аңлата. Вәгазьләрдә дә әлеге мәгънәдә еш кулланыла. «*Ошбу* очракта шушы һәр ике юнәлештә һәм матди һәм рухи өлкәдә дә армый-талмый тырышып эшләү кирәклеге көн кебек ачык [Шура. 1914. № 6. Б. 71]»; «*Ошбу* вәгаземдә дога турында сөйлим ...» [Шунда ук, б. 69]; «Һәр кабилә рәисе ошбу шәрәфле эшне үзенә алырга тели» [Шура. 2016. № 7. Б. 215] һ.б.

Вәгазь тексты белән эшләүнең иң соңгы этапларыннан берсе – текст синтаксисы юнәлешендәге эш. Бу очракта вәгазь текстының структур-композицион үзенчәлекләре турында студентларда тулы күзаллау формалаштыру, аларның мөстәкыйль рәвештә текстның аутентик вариантын төзүенә, студентның әлеге вәгазь текстын татар теленең орфоэпик, лексик-грамматик, синтаксик-стилистик нормалары нигезендә сөйли алуына ирешү күздә тотыла.

Вәгазь текстлары белән эш – күпэтаплы катлаулы процесс. Әлеге эшнең нәтиҗәле булуын раслаучы төп факторларның берсе – студентларның өйрәнелүче текстта очраган дини сүзләрне, дини лексикага нигезләнгән конструкцияләрне башка контекстуаль тирәлектә дә дөрес итеп куллана белүләре. Ул шактый күп вакыт һәм көч таләп итә. Әмма шуннан башка булачак теологларның һөнәри лексиканы, дини стильдә кулланылучы сөйләм калыпларын үзләштерүенә, аларда бу юнәлештә билгеле бер белем һәм күнекмәләр формалашуга ирешү мөмкин түгел. Бу юнәлештә эш алып барганда, проектлар, когнитив, коммуникатив технологияләр актив файдаланыла. Шул рәвешчә, теология юнәлешендә белем алучы студентларда татар әдәби теле нормаларына нигезләнгән һөнәри (дини) сөйләм күнекмәләре формалаштыру бүгенге көндә телгә өйрәтүдә актуаль юнәлешләрнең берсе саналган хәлдә, уку-укыту процессында катнашучы һәр ике яктан да (укытучыдан да, студенттан да) зур тырышлык таләп итә.

## Әдәбият

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 272 б.

Ислам дине нигезләре. Казан: «Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты, 2017. 608 б.

*Нуриева Ф.Ш.* Дини риторика: уку ярдәмлеге / Ф.Ш. Нуриева, Г.С. Нуриев, Ф.Г. Миңнуллин. Казан: Казан университеты, 2013. 418 б.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Ф.М. Хисамова. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2015. 1 т. 512 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2016. 2 т. 392 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977, 1979, 1981.

*Юсупов Р.А.* Икетеллелек һәм сөйләм культурасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 223 б.

**Чыганаклар**

Әс-сәләм. № 4. 2017.

*Фазлыев Җ.* Йөз дә бер вәгазь. Казан: «Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты, 2016. 576 б.

*Шәрәфетдин М.* Бәхетлеләрнең серләре. 3 китап. Казан, 2010. 94 б.

*Шәрәфетдин М.* Бәхетлеләрнең серләре. 4 китап. Казан, 2012. 106 б.

Шура. 2014. № 6, № 7.

Шура. 2016. № 7.

***Батыршина Гүзәл Гомәр кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент, Россия ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы укытучысы*

***Гарипова-Хәсәншина Венера Мәкмүн кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Россия ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы укытучысы*

УДК 784.4

*Г.Г. Гыйлемҗанова*

# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МӨНӘҖӘТ ЖАНРЫН ИСЛАМ ҺӘМ ГОМУМТӨРКИ ШИГЪРИ-МУЗЫКАЛЬ ТРАДИЦИЯЛӘР КОНТЕКСТЫНДА ЧАГЫШТЫРМА ӨЙРӘНҮ МӘСЬӘЛӘСЕ ТУРЫНДА

В статье рассматриваются вопросы изучения мунаджатов как жанра традиционной музыкально-поэтической культуры татар-мусульман в контексте исламской и общетюркской культуры и необходимости сравнительного анализа этого явления в сопоставлении с жанрами и понятиями родственных культур. Эти вопросы неоднократно затрагивались в работах исследователей духовной культуры татар. На их основе выделяется ряд проблем, связанных с дальнейшим изучением явления мунаджата в татарской культуре в самых разных аспектах.

**Ключевые слова:** мунаджат, традиционная культура, исламская культура, общетюркская культура, сравнительный анализ.

The article deals with the issues of studying munajats as a genre of traditional musical and poetic culture of Muslim Tatars in the context of Islamic and general Turkic culture and the need for a comparative analysis of this phenomenon in comparison with genres and concepts of related cultures. These issues have been repeatedly raised in the works of researchers of the spiritual culture of the Tatars. Based on them, a number of problems are identified related to the further study of the phenomenon of munajat in Tatar culture in various aspects.

**Keywords:** munajat, traditional culture, Islamic culture, common Turkish culture, comparative analysis.

Гомумкешелек цивилизациясенең соңгы дистә еллардагы кискен үсеше традицион мәдәниятнең күп форма һәм жанрлары яшәешенә зур үзгәрешләр кертте. Халык иҗатының байтак элементларын югалту фонында, кайбер формаларның торгызылуы һәм үсүе парадоксаль булып тоела. Ләкин татар мәдәнияте турында сүз алып барганда, традицион культураның аерым жанрлары чыннан да яңа үсеш этабы кичерә. Соңгы дистә елларда татарлар тормышында дини жанрларга, аеруча мөнәҗәтләргә игътибар артты. Бу, беренчедән, Россиядә ислам диненең яңарышы белән бәйле булса, икенчедән, узган гасырның 90 нчы елларында башланган халыкның милли үзаңы үсү, югалган рухи кыйммәтләрне кайтару белән дә аңлатыла.

Мөнәҗәтләр халык арасында гына түгел, профессиональ сәхнәдә дә еш башкарыла башлады. Татар халкының әлеге уникаль шигърimузыкаль жанрын бүген халыкара мәйданнарга чыгарыр вакыт житте. Шуның белән бергә татар мәдәниятендә мөнәҗәтләрнең алга таба үсеше белән бәйле проблемалар да туа тора. Алар исә әлеге беренчел рухи жанрларны ислам һәм гомумтөрки цивилизацияләре контекстында өйрәнүне, ягъни чагыштырма анализга мөрәҗәгать итүне

таләп итә. Бу тикшеренүләр, бер яктан, шигъри-музыкаль традицияләр арасындагы уртаклыкны табарга, аларның зур бер мәдәният яссылыгында яшәгәнлеген аңларга ярдәм итсә, икенче яктан, җирле татар традициясенең уникальлеген ача.

Культурологлар фикеренчә, хәзерге татар мәдәнияте, нигездә, төрки, ислам һәм Европа мәдәниятләре компонентларыннан тора. «Бүген бу категорияләр, эчтәлекләре белән төрле кебек тоелсалар да, культурологик яктан инде кабул ителгән. Тарихтан күренгәнчә, беренче икесе күп гасырлар дәвамында татарларның һәм аларның ата-бабалары мәдәниятенең асылын билгеләде» [Сайфуллина, 2021, с. 43]. Шуның белән бәйле рәвештә, татар мәдәнияте бөтен төрки һәм ислам дөньясының аерылгысыз бер өлеше булып тора.

Ислам мәдәниятендә барлыкка килеп, Идел буе мөселманнарында җирле традицияләр йогынтысында мөнәҗәт үзенчәлекле бер жанр булып формалаша һәм халык теленә *көйләп уку* дип кергән шигъри-музыкаль традиция кысаларында яшәп килә. *Көйләп уку* традициясенең таралуына, бер яктан, ислам диненең Идел буе мөселманнарына үтеп керүе йогынты ясаса, икенче яктан, аның тамырлары исламны кабул иткәнчегә кадәрге чорларга, бик тирән тарихи катламнарга барып тоташа. Бу процесслар охшаш тарихи үсеш кичергән тугандаш халыклар культурасында да үз җирле үзенчәлекләре белән үрелеп формалаша. Шулай итеп, мөнәҗәтләрне ислам һәм гомумтөрки халыкларның шигъри-музыкаль мәдәнияте кысаларында өйрәнү һәм чагыштырма анализ ясау һичшиксез урынлы һәм актуаль.

Бу мәсьәләләр татарларның рухи мәдәниятен өйрәнүче галимнәр – филологлар, әдәбиятчылар, ислам дине белгечләре, шулай ук фольклорчылар һәм этномузыкологлар хезмәтләрендә әледән-әле кузгатылып торды. Билгеле, күп гасырлар дәвамында татарлар Урта Азия, гарәп илләре халыклары белән тыгыз мәдәни элемтәләр булдырганнар. Әлеге мәкалә кысаларында татар халкының мөнәҗәтләрен чагыштырма анализ күзлегеннән өйрәнүдәге кайбер юнәлешләр генә билгеләнер. Шуларның берсен татарларның Урта гасырлар госманлы мәдәнияте белән үзара багланышлары мәсьәләләре тәшкил итә[1].

Идел буе, Урал, Себер һәм Кырым мөселманнары арасында күп гасырлар дәвамында төрки-госманлы авторларының китаплары киң таралган. Шуның белән бергә гомумтөрки шигъри-музыкаль традицияләр уртаклыгы һәм үзара йогынты ясашу турында да фикер йөртергә нигез бар. Бу мәсьәлә беренчеләрдән булып Р. Исхакова-Вамба хезмәтләрендә [Исхакова-Вамба, 1978] китап уку традициясе, шул уңайдан мөнәҗәтләр дә, татар халкының ислам цивилизациясе белән бәйле дини рухлы мәдәнияте буларак өйрәнелә. Мөнәҗәтләрне ул гарәп халыклары мәдәнияте белән үзара бәйләнештә тикшерү

[1] Урта гасырлар төрки әдәбияты һәм мөнәҗәтләр темасын кузгатканда, суфичылык темасы зур бер катлам тәшкил итә. Төрле юнәлешләрне һәм традицияләрне үз эченә алган суфичылык мәсьәләләре аерым эзләнүләрне таләп итә һәм әлеге мәкалә кысаларында каралмый.

омтылышы ясый. Мөнәҗәт көйләренең ритмикасында исә XVI гасыр төрек суфие М.Чәләбинең «Мөхәммәдия»[1] көйләре белән уртаклыгын билгеләп. Ә «Мөхәммәдия» көйләренә, аның фараз итүенчә, үз чиратында гарәпләрнең рухани музыкасы йогынты ясаган [Исхакова-Вамба, 1997, с. 149].

М. Чәләбинең Госманлы җирлегендә язылган «Мөхәммәдия» китабы күп галимнәрнең хезмәтләрендә телгә алына. Аның дини рухлы мөнәҗәтләр белән аваздашлыгы турында Ә. Сибгатуллина да яза[2] [Сибгатуллина, 2000, б. 306]. Соңыннан «Мөхәммәдия» китабын И. Мөхәммәтов махсус татар-төрек әдәби багланышлары яссылыгында тикшерә [Мөхәммәтов, 2006]. Г. Сәйфуллина «Мөхәммәдия» китабын мөселман татарларның шигъри-музыкаль мәдәнияте контекстында өйрәнә һәм аны рецитацияләүдә татарлар белән төрекләр традицияләрендә уртаклыклар булуын фаразлый [Сайфуллина, 2010, с. 154–164]. Ләкин шушы мәдәни багланышлар кысаларында «Мөхәммәдия»нең татарларда һәм төрекләрдә башкарылган көйләре арасында ни дәрәҗәдә уртаклык бар – бу мәсьәлә әлегә ачык булып кала һәм киләчәктә эзләнүләр таләп итә. Шулай ук «Мөхәммәдия» китабын мөнәҗәтләр белән бәйле аспектта өйрәнү дә, безнең фикеребезчә, кызыклы нәтиҗәләргә китерер һәм татар-төрки мәдәнияте тарихының тирән катламнарына юл салыр.

Галимнәр шулай ук татар мөнәҗәтләре белән бүгенге көндә төрекләрдә киң таралган иляһилар арасында күп уртаклыклар булуын билгеләп уза. Ә. Сибгатуллина: «Татар халык иҗатындагы һәм язма әдәбиятындагы мөнәҗәтләр төрек фольклорындагы һәм әдәбиятындагы «иляһи» дигән дини эчтәлекле җырлар жанрына бик охшаш. Мөнәҗәтләр белән иляһилар арасында тышкы охшашлыклар булу белән беррәттән, уртак эчтәлекле һәм формалы әсәрләр дә күп очрый», – дип яза [Сибгатуллина, 2000, б. 320].[3]

Татар мәдәниятендәге мөнәҗәтнең табигатен, эволюциясен, гомумтөрки һәм ислам традицион мәдәниятендә тоткан урынын аңлау, аеруча шигъри-музыкаль традицияләр күзлегеннән тикшерү, бүгенге көндә бу өлкәдәге җитди проблемаларның берсе булып тора. Бу мәсьәләләрнең күп аспектлары Г. Сәйфуллина хезмәтләрендә өйрәнелә. Аның мәкаләләрендә әйтеп үтелгән проблемалар белән беррәттән, татар традицион мәдәниятендә Коръән уку һәм аның белән бәйле көйләп уку традициясе, төрле форма һәм жанрларны бердәм ислам

[1] «Мөхәммәдия» – XVI гасыр төрек суфие Мөхәммәд Чәләбинең татарлар арасында киң таралыш алган һәм көйләп башкарылган китабы.

[2] «Халык авыз иҗаты әсәрләреннән дини рухлы мөнәҗәтләрнең бер төркеме исә, безнең фикеребезчә, турыдан-туры «Мөхәммәдия» белән аваздаш. Шуңа күрә моңа кадәр онытылып килгән, төрки мирасыбызның бер бөртеге булган «Мөхәммәдия» китабына да тиешле бәһасын бирер вакыт җитте кебек, алай гына да түгел, яңа мәчет һәм мәдрәсәләр ачылган безнең заманда «Мөхәммәдияне» уку дәреслеге итеп тә кулланганда, китапка икенче яшьлеге» килүе дә бик мөмкин әле» [Сибгатуллина, 2000, б. 306].

[3] Бу һәм кайбер башка аспектлар шулай ук К. Хөснуллин [Хөснуллин, 2001] һәм М. Бакиров [Бакиров, 2018] хезмәтләрендә дә билгеләп үтелә.

сәнгате традицияләре кысаларында өйрәнү мәсьәләләре кузгатыла һәм мөнәҗәтнең татар мәдәниятендә төрле социаль-мәдәни үзгәрешләр йогытысында билгеле бер трансформация кичереп, үзенчәлекле жанр булып формалашу юлы бәян ителә. [Сайфуллина, 2017, с. 219–234].

Г. Сәйфуллина «Казан илләрендә Вәйсел-Карани» мәкаләсендә [Сайфуллина, 2007, с. 197–202] татар мәдәниятендәге көйләп уку традициясенең Урта гасырлар Төркия җирлегендәге иляһиларның күпгасырлык шигъри-музыкаль традицияләренә барып тоташуын ачыклый. Төрек һәм татар көйләрен чагыштырып, татар мәдәниятен төшенүдә яңа нәтиҗәләргә килә һәм шул ук вакытта биредә берьяклы йогынты турында гына түгел, ә бәлки үзара бәйләнешләр хакында фикер йөртү зарурлыгы мәсьәләсен куя.

Бу юнәлештәге эзләнүләрне дәвам итеп, киләчәктә Идел буе татарларының мөнәҗәтләре белән кырым татарларында киң таралган иляһилар арасында параллельләр үткәрергә мөмкин. Г. Туймованың [Туймова, 2008] кырым татарларының традицион музыкасындагы дини шигъри-музыкаль жанрлар – мәүлид һәм иляһига багышланган эзләнүләре дә әлеге тикшеренүләргә нигез бирә һәм бу күренешләрне киңрәк масштабта күзаллау өчен мөмкинлекләр ача.

Мөнәҗәтләрне гомумтөрки шигъри-музыкаль традицияләр кысаларында өйрәнү мәсъәләсенә килгәндә, биредә тагын бер әһәмиятле юнәлешне билгеләп үтәргә кирәк: бу – аларның борынгы чор эпосы белән бәйлелелеге. Китап уку традициясенең борынгы эпоска барып тоташуы турында М. Бакиров [Бакиров, 2018], М. Хөснуллин [Хөснуллин, 20001], М. Нигъмәтҗанов [Нигмедзянов, 1984], Г. Сәйфуллина [2012. с. 71–84], Н. Шәрифуллина [Шарифуллина, 2014, с. 50–52], Э. Каюмова [Каюмова, 2014, с. 288–291] һ.б. яза. Көйләп уку традициясен бу күзлектән өйрәнгәндә, галимнәр фикеренчә, Идел буенда яшәүче күрше халыклар һәм Урта Азия төрки халыкларының эпик традицияләре арасында байтак параллельләр барлыкка килә.

М. Нигъмәтҗанов мөнәҗәтләрне гомумән эпос үрнәкләре рәтенә кертә. Татар музыкаль эпосын башка халыкларның охшаш жанрлары белән чагыштырып, алар арасында һичшиксез бәйләнешләр һәм халыкара характердагы уртак стилистик үзенчәлекләр булуын әйтә. Хезмәтләрендә ул чагыштырма музыка белеме кысаларында эпик жанрларның ислам музыкаль традицияләре һәм Идел буе халыклары мәдәнияте белән тарихи, генетик багланышларын ачыклау мәсьәләләренә кагыла һәм күп кенә мөнәҗәтләрдә кайбер Идел буе халыкларының борынгы, мәҗүсилек чоры фольклор үрнәкләре белән паралельләр бар, дигән нәтиҗәгә килә. Шулай ук галим эпик көйләрнең ритмик оешмасына– «аларның иң мөһим компонентына» басым ясый. Ул мелодик-ритмик күзәнәкләрне Урта Азия халыкларының эпик мәдәнияте белән чагыштырып өйрәнү зарурлыгын күрсәтә [Нигмедзянов, 1984, с. 3–21].

М. Нигъмәтҗановның узган гасырның 80 нче елларында билгеләгән юнәлешен дәвам итеп, Э. Каюмова татар музыкаль эпосының

борынгы чорлардан башлап бүгенге көнгә кадәр формалашуы һәм үсеше концепциясен тәкъдим итә. «Тугандаш төрки һәм монгол мәдәниятләре фонында татар эпик традициясе мөселман китап сәнгате төсмерен алды»,– дип яза ул. Гасырлар дәвамында татар эпик сәнгатенең ислам мәдәнияте кысаларына күчеп, китап уку традициясе булып формалашуын билгели. Һәм чагыштырма өйрәнүгә килгәндә, татарларның музыкаль-эпик традициясендә өч төп компонентны аера: 1) борынгы төрки-монгол эпик әкиятләре, 2) гарәп-фарсы ислам сәнгате, 3) җирле җыр культурасы» [Каюмова, 2014, с. 290].

Шулай итеп, мөнәҗәт жанрын киләчәктә чагыштырма анализ күзлегеннән өйрәнү мәсьәләсендә галимнәрнең хезмәтләрендә байтак аспектлар билгеләнгән. Һәм кайсы гына юнәлешне алсак та, аны бер яссылыкта, ягъни бер фән кысаларында гына өйрәнеп бетереп булмый. Бүген төрле өлкәдәге галимнәрнең тырышлыгын берләштерү, әлеге күренешне өйрәнүгә комплекслы карау таләп ителә. Чагыштырма музыка һәм сәнгать белеме мәсьәләләрен күтәргән И. Мациевский XXI гасыр башында да бу юнәлешнең әле башлангыч этапта гына булуын әйтә. Музыканы төрле дисциплина фәннәре дәрәҗәсендә гомум художество мәдәнияте контекстында – этнос, регион, ил, дөнья күләмендә өйрәнергә өнди [Мациевский, 2014, с. 6–24]. Димәк, М. Нигъмәтҗановның 1984 елда ук «чагыштырма өйрәнү – киләчәк эше» [Нигмедзянов, 1984, с.14] дигән сүзләре әле бүген дә актуаль булып чыга.

Бүгенге көндә мөнәҗәтләрне һәм алар белән бәйле шигъри-музыкаль традицияләрне, формаларны, фәлсәфи һәм эстетик күзаллауларны тугандаш халыклар мәдәнияте белән бер яссылыкта өйрәнү һәм чагыштыру зарури. Бу эзләнүләр татар халкының традицион мәдәниятен ислам һәм төрки цивилизацияләрнең мөһим бер өлеше итеп күзаллауда, шул ук вакытта борынгы ядкярләребезнең тирән тамырларын ачыклауда тагын бер адым булачак. Татар җирлегендә үзенчәлекле бер жанр булып формалашып, күп гасырлар аша, сынаулар узып, үзгәрешләр кичереп, халык күңелендә серле вә илаһи җәүһәрләр булып сакланган мөнәҗәтләр соңгы елларда яңа бер сулыш алып яши башлады. Алдагы төрле аспектлардагы тикшеренүләр безгә мөнәҗәтләрнең бик күп серләрен ачарга, асылын аңларга һәм киләчәген күзалларга ярдәм итәр.

**Әдәбият**

*Бакиров М.Х.* Мунаджаты // Татарский фольклор: монография. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2018. С. 326–357.

*Исхакова-Вамба Р.А.* О некоторых связях народной музыки казанских татар с арабской культурой. // Музыкальная фольклористика. Вып.2. М.: Советский композитор, 1978. С. 298–314.

*Исхакова-Вамба Р.А.* Татарское народное музыкальное творчество (Традиционный фольклор). Казань: Татар. кн. изд-во, 1997. 264 с., с нотами.

*Каюмова* Э.Р. Истоки и эволюция музыкальной эпической традиции татар // Истоки и эволюция литератур и музыки тюркских народов: Материалы международной конференции. Казань, 2014. С. 288–291.

*Макаров Г.М.* Дәрвишләрнең сөхбәтендә: бәетләр һәм мөнәҗәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 159 б.: нота б-н.

*Макаров Г.М.* Музыка старотатарской письменной поэзии как составная часть средневековой элитарной культуры Волго-Камского региона // Музыка. Искусство, наука, практика. 2016. № 1 (13). С. 29–40.

*Мациевский И.В.*Сравнительное искусствознание – XXI век: К введению в проблематику // Сравнительное искусствознание – XXI век. Вып. 1. СПб., 2014. С. 6–24.

*Мөнәҗәтләр* / төз. А.Х. Садыйкова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 64 б.

*Мөхәммәтов И.Р.* Татар-төрек әдәби бәйләнешләре яссылыгында Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабы: филол. фән. канд. ... дис. Казан, 2006. 171 б.

*Нигмедзянов М.М.* Татарские народные песни. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 240 с.

*Садекова А.Х.* Идеология ислама и татарское народное творчество: автореф. дис. ... д-ра филол. наук : 10.01.09. Казань, 2001. 78 с.

*Сайфуллина Г.Р.* «Казан илләрендә Вәйсел-Карани» / Вайсел-Карани на казанской земле» // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2007. № 1. С. 197–202.

*Сайфуллина Г.Р.* Татарский мунаджат: трансформация жанра// Музыка народов мира. Проблемы изучения. Вып. 2. М., 2017. С. 219–234.

*Сайфуллина Г.Р.* Традиция книжного пения как источник по культуре «народного ислама» у волжских татар // Мир ислама. 2012. № 1–2 (8–9). С. 71–84.

*Сайфуллина Г.Р.* Актуально ли музыкальное востоковедение в Татарстане? Вопросы Нового времени // Наследие и современность: проблемы изучения, сохранения и преемственности традиций в искусстве и архитектуре. Шестые Валеевские чтения: сборник статей. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, Ресурсный центр внедрения инноваций и развития традиций в сфере культуры РТ, 2021. 252 с.

*Сайфуллина Г.Р.* «Мухаммадия» ЯзыджоглуЧелеби в культуре татар-мусульман // Наследие ислама в музеях России: изучение, атрибуция, интерпретация. Казань: Изд-во МОиН РТ, 2010. С. 154–164.

*Сибгатуллина А.Т.* Татар әдәбиятында суфичылык (чыганаклар, тематика һәм жанр үзенчәлекләре): Филол. фән. д-ры ... дис. Казан, 2000. 381 б.

*Софийская А.Б.* Влияние османо-турецкой литературы на традиционное музыкально-поэтическое творчество татар-мусульман // Музыка. Искусство, наука, практика. 2016. № 3. С. 33–42.

*Туймова Г.Р.* Религиозные музыкально-поэтические жанры в традиционной музыке крымских татар: мавлид и иляхи: автореф. дис. ... канд. искусствоведения. М., 2008. 22 с.

*Хөснуллин К.М.* Мөнәҗәтләр һәм бәетләр. Казан: Раннур, 2001. 724 б.

*Шарифуллина Н.М.* Мунажат как жанр в свете традиции книжного пения.// Вестник КАЗГУКИ. Казань, 2014. № 4, ч. 1. С. 50–52.

***Гыйлемҗанова Гөлназ Гыйльфан кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре*

УДК 784.671

***Г.Ф. Юнысова***

# ТАТАР БИШЕК ҖЫРЛАРЫНЫҢ ДИНИ ЭЧТӘЛЕГЕ

В статье внимание уделено некоторым особенностям вербального и музыкального текста в татарских колыбельных песнях в связи с воздействием на них мусульманских артефактов. Отдельные атрибуты исламской культуры рассматриваются в зачинах песен, пожеланиях ребенку. Особо отмечено символическое значение птиц в исламе и своеобразная интерпретация этого явления в мире детства. Основной раздел статьи посвящен анализу колыбельных песен, обращенных к пророку Мухаммеду его приемной матерью Халимой. Акцент сделан на интонационной стороне напевов. В научный оборот впервые введены и проанализированы новые полевые материалы, собранные автором работы. Намечен дальнейший путь исследования таких песен.

**Ключевые слова:** колыбельная пророку Мухаммеду; символика птиц; исламская культура; интонационный аспект колыбельных; фольклорные пожелания детям.

The article focuses on some features of the verbal and musical text in Tatar lullabies in connection with the impact of Muslim artifacts on them. Different attributes of Islamic culture are considered in the beginnings of songs, wishes to the child. The symbolic meaning of birds in Islam and the peculiar interpretation of this phenomenon in the world of childhood are especially noted. The main section of the article is devoted to the analysis of lullabies addressed to the Prophet Muhammad by his adoptive mother Halima. The emphasis is on the intonational side of the tunes. For the first time new field materials collected by the author of the work were introduced and analyzed into scientific circulation. A further way of studying such songs is outlined.

**Keywords:** lullaby to the prophet Mohammed; symbolism of birds; Islamic culture; intonation aspect of lullabies; folklore wishes for children.

Төрле төбәкләрдә, мәсәлән, Идел-Урал ареалында, яшәүче татарларның халык иҗаты үрнәкләрендә ислам мәдәниятенең аерым сыйфатларын очратырга мөмкин. Аларны хәтта балалар фольклорына караган иң гади әсәрләрдә, шул исәптән бишек җырларында да күреп була. Әмма алар еш кына, бигрәк тә балалар башкаруында, акрынлап югала бара. Хәзерге заманда халык җырчылары өчен фольклор үрнәгенең шундый эчтәлеге һәрвакыт аңлашылып та бетми, чөнки аны тәшкил иткән өлешләр гадиләшә һәм элек кабул ителгән стандартлар белән бәйле рәвештә саклана. Россия дәүләтенең совет чорында илаһият әдәбиятын, дин нигезләрен өйрәнүне тыю шушындый нәтиҗәгә китерде, чөнки хакимият атеистик тәрбия бирү юнәлешен сайлаган иде.

Бишек җырларының сүзләрендә чагылыш тапкан ислам дине артефактларының эчтәлеге дә, әсәрләрдәге күләме дә төрлечә. Аларның иң кыскалары – Аллаһы Тәгаләнең исемен, шулай ук дин тарихында киң танылу алган кешеләрне, аларның көрәштәшләрен искә алу.

Татар бишек җырларының бер күрсәткече – гадәттә, беренче куплетта урын алган *Аллаһу, аллаһу* дигән сүзләрдән торган юл. Башкаручылар (бигрәк тә балалар) аны, нигездә, үз мәгънәсендә, Аллаһка мөрәҗәгать буларак, кабул итмиләр, ә ниндидер рифмалашу дип саныйлар. Бу сүзләрдән соң бишек җырларының эчтәлегенә хас булган хайваннар дөньясы вәкиле тасвирлана [Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры, б. 26]:

*Аллаһу, аллаһу,*
*Кәҗәләрне талга ку.*

Кабатланып килүче «Аллаһу, аллаһу» сүзләре бу жанр әсәрләрендә үзенең әйдәп баручы урынын саклый (мөгаен аеруча киң таралган *әлли-бәлли* сүзләре белән аваздаш булу аркасында). Кайбер очракта лексеманың төре югарыда китерелгән икеюллыкныкы белән туры килә [Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры, б. 26]:

*Әллиһу – бәллиһу,*
*Кәҗәләрне талга ку.*

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: бишек җырларында чагыштырмача аз таралган тагын бер башламны очратырга мөмкин. Ул Коръәндәге «Фатиха» сүрәсенең беренче аятен акрын гына (үзең өчен генә) көйгә салмыйча кабатлаудан гыйбарәт: *Бисмилләәһиррахмәәнир-рахиим* (Рәхимле һәм шәфкатьле Аллаһ исеме белән). Бу бисмилла, билгеле булганча, шушындый ук бәет һәм мөнәҗәтләрнең дә башлам өлешләрендә очрый. Барлык күрсәтелгән жанр үрнәкләрендә дә (бишек җырларын да кертеп) аның вазифасы бер – Аллаһы Тәгаләнең фатихасын алу һәм рәхмәтенә ирешү. Фольклорчылар бишек җырларындагы бу башламны текстның төп өлеше дип түгел, ә өстәмә дип санап, аны бастырмаганнар да язып алганда да игътибарсыз калдырганнннар, дигән фикер туа.

Югарыда китерелгән икеюллыкта Аллаһы Тәгаләнең исеме кабатлана. Бу очракта, мөгаен, суфичылыкның кайбер үзенчәлекләре чагылыш тапкан. «Нәкышбәндия тарикатенең барлык яшь суфиларына зекер әйткәндә Аллаһ сүзен ике тапкыр кабатларга тәкъдим ителгән» [Тарикат Ясавийа и Крым, с. 188]. Шунысын да билгеләп үтик: татар фольклорында, аерым алганда, бишек җырларында Аллаһы Тәгаләнең тулы исеме *Аллаһу* да, кыска *Һу* рәвеше дә очрый:

*Һу-һу Аллаһу,*
*Кәҗәләрне тауга ку.*
*Кәҗә чәчәк ашасын,*
*Минем кызым йокласын.*

[Ямалтдинов, б. 207]

Аллаһ кошын белдергән «һу кошы» төшенчәсе дә бар. Кошлар тавышы (бигрәк тә сандугачның сайравы һәм күгәрченнең гөрләве) тыңлаучыларда Коръән уку белән бәйле хис-кичерешләр тудырган.

Мәсәлән, язучы З. Бәширинең мәдрәсәдә уку еллары турындагы истәлекләрендә түбәндәге юллар бар: «Имештер, бертуктаусыз «алла» диген, «пәйгамбәр», бертуктаусыз әллә нинди адәм аңламаслык телдә язылган «чипи-чыпаш, кәнәд шаhи!» дигән нәрсәләрне укы!.. Имештер, сандугачлар да, Алланы искә төшереп, әнә шундый сүзләрне сайрыйлар» [Бәшири, б. 119]. Төрле жанр фольклор әсәрләре (кыска җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр) текстларында күгәрчен турында искә алына. Ул йә Изге Коръән китабын «укый», йә *Ләә илләәhә иллааллаh* кәлимәсен кабатлый.

*Өй башында күгәрчен,*
*Укый Әлхәм сүрәсен...*

[Татар халык ижаты. Кыска жырлар, б. 49]

*Кызыл аяклы күгәрчен*
*«Лә иләhә иллаллаh» дип очадыр.*

[Мостафа мулла бәете, б. 551]

Тикшеренүчеләр билгеләп үткәнчә, «кош культы» ясәвия тарикате дини тәҗрибәсендә зур роль уйнаган, соңгысы, күрәсең, үзенә төрки шаманистик ритуаллардан күп нәрсәләр алган. Төрле максатларда шәех Әхмәд үз укучыларын кошларга (торналар, лачыннар h.б.) әверелдергән [Тарикат Ясавийа и Крым, с. 152].

Зурлар еш кына сабый баланың үзен, аның тәтелдәвен төрле кошлар hәм аларның сайрау hәм чәрелдәү тавышларына охшаталар. Баланың сабый чагын «бишек кошы» (Исәнбәт, б. 182) төшенчәсе белән билгелиләр. Бу гыйбарә, мәсәлән, түбәндәге табышмакта чагылыш тапкан, аның җавабы – *бишектәге бала:*

Югары менәр hу-hу...
Түбән төшәр hу-hу...
Уртасында былбыл кош,
Сайрыйдыр ла hу-hу.

[Бәдигый, б. 118]

Анда да шулай ук *hу* сүзе кулланылган: ул бишек аска-өскә хәрәкәт иткәндәге тавышны hәм баланы гәүдәләндергән сандугач сайравын белдерә.

Кайвакыт татар бишек җырлары текстына кертелгән шәхси исемнәр турыдан-туры балага аталмый. Шуларның кайберләре (әйтик, Фатыйма, Ибраhим) ислам тарихында билгеле затлар белән бәйләнгән. Мәсәлән, Фатыйма татар халык иҗатында (шул исәптән балалар фольклорында) персонажы буларак төрле сурәттә очрый. Барыннан да элек, әлбәттә, ул – Мөхәммәд пәйгамбәрнең кызы, hәм мөселманнарның зур хөрмәтен казанган зат. Әмма балалар уенкөлкесендә икенче бер Фатыймага – камкага да мөрәҗәгать итү бар. Риваять буенча, яшь кыз-кәләш явыз яучылардан качу өчен камкага әверелгән.

Бишек җырларындагы төп мотив – балага төрле теләкләр. Аларның кайберләре шулай ук ислам дөньясы белән бәйле. Мондый теләкләрнең өч төрен аерып күрсәтергә мөмкин. Беренчесендә Ходай Тәгаләнең балага хәер-фатиха бирүен көтәләр:

*Яратучы Ходайдан*
*Изге теләк теләдем.*

[Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры, б. 23]

Елаудан туктату, йоклату кебек гадәти булган теләкләрдә баланы фәрештәләрдән яклату турындагы үтенечне күрергә мөмкин:

*Еламасын, йокласын,*
*Фәрештәләр сакласын.*

[Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры, б. 23]

Бишек җырларындагы теләкләренең мөселман җәмгыяте белән бәйле өченче төре – үзенә күрә бер нәсыйхәт, юл теләкләре. Баланың киләчәк бәхетле тормышын планлаштырып, еш кына аның мәдрәсәдә (бигрәк тә Бохара шәһәрендә) яхшы белем алуы, ә кире кайткач, мулла булуы, ягъни халык арасында тирән ихтирам казанган кешегә әйләнүе күздә тотыла. Вакытлар узу белән бу теләк үзгәрешләр кичерә. Кайбер төшенчәләрне яңалары алыштыра: *мәдрәсә* сүзен – *мәктәп*, *Бохараны* – Казан, *мулланы* – галим (укытучы, гыйлемле кеше). Икенче яктан карасаң, бу теләк көчле үзгәреш тә кичермәгән, чөнки мулла элек ислам динен таратучы гына түгел, мөгаллим дә булган. Шул рәвешле, аны халык югары әхлаклы һәм белемле кеше буларак кабул иткән.

Бишек җырларында дин әһеле булып эшләргә хокук алу шартлары турында кайбер тарихи мәгълүматлар бар. Моның өчен Уфада урнашкан Диния нәзарәтенә барырга һәм тиешле рөхсәт (указ) алырга кирәк булган. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: кайчандыр илебездә җәелдерелгән дингә каршы муллаларның үз-үзләрен тотышын һәм тормышын тасвирлаганда сатира элементлары (зәһәр көлү) барлыкка килүдә үз ролен уйнады, бу кайбер бишек җырлары текстларында да чагылыш тапты.

Югарыда каралган барлык бишек җырлары текстында аерым сүзләр аша мөселман мәдәнияте белән бәйләнеш күзәтелә. Татарстан Республикасының Кама Тамагы районында язып алган үрнәкләрдә башкаручылар аларны бишек җырлары дип тәкъдим итсәләр дә, бу җырлар тулысынча ислам дөньясына мөнәсәбәтле. Информантлар раславынча, аларны Хәлимә – Мөхәммәд пәйгамбәрнең тәрбиягә алган әнисе җырлаган. Чөнки, шул чор гореф-гадәтләре буенча, аны сабый чагында күчмәләр гаиләсенә тәрбиягә биргән булганнар. Әлеге бишек җырында Хәлимәнең нәни Мөхәммәдкә мөнәсәбәте гадәти түгел. Ул аңа изге бала, Ходай Тәгаләнең сөекле сабые дип карый. Мөселман чыганакларында хәбәр ителгәнчә, үз әнисе Әминәгә дә, Хәлимәгә дә аның гадәттән тыш бала булуы турында алдан хәбәр ител-

гән була һәм алга таба да аларга әлеге югарылыкны раслаучы билгеләр җибәреп торганнар. Искә алынган бишек җырларының берсе тексты буенча ике бүлектән тора. Аларның беренчесе, салават әйткәндәге кебек, Мөхәммәд пәйгамбәргә мәдхияне һәм мәрхәбәне үз эченә ала:

*Әссәләтә вәссәләмә лә йәнәм*. (1 нче куплет)
*Раббе салли, Раббе халли*. (2 нче куплет)

Бишек җырларының икенче бүлегендәге фразаның үзгәрмәве аны кушымта дип атарга мөмкинлек бирә. Башкаручылар өчен ул, эчтәлеге буенча, йоклату кодыннан гыйбарәт. Әлеге фразаны алар *Алла илчесе, күзеңне йом*, дип тәрҗемә итте.




*Ком, ком,*
*Йа, хабибе, кәнтәнәм.*

*Информант: Айтуганова Өммегөлсем (1913 елгы),*
*ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы. 1981 ел.*
*Г.Ф. Юнысова язып алды һәм нотага төшерде*

Башкаручылар бу бишек җырының гарәп телендәге сүзләрен үзләренчә җырлыйлар. Бу күренешнең фонетик үзенчәлекләре автор тарафыннан нотага төшерелгән көйләрдә дә чагылыш тапкан. Башкаручыларның берсе бишек җырының Мәккәгә хаҗга барган әтисеннән ишеткән кушымтасын гына җырлаган. Үзенең дини белемнәрен әти кеше кызына тапшырырга тырышкан.

Татарстанның Кама Тамагы районында язып алынган ике бишек җыры да көй, өлешчә төзелеш ягыннан әлеге татар фольклоры жанрының гадәти үрнәкләре белән бәйләнгән. Шулай итеп, беренче информант югарыда китерелгән көйнең вариантын бер бишек җыры итеп башкарса да, ул татар фольклоры өчен гадәти текст.




*Бау, бау, бау итә,*
*Улым җокыга китә.*
*Улым җокыга китмәсә,*
*Аюлар алып китә.*
*Улым җокыга китмәсә,*
*Аюлар алып китә.*

*Информант: Айтуганова Өммегөлсем (1913 елгы),*
*ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы. 1981 ел.*
*Г.Ф. Юнысова язып алды һәм нотага төшерде*

Татарларның традицион бишек җырларында, кагыйдә буларак, көйнең еш кына йоклату сүзләренә туры килә торган төп өлеш була. Ул, кагыйдә буларак, җырның башында урнаша. Аның көе, югарыда китерелгән бишек җырыныкы кебек, бер терция интервалы чикләрендә ике авазны тибрәлдерүгә нигезләнгән булырга мөмкин. Әмма аның

ритмик яктан төрлечә оештырылган б.2↑– ч.4↓ музыка әйләнмәсе рәвешен дә алуы бар. Шундый рәвештә без аны Мөхәммәд пәйгамбәргә мөрәҗәгать итеп башкарылган тагын бер бишек җырында очратабыз (әлеге бишек җырының икенче куплетында этнофор, күрәсең, сүзләрнең бер өлешен төшереп калдырган):




*Информант: Ганиева Әминә (1912 елгы),*
*ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы. 1981 ел.*
*Г.Ф. Юнысова язып алды һәм нотага төшерде*

Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган бишек җырларының соңгырак чорларга караганнарында төрле бүлекләрдә татар һәм гарәп телләрендәге вербаль текстларның кушылмалары барлыкка килә (*Ком, ком* рефрены кулланыла). Шундый үрнәк 2018 елның җәендә Ульяновск өлкәсе авылларының берсендә фольклор экспедициясе вакытында язып алынды [Юнусова].

### Бишек җыры






*Кам, кам, йа Хабибе, әнтәм.*
*Кам, кам, йа Хабибе, йәнтәм.*

Такмаклап:

*Йокла, балам, йом күзең*
*Кадерлем һәм күз нурым.*
*Ир каршында ир булып*
*Матур булып үс, улым.*

*Информант: Гыйльманова Фәүзия Шәймәрдан кызы (1932 елгы), Ульяновск өлкәсе, Яңа Малыклы районы, Зирекле куак авылы. 2018 ел. Г.Ф. Юнысова язып алды һәм нотага төшерде*

Танылган фольклорчы Р. Исхакова-Вамбаның халык җырлары җыентыгында да шуңа ошаган үрнәк бар. Аны аудиоязманың П.И. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясе фоноархивында саклана торган басылып чыккан төп нөсхәсе белән генә чагыштырып ачыклый алганнар. Басмада җырның беркадәр үзгә вербаль тексты тәкъдим ителгән булып чыкты. Үзенең халык җырлары җыентыгына Р. Исхакова-Вамба дини тематика белән бәйле төрле фольклор үрнәкләреннән мисаллар кертмәгән. Алар арасында: «Мөхәммәдия» китабы көйләре, төрле мөнәҗәтләр. Күрәсең, XX гасырның 80 нче еллары башында мондый үрнәкләрне җыю һәм бастырып чыгару рөхсәт ителмәгән әле. Нәтиҗәдә Р. Исхакова-Вамба үзе теркәгән бишек җырларында кайбер юлларны үзгәрткән. Авазлар охшашлыгына нигезләнеп, музыка белгече *Ком, ком, я хабибе, кантәнәм* юлын *Кым, кым, елый бәби, көн-төнен* дип алыштырган:

*Кым, кым,*
*Елый бәби, көн-төнен.*
*Җир еламый, күк еламый,*
*Ник елыйсың син, балам?*

[Исхакова-Вамба, б. 81. № 66]

Ул әлеге бишек җыры текстына табигый рәвештә кереп утырды, чөнки аның өч куплеты да татар телендә. Алга таба җырның вербаль текстын «татарлаштыру» нәтиҗәсендә, әйтик, Пермь өлкәсендә язылган бишек җырындагы кебек үк, гарәп сүзләре тулысынча алыштырылып бетә:

*Елама, балам, елама, балам,*
*Сине бишеккә салам.*
*Җир еламый, күк еламый –*
*Ник елыйсың син, балам?*
[Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры, б. 25]

Шунысын әйтәсе килә: «Ник елыйсың?» дигән сорау татар халык иҗатында (аеруча борынгы әкиятләрдә) һәм профессиональ иҗат әсәрләрендә дә күп очрый. Шул ук фольклорда, мәсәлән, Г. Сәмитованың әлеге юлны үз эченә алган шигыре киң таралган:

*Идел буе яшел таш;*
*– Ник елыйсың, яшь туташ?*
*– Мин еламый, кем еласын –*
*Үзем ятим, үзем яшь.*
[Сәмитова, б. 28]

Р. Исхакова-Вамба татар халык җырлары җыентыгында үзе язып алган барлык үрнәкләрнең бары тик беренче куплетын гына нотага төшереп китерә. Күрәсең, ул заманда илебез фольклористикада шулай кабул ителгән булган (һәрхәлдә, Татарстан музыка белгечләре арасында). Татарстанның танылган этномузыкологы М. Нигъмәтҗанов хезмәтләрендә дә шундый ук хәл белән очрашабыз. Дөрес, кайбер үзгәрешләрне ул (Р. Исхакова-Вамба белән чагыштырсак) төп публикация астындагы аерым нота кисемтәләрендә вак шрифт белән биргән. Р. Исхакова-Вамба җыентыгыннан алынган бишек җырының аудиоязмасын тыңлаганнан соң, без аның куплетларының башкаручы тарафыннан төрлечә җырлануын ачыкладык. Шуның белән бәйле рәвештә Исхакова-Вамба Р. тәкъдим иткән җырның башлам бүлеге нотациясен һәм өченче куплетның үзебез эшләгән ноталарын китерәбез.




*Бишек җыры. 1 нче куплет // Исхакова-Вамба Р.А. Татарские народные песни. М.: Сов. композитор, 1981. № 66. Нотага төшерүче Р. Исхакова-Вамба*




*Бишек җыры. 3 нче куплет // Исхакова-Вамба Р.А. Татарские народные песни. М.: Сов. композитор, 1981. № 66. Нотага төшерүче Г.Ф. Юнысова*

Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган татар бишек җырлары язмаларының шулкадәр аз булуының төп сәбәбе, барыннан да элек, совет власте урнашканнан соң, татар җәмгыяте тормышында ислам диненең бетерелүе белән бәйле. Нәтиҗәдә, мондый бишек җырлары тупланмаган. Гәрчә мондый бишек җырларын табу ихтималы зур булмаса да (чөнки алар 1917 елгы революциягә кадәр туган информантлар репертуарында булган), аларны эзләү эшен дәвам итәргә кирәк. Табылган үрнәкләрне гарәп, фарсы һәм башка халыкларның бишек җырлары белән, шулай ук төрле төбәкләрдә, беренче чиратта Идел-Уралда, таралган мөнәҗәтләр һәм Мәүлид көйләре белән чагыштырып тикшерү эшен туктатырга ярамый.

**Әдәбият**

*Бәдигый Х.* Сайланма хезмәтләр. Казан: Иман, 2001. 256 б.

*Бәшири З.* Замандашларым белән очрашулар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968.

*Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге. Ике томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 495 б.

*Исхакова-Вамба Р.А.* Татарские народные песни. М.: Сов. композитор, 1981. 292 с.

Мостафа мулла бәете яки карта уйнап оттырылган Зөлхәбирә бәете // *Хөснуллин К.* Мөнәҗәтләр һәм бәетләр: көйләп укуга нигезләнгән жанрлар. Казан; Раннур, 2001. 551 б.

*Сәмитова Г.* Сайланма әсәрләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 156 б.

Тарикат Ясавийа и Крым. Сулейман Бакыргани: дастаны и хикматы / Вступительный очерк, перевод и комментарии Л.В. Бахревского. М.: Государственный республиканский центр русского фольклора, 2015. 208 с.

Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 336 б.

Татар халык ижаты. Кыска жырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 392 б.

*Юнусова Г.* Фольклор татар Ульяновской области // Милли-мәдәни мирасыбыз: Ульяновск өлкәсе татарлары. 2 нче басма. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән). Казан, 2021. Б. 513–539.

*Ямалтдинов И.* Оренбург татарларының фольклоры. Халык иҗаты үрнәкләре // Милли-мәдәни мирасыбыз: Оренбург өлкәсе татарлары. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; унөченче китап). Казан, 2016. Б. 131–208.

***Юнысова Гүзәл Фәйзрахман кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге*
*фәнни хезмәткәре*

УДК 004.65

***Ә.Ф. Галимҗанов,***
***Р.Ә. Галимҗанов***

# ЗУР МӘГЪЛҮМАТ МАССИВЛАРЫН ЭШКӘРТКӘНДӘ КУЛЛАНЫЛУЧЫ НЕЙРОН ЧЕЛТӘРЛӘРЕ ТИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ЧИШҮ ЫСУЛЛАРЫ

Для моделирования нейронной сети с Residual архитектурой предложено дробно-интегральное уравнение со специальным дробным оператором. Предложенное уравнение решено прямым методом, получена оценка погрешностии приближенного решения к точному.

**Ключевые слова:** нейронные сети, residual архитектуры, дифференциальные уравнения, приближенные методы

To simulate a neural network with Residual architecture, a fractional-integral equation with a special fractional operator is proposed. The proposed equation is solved by a direct method, an estimate of the error and an approximate solution to the exact one is obtained.

**Keywords:** neural networks, residual architectures, differential equations, approximate methods.

**Residual архитектуралар.** Нейрочелтәр архитектуралар арасында residual элемтәләр механизмын файдаланучы архитектуралар популярлашты. Зур мәгълүмат массивларын анализлаганда андый архитектура мисалы булып ResNet тора. Бу архитектура сурәтләрне анализлаганда бик актив файдаланыла, ләкин аны теләсә нинди структуралы зур мәгълүмат массивларында, шул исәптән, мәсәлән, иске татар язуында закончалыклар эзләү һәм кластеризация өчен файдаланырга мөмкин.

ResNet ны кыскача калдык нейрон челтәре дип әйтергә була. Калдык нейрон челтәре ResNet ясалма нейрон челтәре булып тора, аның прототибы – баш мие кабыгындагы пирамидаль күзәнәкләр. Калдык нейрон челтәрләре кайбер катламнар аша үтү өчен тоташулар яисә ярлыкларны калдырып китүләре белән үзенчәлекле. ResNet ның гадәти модельләре ике яисә өч катламны калдырып китүләре белән аерыла, аларга шулай ук нәсызыкчалыклар һәм пакет нормализациясе кирә. Алар өчен өстәмә матрица файдаланылырга мөмкин, ул калдырып кителгән элемтәләр микъдарын билгеләү өчен кулланыла. Бу модельләр HighwayNets исеме белән билгеле. Берничә параллель калдырып китүләр булган модельләр DenseNets дип атала. Калдык нейрон челтәрләре белән нисбәтле рәвештә калдык булмаган нейрон челтәрен гади челтәр дип атарга мөмкин.

Калдырып кителүче элемтәләр өстәү сәбәпләре түбәндәгечә. Беренчедән, бу – югалучы градиентлар проблемасын булдырмау яисә деградация проблемасын (төгәллек туенучанлыгын) киметү зарурлыгы. Ә бусы исә күбесе бик якынча булган зур сандагы мәгълүмат өчен бик актуаль. Икенчедән, җитәрлек дәрәҗәдә тирән булган модельгә зур сандагы катламнар өстәү өйрәтүдә зуррак хаталарга китерә. Өйрәтү вакытында микъдарлар күтәрелүче катлам комачауларын өзү һәм элегрәк калдырып кителгән катламны көчәйтү өчен адаптацияләнәләр (ярашалар). Иң гади очракларда исә күрше катламны тоташтыру өчен микъдарлар гына яраша, өстәрәк катлам өчен микъдарлар анык ярашмый. Бу бары бер нәсызыкча катлам калдырып кителгәндә, яисә барлык арадаш катламнар сызыкча булганда оптималь. Башкача калдырып кителгән катлам микъдарларының анык матрицасын өйрәнү, ягъни өстәмә матрицаны файдалану мәгъкуль.

Калдырып китү шулай ук челтәр структурасын гадиләштерә, чөнки өйрәтүнең башлангыч стадияләрендә азрак сандагы катламнар файдаланыла. Шулай итеп, өйрәтү тизләнә, югалучы градиентлар тәэсире кими, чөнки таралу өчен азрак сандагы катламнар кулланыла. Ләкин соңрак челтәр объектлар пространствосын өйрәнү барышында катламнарны тергезә. Өйрәтү процессының ахырына, барлык катламнар җәелгәндә, ул коллекторга якынрак булып кала, шулай итеп, тизрәк өйрәнә. Калдык өлешләре булмаган нейрон челтәре күбрәк функцияләр пространствосын тикшерә, бу исә аны коллекторны калдырып китәргә мәҗбүр итүче комачауларга бирешүчән ясый һәм тергезү өчен өстәмә мәгълүмат таләп итә. ResNet архитектурасы авторлары тарафыннан билгеләп үтелгәнчә, тасвирланган катлам челтәргә элекке катламнардан информацияне җиңел «сакларга» мөмкинлек бирә. Шуңа күрә сыйфатны югалтмыйча челтәр тирәнлеген сизелерлек арттыруга ирешелде.

Калдык челтәрләр баш миен яхшырак модельли, чөнки кабык катламы нейроннары кереш мәгълүматны, арадаш катламнарны калдырып китеп, турыдан-туры беренче катламнан ала.

Тасвирланган элемтә механизмының математик моделен карыйк.

**Теорема** (Универсаль аппроксимация теоремасы, К. Hornik, 1991) Теләсә нинди өзлексез функция өчен для f(x) функциясен бирелгән төгәллек белән якынайтучы сызыкча чыгышлы a(x) нейрон челтәре бар.

Стандарт катлам керешенә челтәрнең баштагы t катламы эше нәтиҗәсен кабул итә дип фараз итик – бу күрсәтелешне $h_t$ дип тамгалыйк. Ул вакытта челтәр чыгышын болай билгеләп була [Kaiming He..., 2015]:

$$h_{t+1} = f(h_t, \theta_t),$$

биредә $f(h_t, \theta_t)$ дип ниндидер сызыкча үзгәртү тамгаланган, аны практикада тулы бәйләнешле конволюцион катламнар, аларның комбинациясе рәвешендә күрсәтергә мөмкин.

$f(h_t, \theta_t)$ үлчәме $h_t$ үлчәменә тәңгәл дип фаразлыйк. Ул вакытта residual элемтәле катлам дип мондый үзгәртү атала:

$$h_{t+1} = f(h_t, \theta_t) + h_t, \qquad (1)$$

Вектор очракта кушу элементлап башкарыла.

$h_t$ күрсәтелешен t дан функция кебек карыйк, ягъни $h_t = h(t)$. Ул вакытта, катлаулы булмаган үзгәртүләр башкарып, табабыз:

$$h(t+1) - h(t) = f(h(t), \theta_t).$$

$$\frac{h(t+1) - h(t)}{(t+1) - t} = f(h(t), \theta_t).$$

Табылган аңлатманы үзгәртик. $h(t)$ функциясен [a, b] кисемтәсендә өзлексез аргументтан өзлексез функция кебек карый һәм чыгарылмага күчик, ягъни мондый рәвешле язык

$$\frac{h(t + \Delta t) - h(t)}{\Delta t} = f(h(t), \theta_t),$$

Катламнар санын чиксезлеккә омтылдырып, табабыз:

$$\frac{dh(t)}{dt} = f(h(t), \theta_t) \qquad (2)$$

Модельләүнең сыгылмалырак ысулын карыйк. Бөтен тәртипле чыгарылмаларны гомимуләштерү буларак вакланма тәртипле чыгарылмалар кулланыла. Алар практикада, мәсәлән, нейтроннар таралуны модельләгәндә, биологиядә, оптикада киң кулланылыш таптылар. Ягъни, (2) тигезләмәсе урынына мондый модель тигезләмә тәкъдим ителә [Galfmyanov, Vorontsova, Gorskaya]

$$D^{(\alpha)}h(t) = f(h(t), \theta_t), \; h, f \in L_2[0,2\pi] \qquad (3)$$

Белгәнебезчә, сызыкча үзгәртү юлы белән һәр кисемтәне $[0,2\pi]$ кисемтәсенә китерергә һәм периодик дәвам итәргә мөмкин, ягъни (2) дә күрсәтелгән шартлар гомумилекне бозмый.

Биредә $D^{(\alpha)} = \frac{D_+^{(\alpha)} + D_-^{(\alpha)}}{2\cos\left(\frac{\alpha\pi}{2}\right)}$ симметрик операторы $D_\pm^{(\alpha)}$ вакланма дифференциаллау операторлары ярдәмендә билгеләнә. Алар исә [a,b] кисемтәсендә билгеләнгән $\varphi(t)$ функциясе өчен мондый формулалар ярдәмендә билгеләнәләр [3]:

$$\left(D_{a+}^{(\alpha)}\right)\varphi(t) = \frac{1}{\Gamma(1-\alpha)}\frac{d}{dt}\int_a^t \frac{\varphi(x)dx}{(t-x)^\alpha}, -\infty < t < \infty,$$

$$\left(D_{b-}^{(\alpha)}\right)\varphi(t) = \frac{1}{\Gamma(1-\alpha)}\frac{d}{dt}\int_t^b \frac{\varphi(x)dx}{(x-t)^\alpha}, -\infty < t < \infty,$$

болар Риман-Лиувилль сул һәм уң вакланма чыгарылмалары, $0 < \alpha < 1$, Г(х) – Эйлер гамма-функциясе. Табигый ки, вакланма чыгарылмаларны теләсә нинди $\alpha \geq 1$ өчен билгеләп була һәм барлык

нәтиҗәләр дөрес булыр иде, ләкин биредә без $0 < \alpha < 1$ очрагы белән чикләнәбез.

(3) тигезләмәсен якынча чишү методын төзегәндә без $D^{(\alpha)}$ ның симметрик һәм уңай билгеләнгән оператор булуын файдаланырбыз [Galfmyanov, Vorontsova, Gorskaya, 2015]. Моны исәпкә алып, скаляр тапкырчыгыш һәм норма кертәбез:

$$[h,v] = \left(D^{(\alpha)}h,v\right),[h] = \left(D^{(\alpha)}h,h\right)^{1/2}.$$

$D = L_2[0,2\pi]$ пространствосын кертелгән норма буенча тутырып энергетик пространство табабыз һәм аны $H_D$ дип тамгалыйбыз.

$\theta_t$ ны параметр кебек карап һәм башлангыз (3) тигезләмәсен ирекле $v \in H_D$ функциясенә тапкырлап, тигезләмә табабыз:

$$[h,v] = (f,v). \qquad (4)$$

Табылган (4) тигезләмәсен Бубнов-Галеркин методы белән чишәбез. Бу метод буенча $H_D$ энергетик пространствосында $\varphi_j, j = 1..N$ базис функцияләре системасы сайлана. Якынча чишелеш базис функцияләренең сызыкча комбинациясе рәвешендә эзләнә:

$$h_N = \sum_{j=1}^{N} c_j\varphi_j. \qquad (5)$$

Ә билгесез коэффициентлар $c_j, j = 1..N$ түбәндәге сызыкча алгебраик тигезләмәләр системасыннан табыла:

$$[h_N,\varphi_k] = (f,\varphi_k),\ k = 1..N \qquad (6)$$

Якынча чишелеш рәвешен һәм кертелгән һәм гадәти скаляр тапкырчыгышларның сызыкча булуын исәпкә алып, мондый сызыкча алгебраик тигезләмәләр системасын табабыз:

$$\sum_{j=1}^{N} c_j[\varphi_j,\varphi_k] = (f,\varphi_k),\ k = 1 \ldots N \qquad (7)$$

Тәкъдим ителгән метод җыела һәм аның өчен түбәндәге теорема үтәлә:

**Теорема**. (3) тигезләмәсе теләсә нинди уң як өчен бердәнбер чишелешкә ия һәм $L(u,v) = [u,v]$ формасы $H_D$ – билгеләнгән һәм $H_D$ – чикләнгән булсын, ягъни түбәндәге шартлар үтәлсен:

$L(u,u) \geq \gamma_0^2[u]^2, L(u,v) \leq \gamma_1^2[u][v], \gamma_0,\gamma_1 \equiv const$, моннан тыш последовательность подпространств $H_N - \varphi_j, j = 1..N$ функцияләренең сызыкча тышчасы булган аспространстволар эзлеклелеге $H_D$ да чикләмә тыгыз булсын.

Ул вакытта теләсә нинди чикле $N$ өчен (7) системасы бердәй чишелүчән һәм якынча чишелешләр $h_N$ төгәл чишелеш $h$ ка $N \to \infty$ булганда кертелгән энергетик пространство метрикасы буенча омтыла һәм

$$[h - h_N] \leq c\varepsilon(h,N),$$

биредә $\varepsilon(h,N)$ – N га бәйле функция (якынча чишелешнең төгәлсезлек бәясе), һәм ул мондый тигезсезлекне канәгатьләндерә:

$$\min_{c_j}\left\|D^{(\alpha)}\left(h-\sum_{j=1}^{N}c_j\varphi_j\right)\right\|\leq\varepsilon(h,N)\to 0.$$

Бу вакытта, билгеле, f функциясенең $\theta$ параметрларын оптимальләштерү мәсьәләсе дә туа. Аны [Kaiming He, 2015; Vaswani.., 2017; Chen.., 2018] чыганакларында китерелгән нәтиҗәләргә таянып башкарырга мөмкин.

**Әдәбият**

*Kaiming He and Xiangyu Zhang and Shaoqing Ren and Jian Sun*. (2015) Deep Residual Learning for Image Recognition. CoRR

*Galfmyanov A.F., Vorontsova V.L., Gorskaya T.Y.*. Approximate methods for the equations with fractional differential operator//Global Journal of Pure and Applied Mathematics. 2015. Vol. 11, Is. 6. P. 5133–5144.

*Самко С.Г., Килбас А.А., Маричев О.Н.* Интегралы и производные дробного порядка и некоторые их приложения. Минск: Наука и техника, 1987. 688 с.

*Vaswani A., Shazeer N., Parmar N., Uszkoreit J., Jones L., Gomez A.N., Kaiser L., Polosukhin I.* (2017). Attention Is All You Need. NIPS.

*Chen, Tian Qi and Rubanova, Yulia and Bettencourt, Jesse and Duvenaud, David K.* (2018). Neural Ordinary Differential Equations. Advances in Neural Information Processing Systems 31, 6571–6583 NIPS2018

***Галимҗанов Әнис Фоат улы,***
*ТР ФА Гамәли семиотика фәнни-тикшеренү институты фәнни хезмәткәре*

***Галимҗанов Ринат Әнис улы,***
*Казан дәүләт энергетика универститеты аспиранты*

УДК 792

*Гали Рәхим*

## АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫНДА ТАРИХИ ӘСӘРЛӘР

Гали Рахим – писатель, литературовед, критик – в истории татарской литературы занимает особое место. В ноябре этого года исполнилось 130 лет со дня его рождения. Его научные труды были опубликованы во многих газетах и журналах, сейчас они являются библиографической редкостью и мало кому известны. Предлагаемая критическая статья Г. Рахима посвящена постановке на сцене Татарского академического театра трагедии М. Заитова «Ханбика». Рецензия «Академия театрында тарихи әсәрләр» была опубликована 28 ноября 1928 года в газете «Кызыл Татарстан». Автор даёт характеристику постановке драмы, актёрскому исполнению. Без внимания рецензента не остается художественное оформление спектакля: костюмы и декорации.

**Ключевые слова:** Гали Рахим, театроведение, татарская периодическая печать, татарская литература, история татарского театра.

Gali Rakhim – writer, literary critic – occupies a special place in the history of Tatar literature. This November marks the 130th anniversary of his birth. His scientific works were published in many newspapers and magazines, now they are a bibliographic rarity and little known. The proposed critical article by G. Rakhim is devoted to the staging of M. Zaitov’s tragedy «Khanbika» on the stage of the Tatar Academic Theater. The review «Academy of theater and tarihi assarlar» was published on November 28, 1928 in the newspaper «Kyzyl Tatarstan». The author gives a description of the staging of the drama, acting performance. The artistic design of the performance does not remain without the attention of the reviewer: costumes and scenery.

**Key words:** Gali Rakhim, theater studies, Tatar periodicals, Tatar literature, history of the Tatar theater.

Кирәк революциягә хәтле, кирәк соң булсын, татар тарихының борынгырак дәверләреннән алынган тарихи пьесаларны татар сәхнәсе сирәк күрә. Мәсәлән, әсир төрек офицеры Хәйдәр бәй тарафыннан язылып, татарчага тәрҗемә кылынып, Февраль чорында Кариев тарафыннан куелган, һәрьяктан зәгыйфь «Шаһгали хан» пьесасын алмаганда[1], Казан ханлыгы дәверен җанландыручы тарихи әсәрләр татар театрында куелганы юк иде. Шуның өчен «Ханбикә» пьесасының Татар академия театры сәхнәсендә куелуы безнең сәхнә тарихында әһәмиятле бер вакыйга дип каралырга тиеш.

Зәетов иптәшнең «Ханбикә»сен[2] бу юлда беренче адым, беренче сынау дип карарга тиеш.

Тарихи драмаларның сәхнәдә гәүдәләндерелүе – сәнгать ягыннан бик җаваплы эш. Бигрәк тә, бер халыкның Академик театрында шул халыкның үз тормышыннан алынган әсәрләр куелса, бу хезмәт тагын да әһәмиятлерәк һәм җаваплырак бер мәсьәлә төсен ала. Мон-

дый пьесаларның язылышы авторлардан, аларның куелышы сәхнә эшчеләреннән бик зур хәзерлек, коры техника хәзерлеге генә түгел, гыйльми яктан хәзерлек сорыйлар.

Менә шуңар күрә дә, бу юлда безнең Академия театры тарафыннан ясалган бу беренче адым уңае белән, гомуми мәсьәләләр дә кузгатылып, матбугатта яктыртылып узуы тиешле һәм урынлы дип уйлана.

Бу әсәрнең һәм аның куелуының бу яктан безгә биргән сабаклары нидән гыйбарәт булды соң?

Иң элек тарихи пьеса язучы кеше тарихчы ук булмаса да, бер тарихчы кадәр, хәтта аннан артыграк та, үзенең алган тарихи чорын нечкәдән, тирәннән белергә, өйрәнергә тиеш. Бәлки автор бу турыда үз тарафыннан күп тырышлык куйгандыр. Шулай да, режиссёрның тырышуына карамастан, пьеса безне XVI гасыр Казанына алып кайтып, сәхнәдә күрсәтелгән нәрсәләрнең чынлап та тарихи яктан дөреслегенә ышандыра алмады. Тарих һәм сәнгать ягыннан без анда, урысча әйтсәк, убедительность* тапмадык.

Без, мәсәлән, урысның яхшы театрларында «Иван Грозныйның үлеме», «Царь Фёдор», «Борис Годунов»[3] шикелле урыс әдәбиятының классик тарихи драмаларын караганда, үзебезне бөтенләй шул эпоханың эченә кереп киткән итеп хис итәбез. Тарихи-иҗтимагый вакыйгаларның ачылышы шәхси интригалар йомгагының сүтелеше белән гармония ясап барганы шикелле, тормыш вак-төякләре, кием-салым детальләре дә, пьесадагы кешеләрнең сөйләшә торган телләре дә шул гармонияне бозмыйлар. Димәк, һәрьяктан дәвернең стиленең берлеге, бөтенлеге саклана. Стильдә берлек исә – һәрбер сәнгать әсәрен гәүдәләндерүдә иң беренче шарт. Шул булмаганда әсәр безгә тиешле тәэсирен бирә алмый; хәтта аның тәэсире нольгә әверелеп калырга да мөмкин.

Көенечкә каршы, «Ханбикә»дә менә шул стиль бөтенлеге юк. Әсәрнең тарих һәм сәнгатьчә яхшы һәм көчле эшләнмәве, әлбәттә, моңар бик күп зарар итә. Иң элек әсәрнең мәүзугы [темасы, сюжеты] ягына кыскача кагылып үтәргә кирәк. Автор әсәрен «тарихи легенда» дип атаган булса да, дөресендә ул легенда түгел, чын тарихи вакыйгаларны җанландыручы пьеса да түгел, ике арадарак бер әйбер булып чыккан. Ләкин аның тарихилык ягы, шиксез, баса төшә. Әгәр фантазия ягына тагы да азрак әһәмият бирелеп, сюжеты тарихка якынлаштырылса, әсәр, һичшиксез, уңышлырак чыккан булыр иде. Татар тарихын аз гына белгән кешеләрне пьесадагы кайбер юрамалар, тарихтан ераклашулар гаҗәпләндерә. Мәсәлән, әсәрнең героинясы Сөембикә булгач, ник аның фавориты тарихи «Кошчак углан»[4] түгел, ни өчен нindidер билгесез «Кулач» дип уйлыйсың. Тарихтан мәгълүм булган кадәр реаль тарихи шәхесләр кертелсә, әсәр моннан ни зарар итәр иде икән? Аннан соң әсәрдә эпоха өчен характерлы булган хаким сыйныф арасындагы партия көрәшләре, Кырым һәм

* Сүз кириллицада бирелгән.

Мәскәү ориентациясенең сәяси власть юлындагы тартышлары һич диярлек күренми; Сөембикәнең хатын була торып, власть башында торуының сәбәпләре, ике каршы партиянең сәяси уеннары арасында кысылып калуы, шунда лавировать итүе күрсәтелми, бөтен әсәр буенча шәхси гыйшык-сөю моментлары иң алгы планга бәреп чыгалар да, аның иҗтимагый әһәмиятен төшерәләр. Бу дәвердә бик әһәмиятле булган Мәскәү тәэсире Казан тормышының үз эчендә сизелми. Ул әллә кая еракта. Вакыйгаларга урыс тәэсире бөтенләе белән, сәяси вазгыяте һәм сарайдагы роле ачык мәгълүм булмаган, бутафорский «шомчы» Василийга кайтып кала. Ул, XVII йөзнең Мәскәү стрелецлары формасына охшаган киемгә киендерелгән дә, анда да, монда да ялт итеп килеп чыга. Нәкъ «Таһир-Зөһрә»дәге кара гарәп шикелле, бөтен гыйшык интригаларына катыша, әмма сәяси яктан бертөрле дә роле юк.

Әсәрнең тел ягына килсәк, ул баштанаяк хәзерге әдәби татар теле белән язылган. Пьесадагы кешеләрнең сөйләшүләрендә тарихилыкка һич әһәмият бирелмәгән. Алар һәммәсе «мәсьәлә, тәшәккер итәм» дигән шикелле сүзләрне катыштырып, XX гасырның әдәби телендә сөйлиләр. Татар теленә соңгы гасырларда гына кергән «крестьян» сүзе, хәтта урыс теленә дә XVIII йөздә генә кергән «солдат» сүзе, XVI гасыр татарлары авызыннан әйттерелүе бигрәк кызык синхронизм тәэсире бирә. Шуның өстенә тагы аерым кешеләрнең сөйләүләрендә дә индивидуаль аермалар күренми. Менә телнең шулай булуы әсәрнең тарихи колоритын, тормышлылыгын, самимилеген югалталар. Чынлап та, аңлап караган караучыга борынгы Казан декорацияләре эчендә борынгы киемнәр кигән кешеләрнең хәзерге китап теле белән сөйләүләре бик гаҗәп тоела. Бу – тарихи пьесаның бөтен стилен боза торган нәрсә.

Дөрес, моннан 400 ел элек татарың сөйләшү теле ничек булганлыгын без белмибез; ул дәвердән безгә язма әсәрләр дә бик аз сакланып калган. Ләкин безгә бит ул заман теленең нәкъ үзен бирүнең хаҗәте дә юк. Хәзерге телдән беркадәр аермалы булган, хәзерге әдәби гыйбарәләрдән арчылып, бераз борынгылыклар (архаизмнар) кушылып стильләштерелгән телне бирә алсак, сәнгать әсәре өчен шул җитә. Моның өчен, әлбәттә, беркадәр гыйльми хәзерлек күрмичә булмый. XVI һәм XVII йөзләрдән калма язма әсәрләр җентекләп өйрәнелергә тиеш. Шулай ук иске керәшеннәрнең теле дикъкатькә алынырга кирәк; чөнки XVI гасырда чукындырылып, татарлардан аерылган иске керәшеннәрнең теле, мәсәлән, татарларның теленә булган һәртөрле тәэсирләрдән читтә калып, борынгы сафлыкны, борынгы формаларны, борынгы әйтешне (тәләффыз) яхшырак саклаган. Менә шул өйрәнүләргә таянып, XVI гасыр татар теленә азмы-күпме уңышлы рәвештә реставрация ясарга мөмкинлек булыр иде.

Кием-костюм турында да шул ук сүзләрне әйтергә туры килә. Драманың куелышыннан бу турыда режиссёрның нык тырышканлыгы һәм байтак эзләнүләр ясаганлыгы күренсә дә, аерым детальләрдә һаман да тарихи яктан кайбер уңышсызлыклар, анахронизмнар юк

түгел. Мәсәлән, XVI гасыр хатыны Сөембикәнең XIX йөзнең соңгы яртысында татар хатыннарының кунакка барганда киеп бара торган юка, чәчәкле асыл күлмәкләре белән камзулларын киеп уйнавы стильгә туры килми. Мәгълүм юка, чәчәкле «милли» асыл күлмәк безнең Казан хатыннарына XIX йөзнең соңгы яртысында хөкем сөргән урыс-Яурупа модаларына тәкълид [иярү] аркылы килеп кергән; шул заман модалары белән татар күлмәгенең тегелешен чагыштырып карау шуны күрсәтә. Камзул исә, безнең татар арасына XVIII йөздә, ул вакытта Яурупада һәм урысның югары катлауларында ирләр тарафыннан киелгән «камзул» аталган киемгә тәкълид аркасында кергән булырга тиеш; исеме дә, тегелеше дә шуны күрсәтеп тора.

Сөембикәне киендерүдә фантазия юлы беләнрәк бару уңышлырак булыр иде. Мәсәлән, аның икенче пәрдәдәге киеме шактый муаффәкыятьле [уңышлы] иде. Дөрес, без Казан ханлыгы дәверенең чын телен белә алмаганыбыз шикелле, ул дәвернең татар киемнәрен дә аерымачык күз алдына китерә алмыйбыз. Шулай булса да, XVI, XVII, XVIII йөзләрдә Казан ягына килгән Яурупа сәяхәтчеләренең китапларына теркәлеп калган татар рәсемнәрен (гравюраларны) өйрәнү аркасында, без дөреслеккә шактый якын булган борынгы татар киемнәрен төзи алыр идек (Казан музеендагы мәгълүм Сөембикә рәсемен, бу иске рәсемнәр белән чуалтырга ярамый, чөнки ул XIX йөзнең беренче яртысындагы татар киемнәренә карап ясалган).

Иске заман татар киемнәренә реставрация ясаганда, XVI, XVII йөзләрдә Мәскәү урысларының кигән киемнәрен өйрәнү дә бик файда итәр иде. Чөнки бу заманда урысның югары катлауларына татарның кием-салым модалары бик нык тәэсир итүе – мәгълүм нәрсә. Моны урыс тикшерүчеләре үзләре дә игътираф итәләр [әйтәләр, таныйлар]. Мәсәлән, «монамах бүреге» аталган чите мехлы урыс патшалары таҗының, өйдә киелгән такыяларның, байлар туннарының, сәхтиян [сафьян] читек һәм итекләрнең, шулай ук сугыш коралларының һәммәсенең татардан алынганлыгы билгеле.

Ул заман татар хатыннары өчен чапан бөркәнүнең дә характерлы булмаганын әйтеп китәргә кирәк. Чапан бөркәнү безгә Урта Азиянең иң көчле тәэсир иткән заманында, XIX йөзләрдә генә килеп таралган булырга тиеш. Борынгы татар хатыннары баш киеме өчен өрпәк [өчпочмаклы яулык] һәм тастар [кияүгә китәсе кызлар башларына сарып йөри торган озынча ак киндер яулык] кебек нәрсәләр характерлырак булыр иде. Чөнки болар, гомумән, күчмәле төркиләрдә бар; керәшеннәрдә тастар әле дә сакланган. Гади халыкның, бигрәк тә авыл халкының борынгы тарихи киемнәрен яңадан торгызу өчен, безгә тагын шул иске керәшеннәргә кайтырга туры килер. Чөнки аларда безнең хәзерге татар киемнәренә охшамаган оригинал хатын-кыз киемнәре сакланган. Бу киемнәрне алар аз үзгәреш белән XVI гасырдан ук саклап алып киләләр булырга кирәк. Һәрхәлдә, Казан ханлыгының гади халык киемен гәүдәләндергәндә, бер яктан

чуваш һәм күрше фин халыкларының, икенче яктан күчмәле төрек халыкларының киемнәрен күз алдында тотып комбинация ясарга кирәк. Мәсәлән, тәвәккәл бүрек [мех эчле, тышы чүпрәк, плюш яки постаудан тегелгән, гөмбәз сыман түбәле, колакчынсыз баш киеме] белән казаки, әлбәттә, ул заман киемнәре була алмас инде; алар урынында колакчын, колакчынга охшашлы киез эшләпә белән якасыз чикмән урынлырак булачак ...

Сарайдагы җарияләрнең дә, нәкъ солдатлар шикелле, һәммәсенең бертөсле киемгә киендерелүе, җитмәсә тагын ул киемнең балаклы ыштаннардан, кыска балет юбкаларыннан һәм декальтәле корсаждан гыйбарәт булуы караучыга кызыксыз тәэсир итүен дә әйтеп үтәргә кирәк. Монда реализм ачыктан-ачыкка балетка корбан ителгән.

Сүз эчендә Казан ханлыгының сәяси тормышында бик зур роль уйнаучы иң зур дин башлыгы булган «сәед»нең фигурасы турында да бер сүз әйтеп китәргә кирәк. Вәкарьле [горур] һәм мәһабәт булу урынына сәеднең кыяфәт һәм киеме безнең хәзерге авыл муллаларыннан аергысыз иде.

Декорацияләргә килгәндә, 1 нче пәрдәдәге сарай эчен яхшы ук уңышлы дияргә туры килә. 3 нче пәрдәдәге кала эче дә, гомумән алганда, яман түгел.

Декорацияләрнең иң уңышсызы Идел буе пәрдәсендә иде. Күз алдыбызда булган Иделне үзенә охшатыбрак бирү, әлбәттә, тырышканда художникның кулыннан килер иде. Шәт 400 елда Иделнең физиономиясе ул чаклы үзгәрмәгәндер. Аннан соң бу урынның нинди җир булуы да пьесаның барышыннан ачык аңлашылмады.

Инде артистларның уйнавына килсәк, бу – әлбәттә, тарихи пьесаның үзенә турыдан-туры аз кагыла торган мәсьәлә. Ләкин артистның дәверне яхшы белеп, аңлап, күз алдына китереп уйнавының да тарихи пьесаның формалашуы өчен әһәмияте зур булуы шиксез.

Безнең татар артистларының күбесендә нормаль табигый, реаль уен һәм сөйләү юк. Күбесенчә табигый, аһәңле сөйләү урынын бездә кирәксез пафос, декламация һәм көйләп сөйләү тота. Безнең иң карт уйнаучыларыбызның да бу бәладән котыла алганнары юк. Уйналган әсәр никадәр хәзерге тормыштан ераграк булса, бу хәл шулкадәр артыграк сизелә. Хәзерге заманның реаль пьесаларында чибәр генә дөрес тон ала алган артистлар хыялый, тарихи пьесаларда, Шәрык тормышыннан алынган әйберләрдә бөтенләй ялгыш, ялган, табигый булмаган тон алып, бик тиз пафослы декламациягә биреләләр. Бу, әлбәттә, бездә электән театрның үз башына гына тәрәккый итүеннән, артистларны тәрбия итүче бер мәктәпнең булмавыннан, безнең иске кадр уенчыларыбызның яхшы сәхнә мәктәбе дә күрмәгән булуларыннан килә. Бу хәлгә бераз ярдәм итү өчен Академик театр артистларыбызны планлы рәвештә, Мәскәүнең Академик театрларындагы уйнавышының куелышы белән таныштыру өчен, Үзәк вакытлы гыйльми командировкаларга җибәрү файдалы булыр иде.

**Искәрмәләр**

1. Сүз төрек офицеры Гали Хәйдәр тарафыннан иҗат ителгән «Шаһгали хан» исемле дүрт пәрдәле трагедия хакында бара. Әсәр «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан 1918 елның 4 маенда (иске хисап белән) «Большой театр» сәхнәсендә уйналган. Сәхнәдә Шаһгали ролен Г. Кариев, Сөембикә ролен Фатыйма Ильская башкарган. (Бу хакта 1918 елгы «Кояш» газетасының 15 май (№ 1235) санында белдерү урнаштырылган.)

2. Мирза Зәетовның «Ханбикә» исемле тарихи легендасы 1928 елда сәхнәләштерелә. Беренче мәртәбә 1928 елда театр техникумының бишьеллык юбилее уңаеннан, техникум тәмамлаучы укучыларның имтихан спектакле буларак куела. Шул ук елда Татар академия театрының 3 нче премьерасы булып сәхнәгә менә. Әсәргә музыканы Салих Сәйдәшев яза. (Бу хакта тулырак мәгълүматны Л.Ш. Гарипова һәм Ф.Х. Миңнуллинаның «Ханбикә – сәхнәдә: беренче тәҗрибәләр, ялгышлар, уңышлар...» (Фәнни Татарстан. 2020. № 4) мәкаләсеннән табарга мөмкин).

3. Монда рус язучысы, шагыйрь, драматург, тәрҗемәче Алексей Константинович Толстойның (1817–1875) XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башы Россия тарихында булган вакыйгаларны сурәтләгән «Смерть Иоанна Грозного» (1865), «Царь Фёдор Иоаннович» (1868) һәм «Царь Борис» (1870) тарихи трилогиясе күздә тотыла.

4. Кошчак углан (? –1551) – 1546–1551 елларда Сафагәрәй хан, Сөембикә ханбикә чорында хөкүмәтне җитәкләгән шәхес. Мәскәү тарафдарларына каршы көрәшә. Шаһгали хан вакытында Казан ханлыгыннан кача, русларга әсирлеккә эләгә. Христианлык кабул итүдән баш тарткач, җәзалап үтерелә.

*Басмага әзерләде:*
***Хөснетдинова Гөлназ Азат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 75.03

***Н.Ю. Әлмиева***

## ҖЫРЧЫ РӘССАМ БАКЫЙ УРМАНЧЕ

Статья посвящена одной грани многогранного таланта выдающегося татарского художника Баки Урманче – его музыкальной одаренности. Судя по отзывам современников, по аудио-записям, Баки Урманче имел природные данные настоящего народного певца с мощным мужественным голосом, харизмой и знанием татарской народной традиции.

В статье рассматриваются его вокальные и личностные данные, особенности его незаурядного вокального исполнительства.

**Ключевые слова:** Баки Урманче, талант певца, голос, личность.

The article is devoted to one facet of the multifaceted talent of the outstanding Tatar artist Baki Urmanche – his musical talent. Judging by the reviews of contemporaries, according to audio recordings, Baki Urmanche had the natural characteristics of a real folk singer with a powerful manly voice, charisma and knowledge of the Tatar folk tradition.

The article examines his vocal and personal data, the features of his outstanding vocal performance.

**Keywords:** Baki Urmanche, singer's talent, voice, personality.

РСФСРның халык рәссамы, ТАССРның халык рәссамы, Казакъстан ССРның атказанган рәссамы, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Бакый Идрис улы Урманче (1897–1990) – татар мәдәниятенең легендасы. Аның иҗади мирасы күләмле һәм күптөрле. XIX гасырда туып үскән, туксан өч яшенә җитеп дөнья куйган Бакый Урманче – XX гасыр Россия тарихының югары күтәрелү һәм түбән тәгәрәү чорларын кичергән татар сәнгати мәдәнияте манзарасында үзенең биографиясе белән ике гасырны, ике дәверне тоташтырган күренекле зыялыбыз. Традицион татар тормышында үскән һәм дини тәрбия алган, Европа төрендәге татар профессиональ сынлы сәнгатенә нигез салган Бакый Урманче – күпкырлы талантка ия гаҗәеп зур философ та. Урманче шәхесенең асылын безгә төшенәсе дә төшенәсе әле [Монасыпов, 2014]. Рәссам Б. Урманче татар мәдәнияте тарихында бүген дә нәкыш, скульптура һәм графика өлкәләрендә күренекле әсәрләр иҗат иткән Оста буларак кына түгел, ә музыкаль сәләткә, зур диапазонлы тавышка ия булган чын җырчы, татар моңын тирәнтен аңлаган һәм аңа мөкиббән киткән шәхес буларак та кызыксыну уята. XIX гасыр ахырында туган Б. Урманче шәхесе хезмәт белән көн күреп, бәйрәмнәрдә рәхәтләнеп күңел ачарга яраткан традицион татар авылы мохитендә формалаша. Ул авылның бөтен музыкаль атмосферасын – җырларын, бәетләрен, догаларын үзенә сеңдереп үсә.

Б. Урманче тавышы яздырылган магнитофон кассеталары миңа Флора ханым аша килеп иреште. Чөнки Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән вакытта (1984–1993) миңа аның белән якыннан аралашырга туры килде. Татар фольклоры турындагы әңгәмә корганда, без Бакый ага турында да бик күп сөйләшә идек. Аның күпкырлы таланты хакында зур хөрмәт белән, яратып һәм мавыктыргыч итеп сөйләгәндә, Флора Ваһап кызы Б. Урманченың шигырьләр дә язуын, күп кенә татар җырларын башкаруын, Коръән сүрәләрен дә белеп укуын һәм үзенең шуларны магнитофон тасмасына яздыруын әйтте. Шул вакытта ук Флора ханым минем белән Б. Урманче язган картиналарның репродукцияләре генә түгел, ә шигырьләре дә тәкъдим ителгән китап чыгару турындагы идеясе белән уртаклашты. Мин аңа Урманче җырлавын нотага төшерүне үз өстемә ала алуымны җиткердем: минем өчен XIX гасыр ахырында туган, традицион мәдәни мохиттә тәрбияләнгән кешенең җырлавын нотага төшерү кызыктыргыч, кызыклы һәм үзенчәлекле хезмәт иде! Менә шул рәвешле мин Бакый аганың оста җырчы булуы турында белдем дә инде. Аның талантының бу ягы якын дусларына – мәдәният әһелләренә, әлбәттә, билгеле була. Кунаклар килгәндә дә, үзе кунакка барганда да ул җырларга яраткан.


- 3 -
81. Ашкадар.
85. Ашкадар. бергән.
86. Ашкадар. бергән. 1988.
87. Сынчы Фәхри.
88. Сынчы Фәхри.
91. Казан сөлгесе.
94. „Сагыш" фильмында импровизация.
101. Сак-Сок.
102. Коръән.
103. Сынчы Фәхри.
107. Ашкадар.

Рәхимә Тарханова
Р. Тарханова
Р. Тарханова
Бакый Урманче
Б. Урманче
Ф. Кудашева
Ф. Кудашева

Аудиокассетадагы җырларның исемлеге

Аудиомонтаж ясалган компакт-кассеталарның, шулай ук андагы җырлар исемлегенең бер өлешен Флора Ваһап кызы миңа Санкт-Петербургка күченеп китәр алдыннан тапшырды, ә калганнарын кабат җибәрде, – шулай итеп, мин Бакый Урманче җырлавында кечкенә генә фонограмма архивына ия булдым. Исемлекнең күләменә һәм легендар рәссам башкаруында татар халык музыкасы жанрларының төрлелегенә сокłануымны бүген дә яшерә алмыйм. Анда озын көйләр дә, бәетләр дә, Коръән уку да, кардәш халыкларның җырлары да кергән. Алынган язмаларның сыйфаты бер үк дәрәҗәдә яхшы булмаса

да, аларның күбесен нотага төшерергә мөмкин иде. Флора ханымның үтенече буенча, мин бу эшне шактый тиз тоттым.

Аннары хат язышу чоры башланды. Миндә Флора Ваһап кызының изге теләкләр, дусларча соклану белән тулы берничә хаты саклана, һәм мин аңа барысы өчен дә чиксез рәхмәтле. Аның хатларының җылылыгы очраклы конвертлар сайламавында да чагыла: аларның тышында әле Сара Садыйкова, әле Бакый Урманче үзе сурәтләнгән.

Без рәхәтләнеп хезмәттәшлек иттек, безне Бакый Идрис улының җырлавына соклану берләштерде һәм көч бирде. Минем почта аша җибәргән ноталарымның бер өлешен (1996)[1] алганнан соң, ул шунда ук, шатланып, шагыйранә нәзакәтле итеп җавап хаты яза: «тирбәлгән ноталар»га карап, Урманче тавышын ишетүен, аларда рәссамның мәрмәрдән эшләнгән сыннары һәм үтә күренмәле нәкыше «чагылышын, яңгырашын»[2] тоюын бәян итә иде.

Флора ханым халык җырларын башкаруга һәм аларның хәзерге мәдәнияттәге язмышына һичкайчан битараф булмады. Ул үзе дә татар халык җырларын тыңлаганда туган хисләре белән уртаклашты: алар лаеклы яңгыраса, соклануын белдерде; халык җырларының чынчынлап, илһамланып башкарылуына яшьләрнең битарафлык күрсәтүен күреп көенде.

Үзенең хатларында ул әлеге китап турында да хыялланды: «Урманче җырларын аерым китап итеп бастырып чыгарсаң, яхшырак булыр иде, алар бик аз түгел бит». Бу юллар аның ихлас яратуы һәм кайгыртучанлыгы белән сугарылган.

Бакый Идрис улы һәм Флора Ваһап кызы бик үзенчәлекле, гармонияле гаилә һәм иҗат берлеге төзеделәр. Ул һәрвакыт өенә ашыкты, чөнки ире аны һәрчак өзелеп көтә иде. Флора ханымның даими кайгыртуы аркасында рәссам Бакый Урманче озын-озак яшәп кенә калмады, тугры татар хатынының тырышлыгы, шуңа өстәп, кыр тикшеренүләре алып барган фольклорчының һөнәри гадәте – информант (аның да ниндие әле!) белән аралашканда микрофонны тиз генә кабызып куя белүе – безгә Бакый аганың куәтле тормыш энергиясе белән

[1] Урманче җырларының 1996 елгы нота төшермәләре (156 битне кара) соңрак «Мир Баки Урманче» (Казань, 2005, с. 261–271) китабында басылган булып чыкты. (Кызганычка каршы, эчтәлек ягыннан менә дигән бу басмада нотага төшерүченең Н.Ю. Әлмиева икәнлеге күрсәтелмәгән. Китапның әзерләнүе һәм нәшер ителүе турында мин берничә елдан соң гына белдем.) Алар түбәндәгеләр: Коръәннән ике өзек, «Сәйфелмөлек дастаны» көе, «Сак-Сок бәете», «Имаметдин турында бәет», «Аючы Дәүлү бәете», «Нәүрүз көе», «Азаматов кантон», «Ашказар», «Ончы Фәхри көе», «Сүрша кыз» җырлары. Аларның аңлатмаларын, мөгаен, Ф.В. Әхмәтова-Урманче эшләгән. Ул китапта, кызганыч ки, ноталарны җыючы «Азаматов кантон» җырының битләр тәртибен бутаган: нота төшермәләренең өченче бите юк, җырның сүзләре дөрес язылмаган; метроном мәгълүматлары төшеп калган. «Ончы Фәхри көе» һәм «Сүрша кыз» җырларында ноталарның битләре буталган, метроном уртага күчкән, «Ончы Фәхри көе»нең соңгы нота юлы китапны басканда киселгән. Әлеге нота төшермәләре, минем төзәтүләрем белән, 2017 елда чыккан китапка кертелде. Шулай ук нота юлларын язу форматы да үзгәртелде.

[2] 157 биттә Ф. Әхмәтованың Н. Әлмиевага язган хатыннан өзекне кара.





Урманче җырларының нота төшермәләре. 1996 елда Н. Әлмиева тарафыннан эшләнгән.

сугарылган кыю баритонның сыгылмалы тембры һәм тирән татар моңы борылмаларын ювелир осталыкта башкаруы белән үзенә җәлеп итүче җырчы тавышын саклаган. Әлеге үзенчәлекләр Б. Урманченың барлык җырларына да (шул исәптән аның шактый өлкән яшьтә яздырылган язмаларына да) хас. Флора ханым Б. Урманченың сәнгати мирасы турында гына түгел, музыкаль, җыр мирасын да кайгыртып һәм теркәп, яраткан хатыны һәм фольклорчы буларак, үзенең тарихи миссиясен тулысынча үтәгән.

Бакый Урманче үзенең язмаларында фольклор традицияләренә тугрылыклы һәм аларны дәвам итүче чын җырчы буларак чыгыш ясый. Ул лирик һәм героик яңгырашка ия киң диапазонлы баритон тавышка ия булган. Еллар үткән саен, Урманченың тавышы үз көчен югалтмый, ә түбәнрәк регистрга да җәелеп, кайвакыт органга хас куе бас ноталарын бирә. Бакый Идрис улының тавышы табигый куелышлы, җырлау культурасы югары, артикуляциясе искиткеч. Урманче үзенең тормышын бары җырчы карьерасына гына багышлаган булса, һичшиксез, күренекле татар җырчысы булыр иде.

Күренекле рәссамның тууына 120 ел тулу уңаеннан бу юлларның авторы тарафыннан аның тавышы язмаларын (китапның CD кушымтасы бар) һәм җырларының нота төшермәләрен үз эченә алган китап әзерләнде [Альмеева, 2017][1]. Шунда ук беренче тапкыр татар,

[1] Кушымтада китапның һәм аудиодискның фоторәсемен кара.

башкорт һәм казакъ темаларына Урманченың гаҗәеп рәсемнәре урнаштырылды. Әлеге музыкаль җыентыкта татар һәм башкорт халыкларының *озын көйләре*, кыска җырлар (*кыска көйләр*), бәетләр, казакъ җырлары, Коръән сүрәләре бар.

Озын көйләр җырчы Бакый Урманче мирасының иң зур һәм кыйммәтле өлешен тәшкил итәләр. Озын көй – татар һәм башкорт фольклорында изгеләрдән изге, ул башкаручының яхшы тавышка ия булуын гына түгел, шәхес буларак җитлекккәнлеген дә таләп итә торган жанр. Интонацион яктан катлаулы, мелизмнарга бай озын көйләрне башкару – татар һәм башкорт ир-ат җырчыларының югары пилотажы, бу – зур тормыш тәҗрибәсе һәм рухи үсеш таләп итә торган катлаулы сәнгать, – кагыйдә буларак, матур яңгырашны да, батырлыкны да, үткәннәрне уйлап әрнүне дә үз эченә ала. Аутентик җырчы өчен озын көйнең музыкаль стихиясе – иҗат кыры. Һәм ул татар көйләренең таралу кануннарын тоемлау, татар моңына, мелизмнарына (алар иҗади инстинктка буйсына) ия булу аша гамәлгә ашырыла. Бакый Идрис улы Урманчега болар барысы да нәселдән бирелгән: музыкага табигый сәләт һәм традицион этник җыр мохите. Ул озын көйләрне (*«Урал су буе яшел камыш», «Ончы Фәхри көе», «Азаматов кантон»*), кайчагында өчәрөчәр катлаулы җәенке строфаларны гаҗәеп осталык белән башкара, үз тавышы белән шундый оста идарә итә, катлаулы борылмаларда һәм озын сузылышларда эчтән ирекле кеше буларак ачыла, җыры-тавышы белән кеше җанының тормышын сөйли һәм тасвирлап бирә, традицион текст талантлы итеп башкарылганда пәйда була торган икенче планны тудыра. Аның җыры – харизматик зат җырлавы ул, җырчы халык җәүһәренең куәтле энергетика тулы аурасын, бу җырлардагы рухи кичерешләр ташыган интонацияләрнең лирик яки героик пафосын яңадан торгыза. Флора Ваһап кызы раславынча, аеруча яратып башкарган *«Ончы Фәхри көе»н* җырлаганда, Бакый Урманче


Казань, 05.05.96.

Нинучкэем, радость моя, солнечный свет!
Как мне Вас тут не хватает! Какой светлый ум и прозрачная точность в описании многотрудностей жизни вашей, прекрасно мне знакомой. Но Ваша профессиональная передачность, талант, доведение до конца каждой детали – это ваше богатство, счастье. Как хорошо в совершенстве владеть своим искусством! Быть верным ему, любить его и уметь доводить его до других, совершенно далеких от этого искусства простых людей. Такое умение и радостное доведение его до других я встречала только у Урманче, значит, в [illegible] сотворчестве с ним, как пою его «Шурале», «Казан арты», «Су анасы» и прочая графика в сотворчестве с Тукаем, например. А сколько других вещей у него таких же прозрачных в мраморе, живописи, так же просматриваемых, звенящих, как в Ваших трепетных нотах.
Он так же знал цену себе, своим работам, как и Вы, и был так же скромен в оценке их. И мне представляются толстыми ханжами, дремучими неучами всякие Азгат Арслановы и другие, кем бы они не были, когда просят, нет, требуют себе потому, что кто был якобы другом, кто земляком и т.п., его музейные работы. Они не знают им цены, и если бы те работы попали к ним, они бы [illegible]. Недавно один переводчик перевел его стихотворение «[illegible]», посвященное мне, вроде

Ф. Әхмәтованың Н. Әлмиевага язган хатыннан өзек

үз тавышына үзе сокланган кебек. Күтәренке авазлар гүя әллә нинди матур төсләргә кереп җемелдиләр: бу язма Урманченың җырчы тавышы иң көчле вакытта эшләнгән.

Урманче тавышы рәхәтләнеп «коенган» иң зиннәтле көйләрнең берсе – татар җырчылары да бик яратып башкара торган башкорт халык җыры *«Азаматов кантон»*. Ул җырлаганда тавышны шундый итеп эшкәртә ки, без курай моңнарын ишеткәндәй булабыз: Эй!» дигәндәге көчле тавыш бөтен киңлекне тутырып сузыла, ә аннары югала, ишетелми башлый, әмма ул туктамый, табигать белән кушылып, япа-ялгыз калган башкаручының күңелен биләп ала. Аның тавышы кайвакыт органик яңгыраш ала, көйнең озак сузылышы һәм көчле тавыш сулышының баһадирларныкыдай киң булуын күрсәтә. Көчле киң тын-сулышка ия Урманче тавышы көйнең кояш югарылыгындагы биеклекләренә ирешә дә, строфа ахырында, кирәк икән, ярымкараңгы ай яктылыгына төшә. *«Калды ла-и-и-и-и-и-и-и»* сүзендә һәм алга таба һәр ярымстрофа азагында ул башкорт курайчылары кебек тамак белән җырлый башлый (*өзли*): мелострофа ахырында музыка уен коралының сузынкы тавышы җырчыныкы белән кушылып китә. Әйе, Бакый Урманчеда бераз гына булса да өзләүнең авыз камаштыргыч тембры яңгырый: музыкага үтә сәләтле кеше буларак, башкортларның әлеге башкару манерасын ул Мәскәүдәге сыйныфташларыннан үзләштерә, тасмадагы язмасында да ул дусларының бик тә җырларга ратуларын искә ала.

*«Мәдинәкәй»* лирик җырында Урманче гаҗәеп матур ирләр тавышы белән гүзәл хатын-кыз портретын ясый, аның күңелләрне әсир иткеч көе, сак кына *diminuendo*сы, йөрәктән чыккан җылы сүзләре – барысы бергә идеаль мәхәббәт образын тудыра.

Аның җырлавы көй-мелизмнарның нәфис «чигешен» хәтерләтә. Шундый сыгылмалылыкны флейтада уйнаучы музыкантлар гына тудыра алалар, кошлар гына шулай иркен сайрыйлар. Бакый Урманче




башкаруында бормалы көйләрнең эчке потенциалы бик зур: кайбер аерым авазлар эчендә дә бормалар бар! Әмма җырчы иҗатында барлык аваз орнаментлары шулкадәр серле һәм органик бер-берсенә үрелеп бара ки, туган телендә – татарча музыкаль фикерли алган кеше генә моңа сәләтле.

Халык җырлары нәкъ менә Урманче кебек музыкаль сәләткә ия затлар

тарафыннан буыннардан-буыннарга тапшырыла. Музыкальлек, табигый сәләт, көчле тавыш аларны традицион репертуарлы итә: авылларда мондый кешеләр һәрвакыт аерылып торалар.

Әлбәттә, Бакый Урманче татар һәм башкорт халыкларының чын осталык таләп иткән озын көйләрен башкарган. Әмма шунысы да бар: ул тормышының Алма-Ата чорында (1941–1956) отып алган казакъ җырларын да гомер буе онытмаган. «Сүрша кыз» җыры[1] – казакъ халык иҗатында акын тарафыннан думбырага кушылып башкарылган классик ир-ат лирикасының гүзәл үрнәге. Бу жанрга караган җырларны башкарганда юл башындагы сузынкы авазларда казакъларның «Э-й!» дип кычкырулары ирләр тавышының матурлыгын һәм куәтен генә күрсәтеп калмый, бәлки тетрәндергеч сүзләр аша гашыйклыкны чагылдыра. Мәшһүр җырны башкарганда, Урманче сузынкы авазларда, күңеле белән, думбыраның көчле тибешен дә ишетә кебек.

Татар, башкорт, казакълар фольклорындагы озын лирик җырларны (концерт рәвешендә дияргә мөмкин) Бакый Урманче үз табигатенә хас осталык белән башкарган. Өлкән яшьтә (тәкъдим ителгән аудиоязмаларның иң соңгылары туксанынчы яшендә яздырылган!) булуына карамастан, ул йомшак лирик тавышка һәм көчле энергетикага ия була. Болар рәссамның музыкаль талантын ачып сала. Татар җыр культурасы киңлегендә – тормыш-көнкүрештә дә, концертта да – Бакый Урманче кебек татар һәм башкорт халыкларының озын көйләрен (аларның асылы – моңлы көй сызыгын оста итеп ачып бирүдә, орнаменталь көй стихиясенә, сузынкы авазлар динамикасына ия булуда) якты да, дәртле дә итеп башкаручы түбән регистрдагы ирләр тавышы – сирәк күренеш.

Бакый Урманченың җыр мирасында озын көйләр белән янәшә гаять популяр авыл жанры – *урам көе* үрнәкләре дә бар, аларны яшьләр кичке уеннарда гармунга кушылып җырлаганнар, шулар белән егетләрне армиягә озатканнар. Бу җырларның катлаулы булмаган текстлары табигый рәвештә ирләрнең кичерешләр дөньясын тулыландыра.

Телдән телгә күчкән татар халык музыкасының бәет жанры һәрчак традицион татар тормышының бер өлешен тәшкил иткән. Бакый Урманченың аудиомирасында бәетләр музыкаль стиль һәм башкару үзенчәлекләре буенча төрлечә тәкъдим ителгән. Аеруча киң таралган каноник «Сак-Сок бәете» гел көйләп укылган. Урманче бабай каргалган балаларны кошка әверелдерү турындагы озын һәм моңсу хикәятне йомшак, ягымлы һәм тыныч тавыш белән, мавыктыргыч итеп балаларына һәм оныкларына сөйли кебек.

[1] Флора ханымның аудиоязмаларында һәм «Мир Баки Урманче» китабында бу җыр «Сары чәчле кыз» булып бара. Чынлыкта исә казакъ җыры «Сүрша кыз» дип атала. Аның авторы – күренекле казакъ халык-профессиональ җырчысы Жаяу Муса (1835–1929). Әлеге мәгълүматларга аныклык керткәне, шулай ук җырның төгәл казакъча текстын һәм тәрҗемәсен җибәргәне өчен казакъ этномузыкологы, сәнгать фәннәре кандидаты Динә Жусупбәк кызы Әмировага (Алма-Ата) тирән рәхмәтемне белдерәм.

Әмма тормыштагы фаҗигалы тарихларны сөйләгән бәетләр дә бар, бу аларны баллада белән якынайта. Бәеттә, гомумән, тәүбә итү, эч серeңне сөйләү (трагик яки лирик) мотивы салынган. Башкаручының сюжетны бәян иткәндәге хис-кичерешләре катлаулы лирик бормалар кертүне сорый, ә үзеннән – тавышны диафрагмага таянган тынга (опертое дыхание) куеп җырлау осталыгы таләп итә. Болар барысы да мишәр ирләр традициясенә хас. Бакый Урманче башкарган бәетләр арасында аерым торган *«Аючы Дәүлү бәете»* – шуларның берсе. Һәлак булган персонаж исеменнән сөйләнгән фаҗигалы үлем тарихын баритон тавышлы Урманче драматик буяуларга төреп, озын көй итеп башкара. Кечкенә аудиоархив тасмасындагы бердәнбер мелострофада бу балладаның җырлап хикәяләнәчәге һәм аның тыңлаучыларга ничек йогынты ясаячагы турында сөйләнә.

*«Нәүрүз көе»* – Иран һәм Урта Азия халыкларында язгы Нәүрүз бәйрәме көннәрендә, өйдән өйгә кереп, бүләк җыйганда башкарыла торган традицион җыр жанры. Нәүрүз көен җырлау татар мәдрәсәләре шәкертләре арасында традициягә әверелә. Урманче өчен бу – үз тормыш тәҗрибәсенең чагылышы. Мәдрәсә шәкерте буларак, ул үзе дә мәчет файдасына сәдака җыюда катнашкан. Бу шундый уникаль күренеш ки, Бакый Урманче Идел буе татарларыннан язып алырга мөмкин булмаган сирәк фольклор традициясен тапшыручы буларак чыгыш ясый (ә бу нәкъ менә фольклор традициясе: ул шигъри текстның мифологик билгеләрендә дә, көйнең музыкаль үзенчәлекләрендә дә чагылыш тапкан). Урманче (һәм, әлбәттә, Флора ханым) ярдәме белән, без мәдәният тарихы һәм музыка фәне өчен сирәк очрый торган календарь-йола көен саклый алдык, ул үзенең музыкаль параметрлары буенча Урта һәм Түбән Идел буе татар халык музыкасы традициясе контекстына туры килеп тора.

Традицион дини тәрбия һәм белем алган кеше буларак, Бакый Урманче Коръән сүрәләрен яттан укыган, һәм Флора Ваһап кызының сүзләренә караганда, бу аның көндәлек тормышының бер өлешен тәшкил иткән. Аудиодиска Коръән уку да аның шактый зур өлешен алып тора. Шунысы игътибарга лаек: Урманчеда дини текстларны укыганда еш күзәтелә торган төссез басынкылык юк. Анда аның шәхси үзенчәлеге алга чыга: ул догаларны эпик чәчән кебек укый. Шул ук вакытта аның үгет-нәсыйхәт бирү, юату интонацияләре Коръән укучының зирәк мөгаллим, кайгыртучан ата булуын ассызыклый.

Кассета тасмаларында ике дубльгә һәм берничә строфасы гына җырланган җырлар да бар, болар – һәрвакыт көйнең вариантлары. Урманче җырларның интонацияләрен аерым көйнең интонацион кырында һәм, гомумән, озын татар көе стихиясендә табигый рәвештә яшәүче чын халык җырчысы буларак үзгәртә.

Фондтагы Бакый Идрис улы Урманче җырлавында яздырылган язмаларны тыңлаганнан соң, безгә кырыс ирләр тормышының кайгы һәм шатлыклары турында сөйләүче тулы бер каһарман лирика дөньясы ачыла. Урманче җырлау өчен сайлап алган, аның тормышы һәм

иҗатының бер өлешенә әверелгән үрнәкләрдә кеше язмышлары турында аның сыннары белән ассоциацияләнгән тирән кичерешләр дә, нәкышен балкытып торган гүзәллек идеалына соклану да бар. Барлык озын көйләр, шулай ук озын көйләргә әверелгән бәетләр, Бакый Урманче өчен – җанның очыш киңлеге, әлеге җанның тормышын тасвирлау өчен җырчы-оста тавышының гаҗәеп матур буяулары белән язылган «тавыштан киндерләр». Әлеге буяулар кульминацион ачык сузыкларда – Шаляпинннныкы кебек куәтле бас, лирик югары авазларда – йомшак кына җемелдәү, серле түбән авазларда бәрхет «курай» тавышы рәвешен ала. Болар барысы да – гаҗәеп иҗат актлары: алар аның тыңлаучыга мөрәҗәгатендә дә, көчле кешенең үз эченә бикләнеп, ялгыз калуында да чагыла.

Бакый Урманченың тормыш юлы һәм иҗаты музыка белән тулы була, ул аның эшләренә үтеп керә. Ул дуслары җыелганда җырлый. Ул музыка тыңлап картиналар яза һәм иҗат иткәндә җырлый. Аның күпләрне дулкынланырга мәҗбүр иткән «Сагыш» скульптурасының якын дусты, күренекле татар композиторы Ренат Еникиевнең оркестр белән виолончель өчен элегиясендә чагылуы очраклы түгел. Ире иҗат иткән әсәрләрнең музыкальлеге турында Флора Әхмәтова сокланып яза: « Аның Тукай белән бергәләп язылган “Шүрәле”, “Казан арты”, “Су анасы” һәм башка графикалары ничек җырлап тора!»[1] Һәр игътибарлы кеше аның картина һәм скульптураларындагы әлеге музыканы ишетә.

Бакый Идрис улы Урманче җырлаган һәм Флора Ваһап кызы Әхмәтова яздырган гүзәл татар халык музыкасы үрнәкләре – үткәннән киләчәккә җибәрелгән, халыкның гүзәл һәм камил музыкаль иҗатында кодка салынган һәм безнең ата-бабаларыбыздан XXI гасыр яшәүче буыннарга легендар Бакый Урманченың күпкырлы һәм игелекле таланты аша тапшырылган юллама.

**Әдәбият**

*Альмеева Н.Ю.* Музыка жизни Баки Урманче (Бакый Урманче моңнары). К 120-летию художника. Со звуковым приложением. Казань: Заман. 2017. 96 с.: ил. + CD.

Духовный мир Баки Урманче. Казань, 2005. 303 с.

*Монасыпов Ш.Х.* Духовный мир Урманче (Художник, скульптор Баки Урманче) // *Монасыпов Ш.Х.* Портреты выдающихся деятелей искусства Татарстана (в духовно-научном освещении) / Казан. гос. консерватория. Казань, 2014. С. 8–66.

***Әлмиева Наилә Юныс кызы,***
*этномузыколог, сәнгать фәннәре кандидаты,*
*Россия сәнгать тарихы институтының (Санкт-Петербург)*
*фольклор секторы өлкән фәнни хезмәткәре,*
*Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе*

[1] 157 биттә хаттан өземтәне кара.

УДК 006.72

*Г.Р. Хөсәенова*

# ТЕЛ ГАЛИМЕ ҮЗБӘК БАЙЧУРА ТУПЛАНМАСЫНДА ШӘХЕС ҺӘМ ЧОР ЯЗМЫШЫ

В этой статье освещается биография и научная деятельность лингвиста Узбека Байчуры, внесшего неоценимый вклад в изучение языкознания. Автор многочисленных научных трудов по экспериментальной фонетике татарского языка, тюркологии, финно-угроведению, алтаистике. Основным источником при написании статьи послужили архивные материалы, хранящиеся в Национальной библиотеке Республики Татарстан – в фонде Узбека Байчуры. В этой коллекции, созданной в 1996 году, наряду с личными документами, письмами и научными трудами ученого, хранятся и воспоминания, касающиеся его семьи. Автор, отчасти, останавливается и на жизнеописаниях этих личностей, подчеркивая ценность их активной деятельности в начале XX века.

**Ключевые слова:** коллекция, архивные документы, тюркология, алтаистика, финно-угроведение, фонетика.

This article highlights the biography and scientific activity of the linguist Uzbek Baychura, who made an invaluable contribution to the study of linguistics. Author of numerous scientific works on experimental phonetics of tatar language, turkology, tinno-ugric studies, altaic studies. The main source for writing the article was archival materials stored in the National Library of the Republic of Tatarstan – the Uzbek Baichura foundation. This collection created in 1996, along with personal documents, letters and scientific works of the scientist also contains memories concerning his family. The author, in part, dwells on the biographies of these personalities, emphasizing the value of their active activity at the beginning of the XX century.

**Keywords:** collection, archival documents, turkology, altaic studies, finno-ugric studies, phonetics.

1997 елда Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә 527 китап һәм архив документларыннан торган Ү. Байчура фонды булдырылды. Аның хронологик чикләре 1879–1996 еллар аралыгын колачлый. Тупланманың нигезен тел гыйлеме, телләр тарихы, тюркология, фин-угор, алтаистика буенча фәнни хезмәтләр, XX гасыр башыннан алып 1990 елларга кадәр төрле телләрдәге сүзлекләр тәшкил итә. Документларның яртысы рус телендә, шулай да БДБ халыклары һәм төрек, фарсы, немец, инглиз телләрендә дөнья күргән сирәк басмалар да бар.

Фондның Ү. Байчура исеме белән аталып йөртелүе шартлы. Асылда, аны фәнни материаллардан тыш бер-берсенә гаилә җепләре белән бәйләнгән өч шәхеснең архив материаллары тәшкил итә. Болар – тел галиме Үзбәк Байчура үзе, аның әтисе һәм әнисе – талантлы татар журналисты Шәриф Хөсәен улы Байчура, татар хатын-кызлары арасында беренче акушер Әминә Вәлиулла кызы Алимбәк. Өчесе

өч өлкәдә хезмәт куйсалар да, бу гаиләне якты киләчәккә өмет белән карау, уртак омтылышлар берләштерә. Архив документлары белән танышу, аларны өйрәнү процессында укучыда ватан тарихын үзенчә күзаллау барлыкка килә.

Ү. Байчура коллекциясендә сакланган материалларны берничә зур төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1. Шәриф Байчураның тормыш юлы һәм эшчәнлеген яктырткан истәлекләр.

2. Үзбәк Байчураның тел гыйлеменә бәйле хезмәтләре.

3. Әминә Алимбәкның шәхси һәм медицина өлкәсенә караган материаллары.

4. Хатлар.

5. Байчуриннар гаиләсенә кагылышлы рәсми документлар.

Әлеге мәкалә нәкъ менә икенче төркем – Ү. Байчураның фондта сакланган тел гыйлеменә бәйле материалларын, ә аннан да элек, галимнең тормыш юлын һәм фәнни эшчәнлеген бәян итүгә нигезләнер.

Үзбәк Шәриф улы Байчура – татар теленең эксперименталь фонетикасы, төрки, фин-угор, алтай телләрен өйрәнү буенча язылган күпсанлы хезмәтләр авторы. Галимнең үзе сайлаган фәнни тармакта яхшы белгеч булуын аның фәнни мәкаләләре, илебез һәм чит ил галимнәренең кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренә карата язылган югары бәяләмәләре билгели.

Үзбәк Шәриф улы Байчура 1923 елның 6 гыйнварында Казан шәһәрендә талантлы, коммунистик идеяләр белән «янып» яшәгән танылган татар журналисты Шәриф Байчура һәм беренче татар хатын-кыз табибә Әминә Алимбәк гаиләсендә дөньяга килә. Галим, үзенең бер кыскача автобиографик очеркында: «Мин татар мәдәнияте, әдәбияты белән яхшы таныш булган туганнарым арасында үстем, шул сәбәпле, мәктәпкә кергәнче фәкать татар телендә генә сөйләшә белә идем», – дип яза [Автобиография, 795 Т]. Шулай да алга таба рус телендә сөйләшү ихтыяҗы туачагын истә тотып, Үзбәкне якыннары рус мәктәбенә укырга бирәләр.

Укуда зур уңышларга ирешеп килгән малайга тормышының башлангыч этабында ук шактый авырлыклар белән очрашырга туры килә. Әнисе Әминә Үзбәкне этисе тәрбиясендә калдырып, үзен тулысынча җәмәгать эшләренә багышлый, шул рәвешле гаилә таркала. Бүгенге күзлектән караганда, яшь ананың гаиләсен карьера үсеше юлында корбан итүе аңлашылып та бетми кебек. Шулай да әгәр XX гасыр башындагы вазгыятькә, яшьләрнең бу чордагы рухи кыйммәтләренә, максатларына күз салсаң, гаҗәпләнерлек тә түгел. Укуын тәмамлап, табиб дипломы алган Әминә 1935 елда СССР Сәламәтлек саклау халык комиссариаты тәкъдиме белән Согуд Гарәбстаны короле сараенда докторлык вазифасын үтәү өчен, ике елга килешү төзеп, шул илгә китә. Алимбәк бурычын тиешле югарылыкта үти, аннан бик канәгать булалар. Ләкин бер ел ярым эшләгәннән соң, табибә авырый башлый. 1937 елның җәендә аны Мәскәүгә кайтарып, Кремль больницасына

урнаштыралар. Биредә бер елдан артык дәваланганнан соң, 1938 елның сентябрь башында Кырымга, ЕвпаториядәгеСематко ял йортына җибәрәләр. Биредә хәле кинәт авыраеп китеп, ул шул елның 15 сентябрендә вафат була. Архив документлары арасында Алимбәкның отчет доклады, мактау грамоталары, аттестат, брошюралар, фоторәсемнәре саклана. Әминә Алимбәк читтә яшәсә дә, Байчуриннар гаиләсе белән һәрвакыт бәйләнештә була, моның шулай икәнлеген фондта Әминәнең Үзбәккә һәм Шәрифкә юллаган күпсанлы хатлары раслый.

Шәриф Байчураның да тормыш юлы шактый катлаулы була. Совет хакимияте урнаштыру, колхозлаштыру эшләрендә актив катнашуына карамастан, дәүләт тарафыннан «халык дошманы» булуда гаепләнеп, ике тапкыр партиядән чыгарыла. 1933 елда булган репрессиясенең сәбәбе – Татиздат җитәкчеләренең «намуссыз» гамәлләренә игътибарсызлык күрсәтүдә булса, икенчесе – Сталин сәясәтен тиешенчә хөрмәт итеп бетермәү белән аңлатыла.Ү. Байчура бу вакыйгаларны: «Әти кайда гына эшкә урнашып караса да, аннан куыла килде, шул рәвешле, ун ел дәвамында эшсез яшәде. Ачлыктан михнәт чиккән вакытта туганнарыбыз, бигрәк тә әтиемнең сеңлесе ярдәм итмәгән булса, без исән кала да алмаган булыр идек», – дип искә ала.

Байчура тупланмасында Шәриф Байчураның нәселе, туып үскән Ташкичү һәм Бәбки (хәзерге Татарстан Республикасының Буа районы) авыллары турында тарихи мәгълүматлар сакланган. Журналист язганча, татарлар (бигрәк тә дин әһелләре) татар телен генә түгел, рус телен дә яхшы белгәннәр. Татарлар һәм руслар бергә катышып яшәгән бу авылда һәрвакыт үзара хөрмәт өстенлек иткән, һәр ике халык та бер-берсенең йолаларына ихтирам белән караган. Бу материаллар укучыларга революциягә кадәрге татар һәм рус авылларының тормышын күзалларга мөмкинлек бирә.

Ш. Байчура материалларын берничә төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

1. Туган авыл һәм нәсел тарихы.
2. Татар әдәби теленә караган тәрҗемәләр һәм тәнкыйди хезмәтләр.
3. Революция, Гражданнар сугышы һәм колхозлашу темасына караган мәкаләләр.
4. XX гасыр башының танылган шәхесләре һәм революционерлары турында материаллар (И.В. Сталин, В.И. Ленин, М. Вахитов, Н. Тюрякулов, К. Хайруллин).
5. Ул чорның шагыйрьләре, язучылары, драматурглары, җәмәгать эшлекләре белән бәйле истәлекләр (Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Ф. Әмирхан һ.б.).

Янәдән галимнең тормыш юлына кайтыйк. Ачлык, яртылаш ятимлек михнәтен күреп үскән Үзбәк, 1940 елда мәктәпне тәмамамлап, университетка укырга керә. Кечкенәдән аң-белемгә омтылышы гаять көчле булган үсмер бер үк вакытта диярлек ике югары уку йортын – Казан хокук институтын (1942–1948) һәм Казан педагогика

институтының чит телләр факультетын (1945–1949) тәмамлый. Фән дөньясына омтылыш моның белән генә төгәлләнми – Ү. Байчура Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясе Тел белеме институтына аспирантурага укырга керә. Фәнни җитәкчесе итеп танылган галим Е.В. Севортян билгеләнә. Егет ике белгечлек буенча белем ала, беренчесе эсперименталь фонетика булса, икенчесе – тюркология фәне. Ә кандидатлык диссертациясен «Гласные татарского литературного языка в свете экспериментальных данных» дигән темага яза һәм 1966 елда уңышлы гына яклый.

1954–1959 елларда Казан университетында эшләү дәверендә Ү. Байчура ике дистәгә якын тел һәм диалектка караган эксперименталь фонетика материалларын җыя, татар, чуваш, башкорт, удмурт, тува телләре буенча тикшерүләр үткәрә. Галим башкарган экспериментларның нәтиҗәләре Уфа, Чабаксар, Ленинград, Будапешт, Таллин шәһәрләрендә фәнни мәкалә рәвешендә басылып чыга [Онер].

Тел гыйлеме өлкәсендә күп көч куеп килгән Ү. Байчура 1959 елда эштән җибәрелә. Озакламый галим СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында лексикография-терминология бүлегенә эшкә урнаша. Биредә эшләү дәверендә Байчура сүзлекләр әзерләү һәм редакцияләү белән шөгыльләнә, «Звуковой строй татарского языка в связи с некоторыми другими тюркскими и финноугорскими языками» темасына докторлык диссертациясен тәмамлый.

Галимнең төрки һәм фин-угор телләре фонетикасын өйрәнүгә нигезләнгән докторлык хезмәте фәнни тикшерену процессында шактый гына каршылыкларга очрый. Шуларның берсе – тәҗрибәләр үткәрү өчен Казандагы эксперименталь лабораториянең мөмкинлекләре чикләнгән булу. Фонетист тәҗрибәләрен Ленинград дәүләт университетының Эксперименталь фонетика лабораториясендә һәм Мәскәү дәүләт чит телләр педагогика институтында В.А. Артемов лабораториясендә башкара.

Коллекциядә Ү. Байчураның кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре, «Классификация звуков», «О словесном ударении в алтайских языках», «Инструментальные данные об ударении и интонации в алтайских языках», «К вопросу о фонетической структуре слова в алтайских языках», «О слоговой структуре слова в алтайских языках сравнительно с уральскими и индоевропейскими по статистическим и инструментальным данным», «Замечания по лексикографии и лексикологии татарских диалектов», «О принципах изучения диалектальной лексики» дип исемләнгән хезмәтләр, тәҗрибәләр вакытында ясалган ренгентограммалар, рәсми хатлар, илебез һәм чит ил галимнәре Б.А. Серебренников (Мәскәү), А.К. Боровков (СССР ФА, Ленинград), Е.В. Севортян (СССР ФА, Мәскәү); доктор С. Висоцкий (СССР ФА, Мәскәү), М.Ш. Ширалиев (Баку), Ш. Хаттори (Токио), Фокос Фукс (Будапешт), Богуслав Гала (Прага), П.А. Аристе (Таллин) тарафыннан язылган төрле телләрдәге бәяләмәләр урын алган.

1972 елда Ү. Байчура фәнни эшчәнлеген дөрес юнәлештә дәвам итү максатыннан Ленинградта күчеп китә һәм телләрне экспериментал ь методлар белән тикшерә. Аның бу чорда чыккан иң әһәмиятле хезмәтләре түбәндәгеләр: «Татар теленең кайбер фонетик үзенчәлекләре» [Байчура, 1963, б. 127–140], «Әдәби телебез һәм яңа лингвистик ысуллар» [Байчура, 1969, б. 145–151], «К вопросу о характере словесного ударения в чувашском языке» [Байчура, 1963, с. 41–57], «Инструментально-фонетические данные относительно интонации и словесного ударения в тюркских языках» [Байчура, 1967, s. 147–167], «Некоторые экспериментальные данные о мелодике речи и словесного ударения в уйгурском языке» [Байчура, 1971, с. 42–61].

Үзе эшләгән өлкәнең чын остасы яңа җирлектә дә сынатмый – галим Ленинградта тел белеме институтында эшләгән елларда 28 хезмәт яза. Аларда галимнең төп белгечлеге булган экспериментал ь фонетика методологиясеннән башлап, төрки телләрнең һәм башка алтай телләренең фонетик проблемалары, бу телләрдә терминологияне кору, һинд-европа һәм урал-алтай телләрендә килеш һәм басым проблемаларына бәйле темаларда эшләгәне күренә. Инглиз һәм немец телләрен яхшы белгән белгеч чит ил галимнәре белән элемтәдә тора, төрле гыйльми конференцияләргә чакырыла.

1967 елда Прагада узган Халыкара конференциягә барырга рөхсәт булмаса да, аның чыгышы басылып чыга [Байчура, 1967, s. 145–147]. 1969 елда алтайчылар тарфыннан уздырылган XII Халыкара конференциягә (PIAC) шулай ук аңа катнашырга рөхсәт итмиләр, фәкать мәкаләсе генә дөнья күрә [Байчура, 1974, s. 77–87].

Ү. Байчура 1971 елның 26 мартында эштән китәргә мәҗбүр була. Фәнни эшчәнлеге чит илләрнең һәм СССРның абруйлы галимнәре тарафыннан хупланса да, ул үзенә карата кылынган гаделсезлекләрне, аяк чалуларны этисенең халык дошманы булып исәпләнүенә бәйләп аңлата. Сәламәтлеккә туймаган, хезмәттәшләре белән чагыштырганда шактый авыр шартларда яшәгән галимнең язмаларында әйләнә-тирәдәгеләрдән ризасызлык, тәнкыйди караш сизелә.

Ленинградка күчеп килгәч, Ү. Байчураның Көнчыгыш телләре белгече Мөнирә Газыйм кызы Сәләхетдинова белән тормыш коруы мәгълүм. Бу факт галимнең автобиографиясендә чагылыш тапмый, шулай да Казанда яшәп калган этисе Шәриф белән язышкан хатларда ачык күренә. Мөнирә Сәләхетдинованың фәнни кулъязма материаллары Байчура фондында саклана.

Гомерен тел фәненең иң авыр тармакларында көч куюга багышлаган Ү. Байчура, күпсанлы гыйльми хезмәтләр авторы буларак, шактый абруйлы, алыштырмас белгеч буларак күз алдына килеп баса. Бу – дөрес күзаллау. Әмма аның фәнгә керткән өлеше тиешенчә бәяләнде дип әйтү дөреслеккә туры килмәс иде. Шулай да үз вакытында күп тапкырлар эштән куылуга дучар булып, авырлыклар белән еш очрашкан галимнең шәхси һәм фәнни материаллары (шул

исәптән гаиләсенең дә) Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фондларында саклану – аның өчен үзе бер дәрәҗә.

**Әдәбият**

Автобиография // Отдел рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан. Ед. хр. 795-Т.

*Байчура У.Ш.* К вопросу о характере словесного ударения в чувашском языке (по материалам кимографических записей) // Тюркологические исследования. М.-Л., 1963. С. 41–57.

*Байчура У.Ш.* О слоговой структуре слова в алтайских языках сравнительно с уральскими и индоевропейскими по статическим и инструментальным данным // Sprache, Geschichte und Kultur der Altaischen Völker. Protokolband der XII. Tagung der Permanent International Altaistic Conference 1969 in Berlin, Schriften zur Geschichte und Kultur des Alten Orients 5. Berlin, 1974. С. 77–87.

*Байчура У.Ш.* Инструментально-фонетические данные относительно интонации и словесного ударения в тюркских языках // Proceedings of the Sixth International Congress of Phonetic Sciences. Prague, 1967 (1970). S. 145–147.

*Байчура У.Ш.* Некоторые экспериментальные данные о мелодике речи и словесного ударения в уйгурском языке // Структура и история тюркских языков. М., 1971. С. 42–61.

*Байчура Ү.Ш.* Әдәби телебез һәм яңа лингвистик ысуллар // Казан утлары, 1969. № 1. Б. 145–151.

*Байчура Ү.Ш.* Татар теленең кайбер фонетик үзенчәлекләре // СССР Фәннәр Акад. Казан фил. Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәтләре. Икенче китап. Казан, 1963. Б. 127–140.

*Онер М.* Знаменитый тюрколог – алтаист Узбек Байчура [Электронный ресурс]. URL: https://kpfu.ru/philology-culture/zhurnal-39tatarica39/svezhij-nomer/znamenityj-tjurkolog-altaist-uzbek-bajchura-72370.html (дата обращения: 01.10.2022).

***Хөсәенова Гөлнирә Рәзиф кызы,***
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең II категорияле китапханәчесе*

## МЕТРИКА КЕНӘГӘЛӘРЕ НИ СӨЙЛИ?

Россия архивында туу, аерылу, үлү реестрларының бай коллекциясе бар. Бу документларны өйрәнү һәм транскрипцияләү җитди әзерлек һәм тырышлык сорый. Кызганыч, барлык реестрларны бастыру мөмкин эш түгел, чөнки бу зур чыганаклар җыелмасын әзерләү зур көч таләп итә. Соңгы елларда метрика китапларын чыганаклар буларак өйрәнү актив юнәлеш алды, аерым торак пунктларының рәсми кәгазьләре басылып та чыкты.

Г.Ч. Фәйзуллина һәм Э.Х. Кадированың Тубыл губернасының Тубыл өязе XIX гасыр һәм XX гасыр башы кульъязма метрика китапларын өйрәнүгә багышланган «Чебургинские мечетные книги Тобольской губернии XIX – начала XX веков» (Монография. 2-е изд., доп. Казань: Отечество, 2021. 200 с.) [Файзуллина, Кадирова, 2021], «Ашлыкские (Лайминские) мечетные книги Тобольской губернии XIX – начала XX веков» (Монография. Казань: Отечество, 2022. 213 с.) [Файзуллина, Кадирова, 2022] хезмәтләре дөнья күргән иде инде. Югарыда аталган галимнәр һәм Л.Х. Фәизова авторлыгында тагын «Комаровские мечетные книги Тобольской губернии XIX – начала XX веков» (Казань: Отечество, 2021. 335 с.) [Файзуллина, Кадирова, Фаизова, 2022] хезмәте киң җәмәгатьлеккә тәкъдим ителде. Әлеге китаплар галимнәр, төбәк тарихы белән кызыксынучылар, гади укучы тарафыннан җылы кабул ителде.

Себер татарларының сөйләм теле буенча үзенчәлекле күзәтүләр беренче башлап И. Гиганов, В. Радлов тарафыннан фәнгә кертелгән. Д. Тумашеваның көнчыгыш диалектны җентекле тикшеренүләре дә игътибарга лаек [Тумашева, 1961; 1977]. Соңгы елларда шулай ук лингвокультурологик юнәлештә күпсанлы мәкаләләр, монографияләр басылды [Алишина, 1994; Файзуллина, 2016; һ.б.]. Авторлар киң катлау укучыга тәкъдим иткән бу китаплардагы материаллар әлеге төбәктәге XIX – XX гасыр башына караган документлар телен күзалларга, өйрәнергә мөмкинлек бирә.

Китапларда урын алган материал өч төп өлешкә бүлеп бирелә. Беренче өлештә XIX – XX гасыр башында кулдан язылган чыганакларга тарихи һәм лингвистик анализ бирелсә, икенче өлештә 1) туу, никах, аерылышу һәм үлем турындагы таныклыкларның күчермәләре бирелә; 2) иске татар телендәге текстлар кириллицага күчерелә; 3) рус теленә тәрҗемә ителә. Өченче кисәктә әлеге юрталарга караган беренче китапта – Күкрәнде (Чебургинские юрты), Җунтаң (Кондандские юрты) һәм Ләцек (Тахтагульские юрты), икенче китапта – Әшле (Ашлыкские (Лайминские) юрты), өченче китапта – Комарау (Комаровские юрты) авыллары халкының аерым шәҗәрәләре тәкъдим ителә. Әлеге авылларның метрика китаплары беренче тапкыр тикшерү объекты буларак алына һәм басмага әзерләнә. Тикшеренү эшендә мәчет китапларында сакланган XIX – XX гасыр башына караган

мәгълүматлар урын алган. Һәр өч китапта югарыда саналган авыллар турында документлар бирелә. Авторлар архив материалларын беренче тапкыр фәнни әйләнешкә кертәләр. Тубыл өлкәсе мәчетләренең гарәп шрифтында кулдан язылган текстлары Тубыл, Төмән һәм Уфа шәһәрләре архивында сакланып, хәзергә кадәр бастырылмаган һәм тикшерелмәгән. Авторлар мәчет китапларындагы мәгълүматларны гарәп графикасыннан кириллицага күчергәннәр, материалларны рус теленә тәрҗемә иткәннәр.

Өйрәнелгән документларда XIX гасырның 30 нчы елларыннан XX гасыр башына кадәр булган хронологик кысаларда Күкрәнде, Әшле һәм Комарау авылларындагы татарларның туу, никах һәм талак, вафатлары турында мәгълүмат урын ала. Шуларга нигезләнеп, авторлар авыллардагы татар җәмгыятенең тормышы һәм үсеше, халыкның көнкүреше турында кызыклы гына мәкаләләр язып урнаштырганнар. Китаптагы материаллар Көнбатыш Себер авылларындагы татарларның көндәлек тормышы тарихын күзалларга, аларның демографик үзенчәлекләрен күрсәтергә һәм мөселман гаиләсенең тарихи күренешен торгызырга мөмкинлек бирәләр, һәм алар киләчәктә, авторлар күрсәтүенчә, себер татарларының кулдан язылган китапларының корпусын әзерләү, археографик, лингвотекстологик, лингвокультурологик аспектларда комплекслы тикшеренүләр үткәрү өчен кыйммәтле чыганак булып торалар. Икенчедән, туу, никах, аерылышу һәм үлем турындагы метрика мәгълүматлары шәҗәрәләр төзүдә файдаланылалар.

Метрика китаплары иске татар телендә гарәп графикасында язылган. Бу үзенчәлек аларны өйрәнүнең катлаулылыгын билгели. Шуңа күрә бу тарихи чыганакларны өйрәнүдә хәзерге тикшерүчеләрнең мөмкинлеге чикле. Тикшерергә мөмкин булган истәлекләрнең күпчелек өлеше XIX–XX гасыр башына карый. Мәсәлән, Күкрәнде кенәгәләре 1831–1862 елларда язылган. Әйтергә кирәк, бу кулъязмаларның тышкы сыйфаты саклау шартларына нык бәйле. 1863–1917 еллар исән калган кулъязмалар күләменең сизелерлек кимүе белән характерлана. Моннан тыш, 55 ел эчендә 17 ел турында мәгълүмат юк, ягъни 1863–1864, 1866–1869, 1874–1878, 1880, 1892, 1900, 1903, 1907, 1909 елларга караган язмалар юкка чыккан. Авторлар күрсәтүенчә, алар өйрәнгән документларның сакланышы канәгатьләнерлек. Таныклыкларны тутырган имам яки мәзиннәрнең кулъязмаларын тану белән бәйле кайбер кыенлыкларны исәпкә алмаганда, чыганакларны тулысынча укып чыгарга мөмкин.

Кагыйдә буларак, метрика китаплары туу, никах, аерылышу (талак) һәм үлем турындагы дүрт бүлектән тора. Китаптагы метрик язмалар да шул ук принцип буенча тупланган һәм аерым очракларда демографик статистиканы да үз эченә ала, ягъни хисап елында туучылар, үлүчеләр, өйләнешү һәм аерылышулар саны китерелә.

Китапларның беренче өлешендә Г.Ч. Фәйзуллина, Э.Х. Кадирова үзләре өйрәнгән метрикалардагы материаллар буенча үткәрелгән

тикшеренүләренең нәтиҗәләрен аерым мәкаләләр рәвешендә тәкъдим итәләр. Мәсәлән, әлеге документларда очраган кеше исемнәре, туганлык терминнары, авыру атамалары турындагы фәнни мәкаләләр укучыда зур кызыксыну уята. Авторлар эш кәгазьләре стиленең бер жанры булган метрика кенәгәләренең Күкрәнде, Әшле һәм Комарау юрталары текстларының шул чорда бу төр документларга куелган таләпләргә туры китереп төзелгәнлеген ассызыклый. Кулдан язылган метрика китапларының географиясе, графо-фонетикасы, лексик үзенчәлекләре аларны өйрәнүнең перспективалары киң булуын күрсәтә.

Китапның икенче бүлегендә укучыга мөһим һәм аз өйрәнелгән бу тарихи чыганаклар кириллицада бирелә: туу һәм үлү очраклары, резидентларның үлем сәбәпләре турында мәгълүмат теркәлә. Архив документларында себер татарларының төрле этник төркемнәре турында мәгълүматлар урын ала. Мәсәлән, *Әминә, Кыз углан, Фифральнең 9нчы йәүмендә, Атасы сартийә Рәхимкол, анасы Сәхибҗамал, Тобол губернасы, шул ук өйәз, Күкрәнде иләндә тугды. Хәбибә, Кыз углан, Мартның 10 нчы көне, Атасы йасаклы Сәфәрмәт, анасы Сөйәрбикә, Тобол губернасы, шул ук өйәз, Күкрәнде иләндә тугды*.

Китапка себер татарларында кулланылган рәсми эш документлары да кертелгән. Туу, вафат булу, никах, аерылу кәгазьләрен тутыруның аерым тәртибе, аерым стиле бар. Алардагы үзенчәлекләр себер татарларында кулланылган шул чор татар әдәби телен күзалларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, *Җөмлә мәһәре кырык сум улуб, әлхаль алдым егерме сумын. Бән Нәзирә Мусай кызы яза белмәдекем сәбәбле, язарга илтимас итдем Мөхәммәдгали Нийаз углындан. Нәзирә Мусай кызының илтимасы илә риза итдем. Бән Рузый Әбүбәкер углы кырык сум мәһәрдән янә дә зәуҗәм Нәзирә Мусай кызына вирәчәгем калды егерме сум. Яза белмәдекем өчен илтимас итдем Габделхаликъ Корбан углындан. Рузый Әбүбәкер углының илтимасы илә имза итдем. Бән Габделхаликъ Корбан углы. Йегерме биш диен пушлина бирдем Рузый Әбүбәкер углы. Ошбуның өчен имза итдем Габделхаликъ Корбан углы.*

Бу материаллар әле киләчәктә дә фәнни тикшеренүләр объекты була ала. Татар-мөселман исемнәрен анализлау һәм аңлатуга багышланган өйрәнүләр кызыклы булачак. Бу контекстта себер татарларының этник төркемнәренә исем бирү традициясен тасвирлау һәм анализлау (үлгән туганының, әбисенең, бабасының исемен бирү, балага бер компонентлы, ике компонентлы исемнәр бирү; әлеге компонентларның үзенчәлекләре), аларны Идел буендагы һәм башка территорияләрдәге татарларның шул форматтагы документлары белән чагыштырып, эчтәлекле нәтиҗәләр ясау мөмкинлеге бирә. Никахлар һәм аерылышулар турындагы язмаларда имамнар катлаулы төшенчәләрне кулланганнар. Алар еш кына хәзерге гади укучыга аңлашылмый. Рус теленә тәрҗемә ителгән өченче өлештә аларда кулланылган төшенчәләрнең мәгънәләре ачыла. Мәсәлән, *Кыз тарафыдин йизнәсе йасаклы Гыйбаш Илйас углы вәли вәкил булды вә кияү тарафыдин*

*бер тугма Габдулла Ниятбакый вәли вәкил булды вә кызның шаһидләре Аидмөхәммәд Мөэмин углы, Морат Уразмәт углы әлимза куйдым.* Аларда шулай ук үзенчәлекле лексик төркемнәрдән туганлык терминнары, авыру исемнәре, хокук лексикасы урын ала.

Китерелгән нәсел агачы үрнәкләре, фотокүчермәләр китапны тагын да баета, мәгълүматлырак итә.

«Чебургинские мечетные книги Тобольской губернии XIX – начала XX веков», «Ашлыкские (Лайминские) мечетные книги Тобольской губернии XIX – начала XX веков», «Комаровские мечетные книги Тобольской губернии XIX – начала XX веков» хезмәтләрендә җентекләп теркәлгән, системага салынган тирән материал урын ала. Алардагы мәгълүмат тарихчылар, тел галимнәре, төбәкне өйрәнүчеләр, укытучылар өчен генә түгел, гади укучы өчен дә файдалы һәм кызыклы. Бу китапның киләчәктә дәвамы булыр, себер татарларының башка төбәкләрендәге авылларның да мондый үрнәктәге басмалары дөнья күрер, ә бу хезмәтләр алар өчен ышанычлы чыганак булып хезмәт итәчәк.

**Әдәбият**

*Алишина Х.Ч.* Тоболо-иртышский диалект языка сибирских татар. Казань: Изд-во Казан. гос. пед. ин-та, 1994. 119 с.

*Тумашева Д.Г.* Көнбатыш Себер татарлары теле: грамматик очерк һәм сүзлек. Казан, 1961. 240 б.

*Тумашева Д.Г.* Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 294 с.

*Файзуллина Г.Ч.* Номинации человека в татарских народных говорах Тюменской области: Монография. Казань: Отечество, 2016. 285 с.

*Файзуллина Г.Ч., Кадирова Э.Х.* Чебургинские мечетные книги Тобольской губернии XIX – начала XX веков: Монография. 2-е изд., доп. Казань: Отечество, 2021. 200 с.

*Файзуллина Г.Ч., Кадирова Э.Х.* Ашлыкские (Лайминские) мечетные книги Тобольской губернии XIX – начала XX веков: Монография. Казань: Отечество, 2022. 213 с.

*Файзуллина Г.Ч., Кадирова Э.Х., Фаизова Л.Х.* Комаровские мечетные книги Тобольской губернии XIX – начала XX веков. Казань: Отечество, 2022. 335 с.

***Галиуллина Гөлшат Рәис кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*татар теле белеме кафедрасы мөдире*

**2022 елның 6 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Д 022.006.02 диссертацияләр яклау советында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гомуми лингвистика бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Мирхәев Рифат Фирдинат улы (фәнни консультанты – филология фәннәре докторы, профессор Йосыпов Феритс Йосыф улы) «XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында татар телен функциональ үстерүнең социаль табигате» дигән темага филология фәннәре докторы гыйльми дәрәҗәсенә диссертациясен (фәнни белгечлек 10.02.02 – Россия Федерациясе халыклары телләре (татар теле) уңышлы яклады. 2022 елның **13 октябрендә** шушы ук диссертация советында халык иҗаты бүлеге аспиранты Хөсәенова Гөлнирә Рәзиф кызы (фәнни җитәкчесе – филология фәннәре докторы, доцент, Институтның баш фәнни хезмәткәре Лилия Хатип кызы Мөхәммәтҗанова) «Татар романик дастанында фольклор һәм әдәбиятның үзара бәйләнеше» темасына кандидатлык диссертациясен шулай ук уңышлы яклады.

**2022 елның 3–8 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге хезмәткәрләре Балтач районында фәнни экспедициядә булды. 2022 елдагы соңгы экспедициянең максаты халык һөнәрчелеге һәм кәсепләре, декоратив-гамәли сәнгать торышы, йорт бизәүнең милли һәм җирле үзенчәлекләрен өйрәнү иде. «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында оештырылган әлеге экспедиция татарлар яши торган Субаш, Югары Кенә, Түбән Кенә, Татар иле, Карадуган, катнаш Чепья, Иске Чепья; удмуртлар яши торган Мельничная һәм Улисьял исемле мари авылларында узды. Сәнгать белеме үзәге мөдире, сәнгать фәннәре докторы Р.Р. Солтанова, фәнни хезмәткәр, сәнгать фәннәре кандидаты Н.В. Герасимова һәм фәнни хезмәткәр А.Ф. Борһанова составындагы галимнәр төркеме районның Туган якны өйрәнү музейлары (Чепья авылында – Халыклар дуслыгы музее, Карадуган авылында – Себер тракты тарихы, балалар бакчасы музейлары, райондагы мәктәпләр, мәдәният йортлары музейлары) коллекцияләрен, шулай ук «Ива мебель» фабрикасы эшләнмәләрен өйрәнде. Эш барышында шулай ук киң җәмәгатьчелек белән очрашулар узды, музейларның фәнни хезмәткәрләре, гамәли сәнгать осталары белән элемтәләр урнаштырылды.

**2022 елның 13–14 октябрендә** Казанда өч мәйданчыкта «Җәлил укулары – 2022» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе оештырылды. Чаралар Муса Җәлил музей-фатирында (Горький ур., 17), Татар әдәбияты тарихы музеенда (Островский ур., 15) һәм Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында (Татарстан ур., 2) уздырылды. Чарада Татар-

стан, Башкортстан, Мәскәү өлкәсе, Кырым, Кабарда-Балкар һәм Оренбург өлкәсе галимнәре катнашты. Конференция көннәрендә шагыйрьләрнең кульязма дәфтәрләре күргәзмәсе оештырылды, КФУның Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында һәм Муса Җәлил музей-фатирында фәнни секцияләр эшләде, Татар әдәбияты тарихы музеенда татар фронтовик язучылары турында түгәрәк өстәл узды. «Җәлил укулары – 2022» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясенең нәтиҗәсе буларак, фәнни-тикшеренү эшләре тупланган җыентык дөнья күрде.

**2022 елның 22 октябрендә** Түбән Камада Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Разил Вәлиевкә 75 яшь тулу уңаеннан әдәби кичә үткәрелде. Кичәдә Татарстанның танылган язучылары һәм артистлары чыгыш ясады. Алар арасында Ркаил Зәйдулла, Марсель Галиев, Рәдиф Гаташ, Вахит Имамов, Газинур Морат, Алмаз Хәмзин, Факил Сафин һ.б. бар иде.

**2022 елның 19–21 октябрендә** Н.П. Огарев исемендәге Мордва дәүләт университеты базасында «Идел буе этномәдәнияте: үткән, бүгенге, киләчәкнең мәдәни константалары» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Саранск, Архангельск, Йошкар-Ола, Казан, Самара, Ханты-Мансийск һәм Россиянең башка шәһәрләреннән килгән белгечләрне берләштергән әлеге конференция барышында галимнәр Идел буе халыкларының традицион мәдәниятләрен үстерү мәсьәләләре буенча фикер алыштылар. Чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать үзәге мөдире, сәнгать фәннәре докторы Р.Р. Солтанова катнашты, Таң Еникеев иҗаты мисалында татар этнографик төркемнәренең традицион мәдәниятен татар сәхнәсендә чагылдыру тәҗрибәсенә багышланган доклад белән чыгыш ясады.

**2022 елның 22 октябрендә** Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә узган гала-концертта Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» Халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсына нәтиҗә ясалды. Концертта бәйгенең лауреатларын һәм җиңүчеләрен бүләкләделәр. Конкурсның максаты – татар халык җырларын һәм татар композиторларының әсәрләрен пропагандалау, яшьләрнең игътибарын милли-мәдәни кыйммәтләргә җәлеп итү, талантлы яшь башкаручыларны ачыклау һәм ярдәм итү, аларның иҗади потенциалын үстерү. Конкурсның географиясе: Англия, Чехия, Польша, Черногория, Бельгия, Кытай, Финляндия, Украина, Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Россия. Конкурсны гамәлгә куючы – Татарстан Президенты каршындагы мәдәниятне үстерү фонды, Бөтендөнья татар конгрессы, «Салават» эстрада җыр театры. Конкурсны оештыручы – Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе.

**2022 елның 26 октябрендә** Чиләбе өлкәсенең Мияс шәһәрендә күренекле мәгърифәтче

Мифтахетдин Акмулланың иҗади мирасына багышланган II төбәкара конференция узды. «Акмулла укулары» дип аталган әлеге чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре дә катнашты. Татарстан галимнәре конференциянең пленар утырышында шагыйрьнең иҗаты (филология фәннәре кандидаты, ТӘһСИнең өлкән фәнни хезмәткәре Марсель Ибраһимов), аның XX гасыр әдәби процессына йогынтысы (филология фәннәре кандидаты, ТӘһСИнең өлкән фәнни хезмәткәре Ләйсән Надыршина) турында чыгыш ясадылар, конференциядә катнашучыларны М. Акмулланың иҗатын өйрәнү тарихы, аның тормышына һәм иҗатына багышланган яңа басмалар белән таныштырдылар (филология фәннәре докторы, ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты баш фәнни хезмәткәре Рамил Исламов). Чиләбе өлкәсенең Татар конгрессына Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының соңгы елларда чыккан басмалары бүләк ителде.

**2022 елның 26 октябрендә** Г. Тукайның Казандагы әдәби музее тарафыннан, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән берлектә, Филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Резеда Кадыйр кызы Ганиеваның тууына 90 ел тулу уңаеннан «Әдәбият фәне маягы» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә оештырылды. Чара Габдулла Тукай әдәби музеенда узды. Анда филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясе вице-президенты Д.Ф. Заһидуллина, филология фәннәре докторы, ТӘһСИнең әдәбият белеме бүлеге мөдире Ә.М. Закирҗанов, филология фәннәре кандидаты, милли мәгариф бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Д.М. Абдуллина, танылган әдәбият галиме, профессор З.З. Рәмиев, КФУ профессорлары Х.Й. Миңнегулов һәм Т.Н. Галиуллин, ТР Дәүләт Советы депутаты, Татарстанның халык артисты Р.Ч. Төхфәтуллин, әдәбият белгечләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары һ.б. катнашты. Чыгыш ясаучылар Р.К. Ганиева турында истәлекләре белән уртаклашты, галимәнең татар әдәбият фәнен үстерүгә керткән өлеше һәм аның дәвамчылары турында сөйләде, кичәдә шулай ук әдәбият белеменең перспективалары турында фикер алышынды.

**2022 елның 27 октябрендә** Оренбургның туган якны өйрәнүчеләр җәмгыяте оешуга бәйле рәвештә үткәрелгән конференция кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кайбер фәнни хезмәтләре тәкъдим ителде. Чара «Оренбург татар милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы тарафыннан оештырылган иде. Х. Ямашев исемендәге Оренбург өлкә китапханәсенә җыелган татар җәмәгатьчелеге, галимнәр, туган якны өйрәнүчеләр хөкеменә Институтның фәнни хезмәткәре Венер Усмановның «Татар Каргалысы эпиграфик һәйкәлләре»

һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең коллектив хезмәте булган «Милли-мәдәни мирасыбыз: Оренбург өлкәсе татарлары» (Казан, 2016. 360 б.) басмалары тәкъдим ителде. Алар турында ТӘһСИнең фәнни хезмәткәре Венер Усманов, филология фәннәре кандидаты, Институтның өлкән фәнни хезмәткәре Нуридә Насыйбуллина сөйләде, Х. Ямашев исемендәге Оренбург өлкә китапханәсенә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнгән һәм нәшер ителгән китапларны бүләк итеп тапшырды.

**2022 елның 1 ноябрендә** «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан 1–9 сыйныфлар өчен эшләнгән «Туган тел (татар теле)» фәне буенча яңа буын укыту-методик комплектларын мәктәпләрдә куллану рәсми рәвештә рөхсәт ителде. Дәүләт аккредитациясе булган башлангыч, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын тормышка ашырганда куллануга рөхсәт ителгән дәреслекләрнең федераль исемлеге һәм дәреслекләрне куллану сроклары Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының агымдагы елның 21 сентябрендәге 858 нче боерыгы белән расланды.

**2022 елның сентябрь-ноябрь айларында** Ш.З. Закиров исемендәге «Идел-йорт 2022» XXII төбәкара театр коллективлары конкурсы оештырылды. Бәйгедә Россия төбәкләреннән (Башкортстан, Чувашия, Пермь, Санкт-Петербург, Оренбург, Удмуртия, Ульяновск өлкәсе, Төмән, Самара, Түбән Новгород, Чиләбе) 15 театр коллективы катнашты. Шуларның уникесе финалга узды. Җиңүче коллективларның исемнәре 26 декабрь көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында узачак гала-концертта игълан ителде.

**2022 елның 1 ноябрендә** гомуми белем бирү өлкәсендә укыту-методик һәм фәнни басмаларны сертификацияләү органы белән Төбәкара инновацион технологияләр үзәге тарафыннан шушы елның 1 февраленнән 31 октябренә кадәр үткәрелгән иң яхшы дәреслек, уку әсбабы һәм монографиягә (РИНЦ индексациясе белән) IX Бөтенроссия инновацион иҗтимагый конкурсына йомгак ясалды. Әлеге конкурста «Югары уку йортлары һәм югары уку йортыннан соңгы белем бирү йортлары өчен иң яхшы дәреслек (уку әсбабы)» номинациясендә Татарстан галимнәренең «Татарстан Республикасында мелиоратив игенчелекне инновацион үстерүне фәнни тәэмин итү» хезмәте җиңү яулады. Әлеге фәнни хезмәт шулай ук «Җәмгыять тарафыннан танылган хезмәт» номинациясендә Бөтенроссия конкурсының җиңүчесе дип билгеләнде.

**2022 елның 3 ноябрендә** Казанның Яңа татар бистәсе

зиратында татар язучысы, тел галиме, тарихчы, фольклорчы Гали Мөхәммәтшакир улы Рәхим җирләнгән урынга мемориаль такта куелды. Чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе галимнәре, югары уку йортдары укытучылары, журналистлар һәм киң җәмәгатьчелек катнашты.

**2022 елның 10 ноябрендә** Г. Тукайның Казандагы әдәби музеенда галим һәм педагог Хуҗа Бәдигыйның тууына 135 ел тулуга багышланган «Тукайдан алган фатиха белән» кичәсе оештырылды. Чарада Х. Бәдигыйның тормыш юлы, фәнни һәм педагогик эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, Хуҗа Бәдигыйның Санкт-Петербург, Яшел Үзән, Казанда яшәүче туганнары чыгыш ясады. Институтның халык иҗаты бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Ильмир Ямалтдинов, Х. Бәдигыйның фольклористика өлкәсендәге эшчәнлеген анализлап, аның хезмәтләренең татар фольклористикасы тарихында тоткан урынын югары бәяләде. Х. Бәдигыйның лингвистика өлкәсендәге фәнни эшчәнлеге, татар тел белеменә керткән өлеше турында гомуми лингвистика бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Энҗе Кадыйрова сөйләде.

**2022 елның 14 ноябрендә** Россия Фәннәр академиясенең Урал бүлекчәсендә (Тубыл шәһәре)» күренекле этнограф, Себер татарлары тарихы буенча саллы хезмәтләр авторы, тарих фәннәре докторы Фоат Вәлиевнең туган көне уңаеннан багышланган «Вәлиев укулары» узды. Филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәгеТел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары Олег Хисамов, филология фәннәре докторы, халык иҗаты бүлегенең баш фәнни хезмәткәре Илсөяр Закирова, филология фәннәре кандидаты, лексикология һәм диалектология бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре Алинә Хөсәенова Тубыл шәһәрендә узган әлеге чарада катнашып кайтты. 14 ноябрьдә шушы чара кысаларында И.Г. Кадыйровның 2021 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан нәшер ителгән «Татар халкының туй җырлары. Себер ареалы» китабы да тәкъдим ителде, басманы эшләү үзенчәлекләре турында Илсөяр Закирова сөйләде. 15 ноябрьдә Төмән дәүләт университетының Д.И. Менделеев исемендәге Тубыл педагогия институты студентлары алдында Көнбатыш Себер территориясендә комплекслы фәнни экспедиция составында эшләгән галимнәр чыгыш ясап, фәнни эзләнүләренең нәтиҗәләре белән таныштырдылар. Филология фәннәре кандидаты, ТӘһСИнең фән буенча директор урынбасары Олег Хисамовның бу чарадагы чыгышы Көнбатыш Себернең төрки-татар топонимик системасына багышланган иде; филология фәннәре кандидаты, институтның өлкән фәнни хезмәткәре Алинә Хөсәенова «Милли-мәдәни мирас: Себергә фәнни экспедицияләр эзләре буенча» дигән темага чыгыш ясады.

**2022 елның 14–19 ноябрендә** Казан федераль университетында III Казан халыкара лингвистик саммит узды. Чарада 700 дән артык кеше катнашты. Саммитның игътибар үзәгенә төрле телләрне укыту проблемалары, лингвистиканың психология, медицина, программалаштыру һәм сәясәт белән бәйләнеше, дөнья җәмгыятьчелегенең бүгенге үсеш этабында тел белгечләренең бурычлары кебек тел мәсьәләләре куелды. Быелгы Халыкара саммит – 200 ел элек салынган традицияләрнең хәзерге буын лингвистлары һәм филологлары тарафыннан уңышлы дәвам ителүенең ачык дәлиле.

**2022 елның 16–17 ноябрендә** Россия Президенты каршындагы Милләтара мөнәсәбәтләр советының 10 еллыгына багышланган «Россия: бердәмлек һәм күптөрлелек» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Чара Россия Федерациясе Президенты каршындагы Милләтара мөнәсәбәтләр советы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы һәм Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык тарафыннан оештырылган иде. Конференциядә дәүләт хакимияте органнары вәкилләре, фән һәм мәгариф оешмалары хезмәткәрләре, иҗтимагый-сәяси өлкәнең аерым тармакларыннан экспертлар катнашты. Эш Россия Федерациясе дәүләт милли сәясәтенең максатлары, өстенлекле бурычлары һәм юнәлешләрен исәпкә алып билгеләнгән сигез секциядә оештырылды. Конференциядә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Гөлназ Мөхәрләмова «Россиянең этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклау» секциясендә Татарстан Республикасында татар теле мисалында Россия Федерациясе халыкларының туган телләрен саклау һәм үстерү барышына фәнни һәм фәнни-методик ярдәм итү үзенчәлекләрен яктыртуга багышланган доклад белән чыгыш ясады.

**2022 елның 17 ноябрендә** Россия Фәннәр академиясе һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы, дөньякүләм танылган астрофизик, Россия Фәннәр академиясенең космик тикшеренүләр институтында бүлек мөдире, Макс Планк җәмгыяте Астрофизика институтының директор-эмериты, Принстонда урнашкан Перспектив тикшеренүләр институты профессоры Рәшит Али улы Сөнәев Макс Планк исемендәге медаль белән бүләкләнде.

**2022 елның 23–25 ноябрендә** Уфа фән һәм технологияләр университетының Стәрлетамак филиалында татар һәм чуваш филологиясе кафедрасы оешуга 25 ел тулуга багышланган «XXI гасырда төрки филология: проблемалар һәм перспективалар» дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды. Аның эшендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының инновация эшчәнлеге һәм тышкы элемтәләр буенча директор урынбасары, филология фәннәре кандидаты Алсу Шәрипова һәм әдәбият белеме бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов катнашып,

пленар докладлар белән чыгыш ясады. Чара кысаларында шулай ук Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фәнни басмалары тәкъдим ителде. Уфа фән һәм технологияләр университеты Стәрлетамак филиалының татар һәм чуваш филологиясе кафедрасына, Башкортстан Республикасы татарлары конгрессының Стәрлетамак шәһәр бүлекчәсенә, Стәрлетамак шәһәр округының 5 нче гимназиясенә ТӘһСИнең соңгы елларда дөнья күргән басмалары бүләк итеп тапшырылды.

**2022 елның 25–27 ноябрендә** узган Дөньякүләм «Татарча диктант» акциясендә 31 ил һәм Россия Федерациясенең 74 төбәгендә 1 106 827 кеше катнашты. Акциянең рәсми сайты (https://diktant.tatar/) чыганагыннан алынган мәгълүмат буенча, быел дөнья буйлап 5 меңнән артык диктант мәйданчыгы оештырылган, шуның 2 меңнән артыгы – Татарстан Республикасында. Акция үзенең татарча язу дәрәҗәсен тикшереп карарга теләгән һәм туган теленең язмышына битараф булмаган замандашларыбыз өчен булдырылды. Акцияне оештыручылар: Бөтендөнья татар яшьләре форумы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, Казан (Идел буе) Федераль университеты, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе, Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгы.

**2022 елның 30 ноябрендә** «Шәҗәрә – Моя родословная» Бөтенроссия фестиваль-бәйгесенең финалы узды. Бәйге Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының мәгариф һәм мәдәният бүлекләре белән берлектә икенче ел рәттән үткәрелә. Быел әлеге бәйгедә катнашу өчен Татарстан Республикасы районнарыннан һәм Россия Федерациясе төбәкләреннән барлыгы 150 гариза кабул ителгән. Шуның 37 се финалга узды. Финалистларның унысы (нигезләмә буенча) җиңүче дип табылган. Сигез катнашучы жюриның махсус бүләгенә лаек булды.

**2022 елның 1 декабрендә** Ташкентта Мирзо Улугбәк исемендәге Үзбәкстан милли университетында Казан федераль университеты каршындагы Каюм Насыйри институтының белем бирү һәм мәдәният үзәге ачылды. Үзәкне ачу тантанасы Үзбәкстан Республикасында Татар мәдәнияте көннәре кысаларында узган. Анда Үзбәкстан Милли университеты ректоры Ином Маджидов, Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, КФУның Каюм Насыйри институты директоры Әлфия Йосыпова, студентлар һәм укытучылар, Ташкенттагы татар диаспорасы вәкилләре катнашкан. Узган елларда Каюм Насыйри институты базасында Астанада (Казакъстан), Бишкәктә (Кыргызстан Республикасы), Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Уфа, Самара, Пенза, Чабаксар, Ульяновск, Тубыл шәһәрләрендә һәм Пермь краенда унике белем бирү һәм мәдәният үзәге ачылган.

**2022 елның 2–3 декабрендә** Уфада Россия халыклары мәдәни мирасы елына багышланган чаралар кысасында «Фольклор һәм әдәбият традицияләре: кичә, бүген, иртәгә» исемле Халыкара фәнни конференция узды. Төп оештыручылар – А.М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтының Фольклор, Россия һәм СНГ халыклары әдәбияты бүлекләре һәм Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университеты. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре филология фәннәре докторлары Л.Х. Мөхәммәтҗанова, Л.Х. Дәүләтшина, филология фәннәре кандидаты Р.Ф. Сафиуллина әлеге конференциядә онлайн катнашып, фәнни докладлар белән чыгыш ясадылар.

**2022 елның 4 декабрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында киез һәм ефәктән тегелгән татар халык стилендәге костюмнар тәкъдим ителде. Чарада Татарстан Республикасы «Киез НУР» төбәк иҗтимагый оешмасы осталарының Президент мәдәни инициативалар фонды ярдәмендә гамәлгә ашырыла торган проект кысаларында ясалган эшләнмәләре күрсәтелде. Билгеле булганча, «Киез НУР» оешмасы үзенең эшен институтның Сәнгать белеме үзәге белән тыгыз хезмәттәшлектә алып бара. Чара кысаларында татар халкы өчен традицион булган бу шөгыль белән якыннанрак танышырга теләүчеләр өчен киез басу техникасын үзләштерү буенча мастер-класс уздырылды.

**2022 елның 4 декабрендә** Татар китабы йортында XXII «Иделем акчарлагы» яшь язучылар бәйгесе җиңүчеләрен тәбрикләү тантанасы узды. Конкурсны оештыручылар: Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татар федераль милли-мәдәни автономиясе, «Идел» яшьләр үзәге. Бәйгегә Россия Федерациясе төбәкләреннән һәм Татарстан районнарыннан 375 эш кабул ителгән иде. Әлеге эшләрне язучы, шагыйрьләрдән торган мөхтәрәм жюри бәяләде. Гран-прига Балтач районыннан Гөлназ Әхмәдиева лаек булды.

**2022 елның 5–11 декабрендә** Казанда «Һөнәр» XIV Бөтенроссия яшь режиссура фестивале узды. Фестиваль кысаларында Татарстан, шулай ук Владимир, Чиләбе һәм Санкт-Петербург театрлары алып килгән 23 спектакль тәкъдим ителде. Фестивальнең төп мәйданчыклары Казан театрлары булды, ә Чаллы һәм Әлмәт драма театрлары спектакльләрне үз мәйданчыкларында күрсәтте.

**2022 елның 7 декабрендә** Татарстан Республикасы Дәүләт Советында татар телендәге мәгълүмати күрсәткечләрдә хаталарны ачыклау буенча бәйгегә йомгак ясау тантанасы булды. Чарада Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия

Сабурская, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары, комиссия әгъзасы Камил Нугаев катнашты. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин тантанада чыгыш ясап, татар атамаларындагы хаталарны ачыклауга гражданнарны җәлеп итү кешеләрнең тел чисталыгы һәм аны яклау белән кызыксынуын күрсәтә, дигән фикер белдерде.

**2022 елның 8–10 декабрендә** Казанда «Россия музейларында ислам мирасы» дигән Бөтенроссия конференциясе узды. Фәнни форум Татарстан җирендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган иде. Ислам тарихы, бүгенге дөньяда ислам сәнгатенең роле, рухи кыйммәтләрне саклау, динара диалог, мөселман мәдәнияте предметларының уникаль коллекцияләре һ.б. темаларга багышланган докладлар белән Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Азов, Грозный, Саранск, Истанбул, Баку һ.б. шәһәрләрнең музей, архив, китапханә һәм мәгариф учреждениеләре галимнәре, белгечләре чыгыш ясады. Фәнни форум Татарстан Милли музее тарафыннан мәдәният министрлыгы ярдәме белән гамәлгә куелды. Оештыручылары – Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Болгар ислам академиясе һәм Россия ислам институты.

**2022 елның 7–9 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Дөньякүләм рухи мәдәният контекстында төрки телле китап» темасына багышланган ел саен уздырыла торган «Татар гыйлеме» Халыкара яшьләр фәнни мәктәбен оештырды. Ел саен үткәрелә торган «Татар гыйлеме» Халыкара яшьләр фәнни мәктәбе быел дүртенче кат уздырылды. Чараны оештыруның максаты – фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү дәрәҗәсен күтәрү, талантлы яшьләрне фән үсешенең өстенлекле юнәлешләре буенча фундаменталь фәнни тикшеренүләрдә катнашуга җәлеп итү, халыкара кооперация һәм яшь галимнәрнең, аспирантларның һәм магистрантларның мобильлеген арттыру нәтиҗәсендә фән һәм мәгарифнең дәрәҗәсен күтәрү. Халыкара яшьләр фәнни мәктәбе эшендә быел Үзбәкстан, Азәрбайҗан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа шәһәрләре, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе галимнәре, республиканың фәнни һәм фәнни-мәгариф учреждениеләре, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре һ.б. катнашты. Фәнни мәктәп кысаларында Россия һәм якын чит илләрдән чыганак белеме, сәнгать белеме, археография өлкәсендә эйдәп баручы галимнәрнең лекцияләре тыңланды.

**2022 елның 8–9 декабрендә** Мәскәүдә халыкара иҗтимагый оешма һәм Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте ярдәме белән Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында «Гаделлек һәм урталык: дөнья низамының илаһи прин-

циплары» дигән исем астында XVIII Халыкара мөселман форумы узды. Форумда дин әһелләре, академия җәмәгатьчелеге вәкилләре, дөньяның 30 иленнән, шул исәптән Азәрбайҗан, Беларусь, Мисыр, Һиндстан, Индонезия, Ирак, Иран, Казакъстан, Катар, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Пакъстан, Согуд Гарәбстаны, Төркия, Үзбәкстаннан вәкилләр катнашты. Чарага Татарстан Республикасыннан ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев барды һәм пленар утырышта чыгыш ясады. Ул Татарстан Республикасы Президенты һәм Хөкүмәте исеменнән форум эшендә катнашучыларны сәламләде, чараның мөһимлеген ассызыклады.

**2022 елның 9 декабрендә** Россиянең хәзерге заман тарихы үзәк дәүләт музеенда «Ислам Бакчалары. Гасырлар аша иман нуры» күргәзмәсен ачу тантанасы узды. Әлеге чарада Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев катнашты. Күргәзмә Идел буе Болгар дәүләте халыклары тарафыннан рәсми рәвештә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышланган һәм рәсем сәнгате әсәрләре аша Россия мөселманнары тарихының төп вакыйгаларын һәм шәхесләрен ачуга юнәлдерелгән. Экспозициядә «Россия дәүләте мөфтиләре: империядән-федерациягә», «Мәскәү җамигъ мәчете имамнары» портретлары һәм «Мәдинә» нәшрият йортының шәхси коллекциясеннән Илдар Акжигитов, Рөстәм Хуҗин, Ләйлә Хәсьянованың сәнгать әсәрләре тәкъдим ителгән. «Ислам бакчалары. Гасырлар аша иман нуры» күргәзмәсе Россия Федерациясе мөселманнарының Диния нәзарәте һәм «Мәдинә» нәшрият йорты ярдәме белән оештырылды. Ул 2023 елның 15 гыйнварына кадәр эшлиячәк.

**2022 елның 12 декабрендә** Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музеенда Тукайның «Күңелле сәхифәләр» китабы тәкъдим ителде. Бу – Габдулла Тукай үзе исән вакытта нәшер ителгән китапның репринт вариантларын кулланып әзерләнгән яңа форматтагы басма. Габдулла Тукайның «Күңелле сәхифәләр» китабы беренче тапкыр 1910 елда Казанда «Сабах» нәшрияты, «Милләт» типографиясендә гарәп графикасында нәшер ителә. 2022 елгы басма Татарстан Республикасы Милли музее фондларында, Габдулла Тукай әдәби музее экспозициясендәге нөсхәләргә нигезләнеп, бөтен үзенчәлекләрне саклап әзерләнгән. Әлеге китап – Г. Тукайның әдәби музее белән Татарстан китап нәшриятының берничә елга сузылган ныклы хезмәттәшлеге нәтиҗәсе.

**2022 елның 14–15 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм Алтын Урданы өйрәнүче галимнәрнең Халыкара ассоциациясе тарафыннан «Идел буе Болгарында һәм Алтын Урдада ислам кабул ителүнең цивилизацион әһәмияте: Россиянең Урта гасырлар тарихында интеграцион процесслар» дип исемләнгән VII Халыкара

Алтын Урда форумы оештырылды. Чарада Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре актив катнашты, халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәрләре, филология фәннәре докторлары Лилия Мөхәмммәтҗанова, Илсөяр Закирова татар дастаннарына багышланган фәнни докладлар белән чыгыш ясады.

**2022 елның 16 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Хәзерге дөньяда традицион мәдәниятне саклау һәм үстерү тәҗрибәсе» дип аталган I Халыкара конференция узды. Чара Сәнгать белеме үзәге тарафыннан халык сәнгатен популярлаштыру һәм мәдәни традицияләрне, тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен, этномәдәни күптөрлелекне, барлык халыкларның мәдәни үзенчәлеген саклап калу максатыннан игълан ителгән Россия халыкларының мәдәни мирасы елы кысаларында оештырылды. Конференциядә традицион мәдәниятнең төрле формаларындагы тарихи үзенчәлекләр, шулай ук Татарстанда, Төньяк Кавказ (Дагстан, Ингушетия) республикаларында, Кавказ арты (Азәрбайҗан, Грузия) һәм Үзәк Азия (Казакъстан, Үзбәкстан) илләрендә этномәдәниятне саклау һәм үстерү мәсьәләләре каралды.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

– авторның фамилиясе, инициаллары
– мәкалә исеме (татар һәм рус телендә)
– аннотация (рус һәм инглиз телендә)
– төп сүзләр (рус һәм инглиз телендә)
– сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, әтисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12, 1 нче кат, 10 нчы бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек*
*итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2022. № 4

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 23.12.2022. Басылды: 12.01.2023.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 12. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла